# Сәләткә нур булган йолдызлар



# «СӘЛӘТКӘ НУР БУЛГАН ЙОЛДЫЗЛАР»

*(өченче китап)*

Шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, пьеса һәм публицистик язмалар

Казан, 2021
imagestudio

УДК 821.512.145–1/–2/–3/–4
ББК 84 (2Рос = Тат) –4/–5/–6
С94

**«Сәләткә нур булган йолдызлар»**

Өченче китап: шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, пьеса һәм публицистик язмалар / [төз. һәм кереш сүз авт. Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур блугна йолдызлар» конкурсының оештыру комитеты]. – Казан: imagestudio., 2021.– 187

**Төзүчесе:** Флүс Латыйфи исемендәнге «Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсының оештыру комитеты

Әдәбиятка яшьләр килә. Кечкенәдән җитди иҗатка омтылган яшь буын каләмен төрле жанрларда сыный. Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсы – яшьләрнең төп ярдәмчесе. Бу җыентыкта конкурста җиңү яулаучыларның һәм казыйлар тарафыннан аерым игътибарга лаек булучыларның да, конкурска беренче эшләрен җибәрүчеләрнең дә эшләре туплап бирелде.

УДК 821.512.145–1/–2/–3/–4
ББК 84 (2Рос = Тат) –4/–5/–6

# Кереш сүз

«Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсы елдан-ел зуррак аудитория туплый: катнашучылар саны арта, география киңәя. Конкурска килгән эшләр дә елдан-ел күбрәк куандыра. Әлбәттә, конкурска килгән эшләр арасында җитлеккән әдипнеке дип карарга мөмкин булганнары да, күп тырышлык таләп иткәннәре дә бар.

Һәр авторның теле, язу алымы, дөньяга карашы аерылып тора. Тик ничек кенә булмасын, алар – татар әдәбияты, татар журналистикасының киләчәге булырдай кешеләр.

Вакыт узу белән, кечкенә генә чишмә дә танымаслык елгага әверелә ала. Моннан күп еллар элек без кечкенә чишмәне елга итү вазыйфасын үз өстебезгә алдык. Тәҗрибәле язучылар, шагыйрьләр, журналистлар һәм драматургларны, оештыру комитетын – барыбызны да бер максат берләштерә: яшь авторларга чын язучы булырга булышу.

Еллар узар. Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсыннан чыккан авторлар зур язучылар булып танылырлар. Ләкин һәркайсы үзенең чишмә башының кайда булуын йөрәгендә саклар дип өметләнеп калабыз.


Шигърият

# 📖 12-14 яшьлекләр

**Николаева Алина Сергеевна, 13 яшь**
*Җитәкчесе: Хаҗиева Ләйсән Мансур кызы*

## ДӘҮ ӘНИЕМ – СУГЫШ БАЛАСЫ

Дәү әнигә «Әти» сүзен
Әйтү насыйп булмаган,
Аның матур балачагын
Явыз сугыш урлаган.

Әтисе киткән сугышка
Дәү әни карында чакта.
Һәм әйләнеп кайта алмаган
Янәдән туган якка.

Ятимлекне, ачлык чорын
Татып үскән дәү әни.
Бу хакта уйлап куйсам да,
Минем йөрәгем әрни.

Сез күргән авырлыкларны
Безгә күрү язмасын!
Күкләребез тыныч булсын,
Сугыш кабатланмасын!

**Галиева Әдилә Мөнир кызы, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Гарипова Наилә Габдрәшит кызы*

## ЯРАТМЫЙМ СУГЫШ СҮЗЕН

Яратмыйм сугыш сүзен,
Әбием дә яратмый.
Аның бабасы сугыштан
Кире әйләнеп кайтмый.

Җиңүләрнең иң зуры дип,
Көтеп ала май аен.
Бәлки кабере табылыр дип,
Көтә хәбәр көн саен.

Быел аның бабасына
Йөз дә сигез яшь тулган.
Әбиемнең күзләренә
Сагыш яшьләре тулган.

Сугыш сүзен яратмыйм мин,
Әбием дә яратмый.
Яуга киткән ир-егетләр
Кире әйләнеп кайтмый.

**Фархуллин Әмир Раиф улы, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Гыйззәтуллин Илфир Рәхимша улы*

## ДИСТАНТ ДӘРЕС

Иртә белән бик соң тордым,
Сәгатьтә сигез икән.
Расписание карадым:
Беренче дәрес тиздән.
Ашыктым ботка ашарга,
Тиз генә мин чәй эчтем
Тешне выж-быж чистарттым –
Ноут ачарга киттем …
Берзаман айфон шалтырый
«Синең Зум ачыламы?
Минеке никтер ачылмый …»
– Минем дә ачылмады!…
Ничектер без Зумнан кердек
Нигәдер ишетелми
«Ишетелә?» – дип языштык
Юк , никтер ишетелми!
Шулай үтте минут утыз,
Беренче дәрес бетте.
«Ярар», – диде укытучыбыз.
«Менә сезгә өй эше» …
Икенче дәрес башланды –
Тагын без Зумнан кердек.
«Бүген сезгә – тест», – диюгә.
Без коелышып индек.
Беренче өч сорауларга
Җаваплар биргән идем,
Шулвакыт китте SMS
«Кая, ничек эшләдең?»
Тестка җавап биргән саен,

Күбрәк SMS яуды ...
«Плиз,
Ничек эшләдең? Күрсәт!
Болар гына бит калды.»
Эшли-эшли, яза-яза,
Ерып чыктым мин моны,
Тик SMS дулкыннары
Көч җыеп кына барды.
«Эй! Алло! Плиз, алтынчысын! –
«Юк, эшем бар. Үзең тап» –
«Ну Фархул, ну плиз, бик зинһар!» –
«Тапсаң бит инетта бар!»
Пешә-пешә, тирли-тирли,
Классташ белән әрли-әрли
Сизмәгәнем бу дәреснең
Ахырына җиткәнен.
Тестның җаваплары китте
Ватсап аша апага.
Бер көнлек дистант-дәрес ул
Тигездер бер атнага!

# 15-18 яшьлекләр

**Галиуллина Руфинә Роберт кызы, 17 яшь**

## ТАТАРСТАН – ТУГАН ИЛЕМ

Туган җирем – Татарстан!
Горурланып сөйләр үз илем.
Гүзәл табигате әсир иткән
Байлыкларың белән мул җирем.

Гөрләп эшли завод-фабрикалар,
Кырларыңда шаулый игенең.
Нефть чыганагы булып тора
Нурлат, Әлмәт, Азнакай җирең.

Шаулый Идел, Чулман елгалары.
Күлләре дә һич тә калышмый,
Үрчи анда чөгә, чуртан, сазан,
Елгаларда баржалар эшли.

Башкаласы – горур, матур Казан,
Илебезнең иң зур шәһәре.
1000 ел тулган чал тарихлы шәһәр.
Татарымның бөек мәркәзе.

Тагын бик күп шәһәрләре белән
Горурлана ала Татарстан.
Әлмәт, Чаллы, Нурлат, Түбән Кама
Балкып тора ерак-ерактан.

Табигатькә килсәк, ул аңа бай.
Урманнары шаулый диңгез күк.

Сайрый анда төрле матур кошлар,
Җәнлекләр дә анда шундый күп.

Татарстан – республикам минем!
Мәңге яшь кал минем күңелдә,
Мин яшәрмен горурланып кына
Шундый гүзәл туган илемдә!

## **Билалова Айзилә Ренат кызы, 18 яшь**

***

Әкрен,
әлай еш күз атма син,
кузгатма хәтернең көртләрен,
яныма килергә әзерме,
калтырап торганда ут тәнем.
Юк шигем,
тик синең караштан
аяктан куба җир, ишелә
күкләрдән яралган мәдхия
һәм тула ярасыз җаныма.
Каныма береккән моң гына
булып кал, кирәкми артыгы,
аяусыз күзләрең яктысын
мин сүзсез күптәннән ятладым.

**Вәлиев Кәрим Сергей улы, 14 яшь**

*Җитәкчесе: Бикмөхәммәдова Светлана Валентин кызы*

## АВЫЛЫМ

Оҗмахка тиң синең табигатең,
Авылкаем – якты йолдызым.
Яшел хәтфә элгән урманында,
Хозурланып йөрим ялгызым.

Тау башында челтрәп аккан чишмәң,
Сихәт бирә тәнгә, җаныма.
Тормышымнан сине артык күрү,
Сеңгән ахры минем каныма.

Кайберәүләр өчен җаным әрни,
Алар сине бик тиз оныта.
Күлләреңә төрле чүп- чар ташлап,
Агачыңны кисеп корыта.

Сиңа булган ихтирамга дәлил,
Йөрәк язган шигырь юллары.
Тормышымда һәрчак маяк булыр,
Синдә үткән яшьлек еллары.

**Вәлиев Рәзил Рәмис улы ,16 яшь**
*Җитәкчесе: Әхмәтшина Люция Таһир кызы*

## ЯРАТАМ ТУГАН ЯГЫМНЫ

Яратам мин туган авылымда
Сызылып матур таңнар атуын.
Язлар җиткәч туган якларыма
Җылы яктан кошлар кайтуын.

Яратам мин ямьле җәйләр җиткәч,
Болыннарда җиләк җыярга.
Хуш ис бөркеп торган чәчәкләргә
Төрле күбәләкләр кунганда.

Яратам мин алтын көзләр җиткәч,
Төрле төскә кергән урманны.
Сары төскә кереп матур булып
Көнбагышлар үскән кырларны.

Яратам мин салкын кышлар җиткәч,
Җиргә йомшак карлар ятуын
Ак чәчәктәй булып тирә-якка
Әкрен генә карлар яуын.

**Габделхакова Әдилә, 15 яшь**

# ТУГАН ТЕЛЕМ

Туган телдә горурланып,
Әни, диеп эндәшәм.
Туган телем һич югалмас,
Яшәр җирдә, гел яшәр.
Хөрмәтлибез татар телен,
Туган телем булганга.
Горурланам мин бу җиргә
Татар булып туганга.
Хөрмәтлик без туган телне,
Туган тел ул бер генә.
Шул вакытта телем яшәр,
Кадерләрен бел генә!
Татар булып туганмын мин,
Татар булып яшәрмен.
Телебезне югалтмыйк дип,
Яшь буынга дәшәрмен.
Алмаштырмыйк туган телне,
Башка чит-ят телләргә.
Яшәсен туган телем дип,
Кала безгә теләргә.
Онытсаң син татар телен,
Алыштырсаң чит телгә,
Бу була телгә хыянәт,
Ярамый болай бер дә.
Саф татарча матур итеп,
Сөйләшеп яшик әле.
Әйткән киңәшне, укучым,
Тыңла, зинһар, син яме!
Телемнең киләчәге дә,
Укучым, синең – кулда.
Телем һәркөн чәчәк атсын,
Шул теләк минем уйда.

**Газизова Ләйсән Ильшат кызы, 18 яшь**

## МӘҢГЕЛЕККӘ КИТСЕН САГЫШЛАР...

Искән җилләр бәхет алып килсен,
Мәңгелеккә китсен сагышлар.
Таң йолдызы кебек якты көннәр
Язмыш миңа меңләп багышлар.

Яшьлек язында кайнасам да
Балачагым әле үтмәгән.
Диңгезләрдәй тулган күңелемнән,
Көзге уйлар әле чыгып бетмәгән.

Кошлар китте канат кагып,
Ә сагышлар тик китмиләр.
Ярый әле бар дус-иптәшләр
Җаннарыма бәхет өстиләр.

Бәлаләрдән, язмыш, бушат мине,
Килгән авырлыктан арыныйм.
Туган илнең якты күгендәге
Сандугачтай канат кагыныйм.

Туйдым бик тә кышкы сагыштан,
Ямьле язлар, тизрәк җитегез.
Сынасаң да сына инде, язмыш,
Кайгыларым гына китегез.

**Гатина Алинә Әлфәт кызы, 15 яшь**
*Камалова Гөлсирин Сәгыйть кызы*

# ҖИҢҮ КӨНЕ

Безгә җиңү биргән, илне гөлгә күмгән,
Тынычлыкны яклап яу кергән.
Бабамнарны бүген, искә алып тагын.
Оныклары булып баш иям.

Сирәгәйде инде ветераннар рәте
Китаплардан гына беләбез.
Сугыш чорларының балаларын хәзер
Геройларга тиңдәш күрәбез.

Бабам сөйли миңа сугыш чорын елап,
Ачлы-туклы узган чорларны.
Әкият кебек тыңлыйм ышанмаслык хәлләр,
Кайгылардан торган елларны.

Алты-җиде яшьтә бабам ятим калып
Җиккән нужа тормыш арбасын.
Истәлекләр аша, шигырьләргә салып
Сөйли бабам сугыш язмасын.

Озак яшә диеп, битләреннән үбеп,
Геройга тиңлим мин аны.
Минем кебек чакта, ир егетләр кебек,
Дөнья көткән газиз бабамны.

Илләребез кабат сугыш утын тоеп,
Яшәмәсен иде калтырап.
Зәңгәр күк йөзендә бәхет диңгезедәй
Чыксын иде кояш ялтырап.

**Гафарова Илүзә Альфир кызы, 18 яшь**

## «ХИС ИТӘСЕМ КИЛӘ БЕРӘР НӘРСӘ»

Хис итәсем килә берәр нәрсә
Булсын ачу, булсын мәхәббәт
Хәтта түзәр идем кешеләрнең
Булуына кайчак кабахәт
Кеше килә жиргә тояр өчен
Хис ташкынын бүләк итәргә
Ә мин тоям бушлык кына никтер
Мәгьнәсездер шуна яшәргә.
Булсын авыр, булсын бик тә кыен
Түзәм барсын, тешне мин кысып
Шатлыкны да күңел түрләреннән
Йөрер идем жиргә таратып.
Алсу күзлек киеп карар идем,
Дөньяларның шау-шу мәленә
Яшь килгәндә, елап алыр идем,
Көлер идем кеше көлгәндә.
«Мин бит кеше», – дияр идем
Йөрәк кенә таштан ясалган.
Бар нәрсәгә хиссез, төкереп карау –
Шулай минем дөнья каралган.

**Гимадиева Ләйсән Илгиз кызы, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Фәтхуллова Римма Хәбетдин кызы*

## АЛИШ АБЫЙГА

Алиш абый әкиятләре
Бирә әхлак, тәрбия.
Бөтен халык сезнең алда
Бүген дә бит баш ия.

Гади телле, эчтәлекле,
Кызыклы сезнең иҗат.
Бөек мәшһүр Алишыбыз
Булуына без бик шат.

## Әхмәдиева Гөлназ Мәлик кызы, 16 яшь

***

табаныңны
җомга саен
кытыкласа чирәм шавы,
үткән өчен
җавап тотма –
һәр үткәннең үз чаршавы.
һәр үткәннең
киләчәге
башкаларга охшамаган.
башы гына
шигыремнең -
рифмалары таушалмаган.
кауша, урам!
бит син генә
курыкмыйсың үлемнәрдән.
аерырга
авыр хәзер
үлгәннәрне исәннәрдән.
үзәннәрдән
тамчы көлә
ярып илһам кәсепчесен.
шаулат, димен,
диктофоның!
тынсын бераз җил ачысы.
яз тамчысы -
гашыйклыгым
катыш нәфрәт сүрәләре.
безгә тәнкыйть
бирерсезме,
мәхәббәтнең түрәләре?

**Гыйниятуллина Алинә Динар кызы. 17 яшь**
*Җитәкчесе: Рамазанова Розалия Гарифулла кызы*

## ИСКЕ КАЗАНЫМ

Туфрагыңның һәрбер бөртегендә
Күз яшьләре, сагыш, моң-зарың.
Изге җирдә халкың дога кыла,
Яңарасың, Иске Казаным.

Чын хаклыкны диварларың күргән,
Телгә килеп әйтер уйларын.
Кайсы нәселдән мин? Хакыйкатьне
Сөйлә әле, Иске Казаным.

Вакыт үтеп, бәлки буталгандыр
Хаклык белән ялган арасы.
Киләчәккә чын тарихны белеп,
Горурланып килә барасы.

Табигатең ямьле, һавасы саф,
Кошлар җырлый матур җырларын.
Татар дөньясында йолдыз булып,
Мәңге балкы, Иске Казаным!

**Әкрамова Газизә Рамил кызы, 15 яшь**
*Җитәкчесе: Сәләхова Зөлфирә Үрнәк кызы*

## КҮБӘЛӘК

Дусларым, дускайларым,
Минем янга килегез!
Гаҗәп чуар күбәләк,
Нинди матур, күрегез.
Җырым ишетеп килдеңме,
Калдырып урман-кырны.
Рәхмәт сиңа, күбәләккәй,
Син тыңлыйсың җырымны.
Кунак итәр идем сине,
Ширбәтләр белән сыйлап.
Мин дә синең кебек шулай
Үсәмен биеп, җырлап.
Урман-суның, болыннарның
Алиһәсе – күбәләк.
Әй, сөйләштем рәхәтләнеп,
Яннарына чүгәләп.
Күлмәгеннән күз чагыла,
Өрфия сыман юка.
Гомере кыска, күбәләкнең
Рәнҗетә күрмик юкка.

**Әүһәдиева Тәнзилә Хәмит кызы, 17 яшь**
*Җитәкчесе: Габбасова Гөлсинә Камил кызы*

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, САБАН ТУЕ

Җәйнең иң матур аенда
Сабан туе итәбез.
Котлы булсын, тыныч булсын
Туачак һәр иртәбез.
Районыбыз уртасыннан
Себергәчә юл үтә.
Бер күрергә зар булып,
Кунаклар шуннан кайта.
Очрашабыз, күрешәбез,
Сөйләшәбез Сабантуйда.
Әгәр Сабантуй булмаса,
Гөрләшер идек кайда?
Яшен, картын җилкендереп
Хуш киләсең, Сабан туй.
Сабан туе кебек булсын
Тормышыбыз гомер буе.
Арыш чәчтек, иген чәчтек,
Игенебез гөрләп үссен.
Күзләрен табыннарыбыз
Сый-нигъмәт белән тулсын.
Киләсе ел Сабантуйга
Онытмагыз, кайтыгыз.
Туган газиз туфракта
Сезне каршы алырбыз.
Сабан туйда сайрашырбыз
Күңелләрне ачарбыз,
Шулай кайтсагыз кунакка
Шат булырбыз барчабыз.

**Әхмәдуллина Зәлия Илназ кызы, 15 яшь**

## ЯЗАМ ӘЛЕ АВЫЛЫМ ТУРЫНДА

Авылымның табигате гүзәл
Урнашкан ул матур урынга.
Хисләремне тигез җепкә тезеп
Язам әле аның турында.

Тау башына салынмаган авлым
Елга ага бүлеп икегә.
Авылыннан аерылган кеше
Сагына башлый аны, китүгә.

Авылымның урамнары чиста
Балкып тора матур өйләре.
Ә кичләрен урам яңгыратып
Ишетелә татар көйләре.

Төз каеннар озатып кала безне
Яшел шәлләренә уралып.
Туган йортны берүк онытмагыз,
Йөрмәгез сез, дия югалып.

Җәен яшеллеккә күмелә авыл,
Шау чәчәктә капка төпләре.
Нинди генә гөлләр үсми анда,
Һәрберсе дә исең китмәле.

Акрын гына кояш күтәрелә
Алсулатып офык читләрен.
Җил- егет тә никтер тынып калган,
Җилфердәтми җиләс чикмәнен.

Авыл урамнарын тутырып көтү килә,
Куа килә абый-апалар.

Әнә шулай алар көн дә мал-туарны
Матур итеп озатып калалар.

Каз-үрдәкләр йөри яр буенда
Суга бара сылу апалар.
Бар да матур туган авылымда,
Таңнары да үзгә аталар.

**Зәһидуллина Алия Фәрит кызы, 18 яшь**

## ҖИҢҮЕГЕЗ ӨЧЕН МЕҢ РӘХМӘТ!

Җиңү бәйрәме…
Сугыш афәте тынганга
Үтсә дә бик күп еллар,
Күз яшьләрен тыя алмый
Безнең әби-бабайлар.

Ватан өчен үз көчләрен
Кызганмый тырышканнар.
Тыныч тормыш булсын өчен,
Аяусыз сугышканнар.

Җиңү яулап кайткан өчен,
Без бит мәңге сезгә рәхмәтле!
Аяз күкләр, тыныч көннәр өчен
Күрсәтә алсак идек хөрмәтне.

Сугышның бар михнәтен күреп,
Көрәшкәнсез ачлыкка түзеп.
Рәхмәт әйтеп, баш иябез бүген
Сезнең алда тез чүгеп.

Чыкмас мәңге безнең хәтердән
Җиңүнең җитмешенче язы
Ветераннарның бу язны
Каршылады бик азы.

Сугыш чоры балаларына да
Дан җырлыйбыз бүген бергәләп,

Сезне искә алып һәйкәлләргә
Без йөрибез һәрчак кергәләп.

Гасырлардан гасырларга күчеп,
Ирешсеннәр рәхмәт сүзләре.
Сугыш кичкән буын – өлкәннәрнең
Яшьләнмәсен иде күзләре!

**Җамалова Гүзәл Фәрит кызы, 17 яшь**

## ЯШӘ СӨЕНЕП КЕНӘ

Һәр туар таң сине күрү –
Бәхет бит ул, әнием.
Синә атап шигырь язу –
Йөрәк җылым бит, бәгърем.
Туган һәр көнгә сөенәм
Син янымда булганда.
Әни кызы булу бит ул –
Иң зур бәхет дөньяда.
«Оҗмах – әниләребезнең
аяк астында», – диләр.
Аналар – фәрештә ул!
Ансын мин күптән беләм.
Ачык йөзең, нурлы күзең
Фәрештәләргә тиң синең.
Җылы сүзең, йомшак кулың
Саф алтындыр син үзең.
Тагын бик күп, бик күп
Еллар язсын бергә яшәргә.
«Әнием, хәлең ничек?» – дип
Һәрчак иртән дәшәргә.
Яшә әле кайгы күрми
«Балам», – диеп, сөенеп.
Шомырт чәчкәләре сыман
Кояш нурына төренеп.

**Минһаҗева Зөһрә Илсур кызы, 15 яшь**
*Җитәкчесе: Дәүләтова Рушания Фатих кызы*

# МИЛЛӘТЛӘР ДУСЛЫГЫ

Нәрсә соң ул милләтләрнең
Бердәмлеге, дуслыгы?
Телләре төрле булса да,
Була аңлашу теле.
Рәсәйдәге һәрбер милләт
Үз телендә сөйләшә.
Кирәк булганда, үзара
Рус телендә аңлаша.
Һәр милләтнең үз көе бар,
Үз шигыре, үз җыры.
Төрле милләтләр очрашса,
Карашлар була җылы.
Халыклар төрле булса да,
Бер-берсен хөрмәт итә –
Бу бит милләтләр дуслыгы,
Бердәмлеккә ни җитә.

**Рәшитова Гөлназ Рөстәм кызы, 18 яшь**
*Җитәкчесе: Нигъмәтҗанова Гүзәл Васил кызы*

## БУРАН

Урамда кар ява бураннап.
Бернәрсә күренми каршыда.
Күңелдә дә жилләр ыжгыра-ыжгыра
онытылган хисләрне туздыра.

Күңелдә дә минем салкын кыш.
Яз җитеп эрерме бу бозлар?
Бураннар да, җилләр бераздан басылыр,
тик әрни йөрәктә яралар.

Ышанам, барысы да төзәлер,
тик күпме вакытлар үтәдер.
Язмышны үзгәртеп, үзгәртеп лә булмый,
сынаулар күкләрдән киләдер…

**Сабирҗанова Сөмбел Әлфрит кызы, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Шәймөхәмәтова Әлфия Искәндәр кызы*

## КИТАПЛАРДАН, ЗИНҺАР АЕРМАГЫЗ!

«Укы инде, балам, укы!» – диеп,
Кирәкми лә миңа әйтергә.
Минем күңелем үзе ашкына ич
Китаплардан күпне белергә.

Геройлары белән серләшәм дә,
Шатлыклары булса, сөенәм.
Кайгыларын миңа сөйләсәләр,
Алар өчен бик тә көенәм.

Җырласалар, алар белән җырлыйм,
Күңелем шат, шаярсалар.
Бик ямансу булыр иде миңа,
Китаптан аерсалар.

**Сафина Азалия, 15 яшь**

## ПЕСИЕМ

Минем нәни песием бар,
Йомшак исемле була.
Үзе шаян, үзе наян,
Төсе дә ала-кола.
Ашыйсы килгән чакта,
«Мияу», – дип кычкыра.
Мин биргән ризык белән,
Тамагын ул туйдыра.
Ипи бирәм, сөт бирәм,
Калган итне дә бирәм.
Йомшак шундый шатлана:
Әйтерсең аңа бәйрәм.

**Сафина Әдилә Альфред кызы, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Сафина Римма Ришат кызы*

## ТУГАН ТЕЛЕМ

Тел ачкычы тели миңа әбием,
Мәктәпкә дип киткән чагымда.
Белә шул ул: кайсы дәрестә дә,
Туган телем тора янымда.
Үз телемнең олылыгын тоеп,
Ышанып керәм һәрбер көнемә.
Тарихларны ачар ачкычым бар,
Рәхмәт яусын туган телемә.

**Тахавова Эльза Рамил кызы, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Хәйретдинова Гөлнур Мәхмүт кызы*

## МИНЕМ ӘТИ ИҢ-ИҢЕ

Минем әти иң-иңе,
Юктыр аңарга тиңе.
Җырлый, бии, йөгерә,
Юа, җыя, сикерә.

Ашарга да пешерә,
Йокларга да өлгерә.
Эшләмәгән эше юк,
Җитешмәгән җире юк.

Энемне дә уйната,
Әнине дә юата.
Абыйга ярдәм итә,
Миңа мәсьәлә чишә.

Бик яратам әтине,
Ул бит минем бер генә.
Ул да мине ярата,
Шулай булсын гел генә.

**Фархиева Рамилә, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Ильясова Алена Бари кызы*

## КОШЛАРЫМ

Ә мин кошлар очыра алмам инде –
Тургайларым калыр читлектә.
Сәбәп гади – мин алдаша белмим,
Кия белмим бит мин битлек тә.

Эчемдәге – тышымда шул минем,
Гел турыдан гына әйтәмен.
Шуңадырмы күпләр кача миннән,
Шуңа дустым минем бер дигән.

Иң якын дус намус булды минем,
Ансыз ятим калыр идем мин.
Ансыз яшәү яшәү түгел инде,
Гомрем суга салыр идем мин.

**Фәттахова Зәлидә Фәнәвил кызы, 17 яшь**

*Җитәкчесе: Фәттахова Гөлфия Илфат кызы*

## НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ

Шагыйрь кеше нинди була икән?
Шуңа җавап килә табасым.
Аның хисләр дөньясына чумып,
Килә шуннан гыйбрәт аласым.

Нәкый ага әсәрләре ачты
Минем бу дөньяга күземне.
Аның геройлары белән бергә
Яшәгәндәй тоям үземне.

Бормалы су юлы белән
Кызлар һаман суга барамы?
Уракчы кыз үрелеп су алганда
Сөйгән ярың искә аламы?

Яр буенда тыңлап утырганда,
Кемнәр хәзер сазда уйныйдыр.
Шәрыкъ кызы айлы матур төндә
Кемне шулай өзелеп уйлыйдыр.

Әллә инде Хуҗа Насретдинең
Шаяртамы тагын көлдереп.
Тапкыр теле, үткен сүзе белән
Тирә- якны хәйран калдырып.

Гади шыгыйрь, ләкин безгә күпме
Даһи әсәр язып калдырган.
Күпме укучысы күңелендә
Якты өмет, йолдыз кабызган.

Халык әйтсә, хак әйтә, диләр бит,
Син – халыкның булгансың үзе.
Ничә буын синең әсәрләрдән
Туплый, чыннан, хакыйкать сүзе.

Бөек иҗатыңа башны иеп,
Шигыремне юлладым сиңа
Әсәрләрең якты маяк булыр
Һәрбер яңа килгән буынга.

**Хәбибрахманова Айгөл Васил кызы, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Гафиева Алинә Ринат кызы*

## ӘНИЕМ ГӨЛЕ

Тәрәз төбе тулы гөлләр белән –
Әниемнең матур гөлләре.
Мин һәр иртә саен сокланамын,
Син дә, дустым, әйдә, күр әле.
Шау чәчәктә утыралар алар
Кояш нурларының астында,
Минем һәрбер иртәм үтеп китә
Бөтерелеп гөлләр янында.
Сулар сибәм «Матур булсын!» – диеп,
«Аумасын!» – дип бәйләп куямын.
Һәрбер иртә саен, горурланып,
Гөлләремә карап торамын.

**Халикова Камилә Рифат кызы, 15 яшь**
*Җитәкчесе: Галимҗанова Гөлүсә Ринат кызы*

## КАЛДЫР

Битлекләрне ачыйк,
Бу юлы ялгансыз!
Безне берләштерә
Җитди сәбәп.
«Соң!» – дисең
Җибәрәм,
Сүз бир…
Истә калдыр
Вакыт китте
Сиңа – бер сәгать.

**Хәйретдинова Гөльяз Илдус кызы, 16 яшь**

*Җитәкчесе: Галиева Ленара Рафаил кызы*

## ТАТАР ТЕЛЕМ – ТУГАН ТЕЛЕМ

Матур итеп саф татарча сөйлим
«Кем өйрәтте?» – диеп сорама!
Әйтегезче дуслар, я кайсыгыз,
Туган телсез бер көн торала?

Мин татарча сөйлим, уйныйм, көлм,
Биим, җырлыйм, бар да татарча!
Ана телем, газиз телем белән
Дәшәмен мин сезгә дусларча!

Кая барсак, кайда йөрсәк тә
Онытмаек туган телне без!
Татар телен, бөек Тукай телен
Саклыйк, яклыйк, дуслар, әйдәгез!

Мин сөйләшәм затлы туган телдә
Туган телдә – Татар телендә!
Татар теле, газиз Әнкәм теле –
Яңгырап торыр һәрчак телемдә!

Горурланам телем синең белән
Туганыма татар илендә.
Мин канәгать биргән соравыма
Жавап алсам, татар телендә!

**Шәймәрданова Ильнара Илгизәр кызы, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Гобәйдуллина Рушания Минәхмәт кызы*

## ДӘРЕСТӘ

Утырам мин дәрестә.
Вакытым булганда,
Шигырь язып алам шунда.
Дустым әйтә:
– Нишлисен син,
Гел язып утырасын?
Бер карасам дәфтәреңә,
Бер карасам буш биткә.
Сызгалыйсың, я язасың
Бердә тик тора алмыйсың!
– Мин бит – шагыйрь, – дидем аңа –
Уйларымны бушатам.
Уйларым эчтә кайный,
Бушатмасам – яный!
Нишләргә инде мина?
Берсе кушмый язарга!

**Кашапова Динә Рәис кызы, 15 яшь**
*Җитәкчесе: Шәгәрәева Алинә Илсур кызы*

# САГЫНУ

Белмим, әллә нидән бүген,
Болыт каплый күңел күгемне.
Яңгыр тамчылары түгел, күз яшьләре
Чылаталар битне, күземне.

Нигә моңсу, нигә авыр миңа?
Йолдызларым, җавап бирегез.
Төн тып-тыныч, ай, йолдызлар балкый,
Нидән миңа болай күңелсез?

Назлы дустым, җилем, әйтче, нигә
Елмаясым килми һич кенә?
Бөтен җиһан, бар зур дөнья, нидән
Минем өчен бүген кечкенә?

Ай-сердәшем, бәлки син әйтерсең,
Кайдан килгән мондый ашкыну?
Ай дәшмәде, тик төн пышылдады:
«Күңелеңдә синең – сагыну…»

**Мостафина Йолдыз Алмаз кызы, 16 яшь**
*Җитәкче: Гайнетдинова Нәфисә Хабибулла кызы*

## БҮГЕН МИНЕМ ШУНДЫЙ ХАЛӘТ

*30 март көнне бу дөньядан ахирәткә күчкән*
*бабам Р.А Мостафин рухына багышлыйм.*

Бүген минем шундый халәт,
Якын кешем китте еракка.
Әй, кадерле бабакаем минем,
Күңелем тула, алам елап та…
Син, бабаем, бик кадерле кешем,
Өйрәттең бит ихлас булырга.
Һәрвакытта әйтеп тордың миңа,
Гаделлек һәм намус турында.
Әй, бабаем, тыныч йокла инде,
Урыннарың булсын җәннәттә,
Синең язган матур шигырьләрең
Калыр мәңге минем йөрәктә!
Синнән күчкән миңа шундый сәләт:
Шигырь язам.
Чөнки…
Бүген минем шундый халәт…

**Дәүләтшина Ильвина Илдар кызы, 17 яшь**

*Җитәкчесе: Нигъмәтҗанова Гүзәл Васил кызы*

## САФ ҺАВА – ТӘНГӘ ДӘВА

Юкка гына әйтмиләр бит,
Саф һава – тәнгә дәва.
Тән дәвасы сәламәтлек,
Сәламәт яшәп була.

Саф һавада кар көрәсәң,
Юллар ачылып китә.
Алай гына да түгел,
Күңел яктырып китә.

Саф һавада җиләк җыйсаң,
Табын ямьләнеп китә.
Иелеп-бөгелеп җиләк җыеп,
Билләр нечкәреп китә.

Саф һавада чаңгы шусаң,
Арыган башлар ял ала.
Кызу-кызу шуып барсаң
Тәннәр язылып кала.

Саф һавада тик йөрү дә –
Үзе бер шифа, диләр.
Сәламәт булыйм дисәң,
Көн дә сикер һәм йөгер.

Юкка гына әйтмиләр бит,
Саф һава – тәнгә дәва.
Бары шушыларны эшләп,
Сәламәт яшәп була.

# 📖 19-25 яшьлекләр

**Бәһаветдинова Зөһрә Илгизәр кызы, 21 яшь**
*Җитәкчесе: Бәһаветдинова Флизә Кыяметдин кызы*

## ЙОЛДЫЗЫМ

Йолдызым,
Шундый якын, шундый ерак та син.
Балкыйсың бит әйтер сыман бер сүз.
Аңлый алмыйм, хәрефләр дә төзеп карыйм,
Кирәк, күрәсең, «тирән» күз.

Йолдызым,
Шундый якын, шундый ерак та син.
Сизәм кебек синең теләкне.
Тик инанмыйм дөреслегемә
Әйтче, ашыгырга кирәкме?..

Йолдызым,
Шундый якын, шундый ерак та син.
Бик мөлаем үзең күкләрдә.
Түземсезлек белән көтәм, беләсеңме,
Очрашулар аяз төннәрдә.

Йолдызым,
Шундый якын, шундый ерак та син.
Балкы гел дә шулай әкияти.
Күр әле үзен,
Ышандырып хыялыма
Юлымнан югалмый җемелди.
Шундый якын, шундый ерак син.

**Мөбәрәкшина Зилә Нияз кызы, 22 яшь**

*Җитәкчесе: Кузьмина Халисә Хатыйп кызы*

## ХАТЫН-КЫЗГА

Хатын кызның көчлелеге – гафу итә белүендә
Үлем-яшәү арасында
Калкып чыга белүендә.

Хатын-кызның көчлелеге – кабул итә белүендә
Сулмый, кипми шытып чыгып,
Сукмак яра белүендә.

Хатын-кызның көчлелеге – елмая белүендә.
Шушы көләч йөзе белән
Шатлана белүендә.

Хатын-кызның көчлегеге – сабыр итә белүендә.
Язмыш ачы җил җибәрсә,
Упкын, сулар, таулар аша
Исән калып, горур басып…
Түзә ала белүендә.

## Миңнуллина Эльвина Марат кызы, 22 яшь

***

Меңәрләгән кеше эзли, көтә…
Ә мин ялгыш кына табылдым.
Хәтер көндәлеген утка ягып
Әсир булдым аңа, табындым.
Бер кысырын җиһан галәм ача.
Батырмый су аны, яндырмый ут та.
Ә ул миңа оҗмах бүләк итте, шуның белән бергә…
Тәмугъ та.

## Мөхәммәтдинова Эльгина Илсур кызы, 20 яшь

***

Диңгез белән күк тоташканда,
Җәйнең урталарында
Безнең күзләр тоташты
Йөрәкләр дә чуалды.
Җәйнең жиләклегендә
Кабат чыктың каршыма
Кулларга куллар биреп
Каенлыкта серләштек
Шуннан бирле син янымда
Минем өчен янасың.
Җәйнең серле таңында
Кочагыңа аласың.

**Рәхимҗанов Рамазан Рәфис улы, 21 яшь**

## ДУС

Дус, имештер, чын булалмый,
Шуның бар да сәбәбе
Ә миндә алар күп түгел,
Бер булса да, иң шәбе.

Авырда гына килми ул,
Көне-төне элемтә.
Шаян сүзен кыстырып та,
Елмаюны ул көтә.

Кирәккә генә кулланып
Чын дуслыкны югалтмас,
Үлемгә кадәр җитсә дә,
Ул сине ташлап калмас.

Ул синнән дә акыллыдыр
Өйрәнерсең дә үзең,
Аннары ул да көлердер
Аста калдырмас сүзен.

Ходай биргән сәламәтлек
Туздыру өчен түгел,
Янәшәдә шәп дус торса,
Шулар өчен ач күңел.

**Камаев Ринат Азат улы, 20 яшь**

## БЫЛ-БЫЛ

Рэп укый был-был
Тырышып, көчәнеп,
Төймә кебек тезеп сүзләрен.
Сайрар иде,
Ләкин хәзер «модно» түгел икән
Өздерә-өздерә җырлап йөргәнең.

Рэп укый был-был,
Сүзен сүзгә кушып,
Рифма белән уйный бик җәһәт!
Әй, малай, тырышканын күрсәң,
Шаклар катыр иде әбекәйләр,
Ялгыш кына ишетсә.

Рэп укый был-был,
Яшьләр өчен укый,
Яңа буын өчен кайгыра.
Булган моңын сала ул шигырь юлларына,
Сала үзе язган битның ритмына.

Рэп укый был-был
Әби-чәби өчен түгел,
Юкла, «молодежь» өчен сызгыра!
Нурминскийдан үрнәк ала был-был,
«Алтан»нардан илһам ул ала.

Рэп укый был-был,
Сезгә ничектер,
Миңа ошый, фикере – актуаль.
Тормыш турында сайрый
Яшьләр аңласын дип,
Асылында Тукай язган сүзләр,
Шакировлар сузган көйләр булса да.

**Фарваева Гүзәл Венир кызы, 19 яшь**

*Җитәкчесе: Фарваева Резеда Әнвәр кызы*

## ӘНИЕМ

Сине шулай яратканга, сүзләр җитми,
Килә әйтәсе…
Биекләргә килә күтәрәсе,
Бар дөньяны бүләк итәсе.
Шундый назлы, йомшак кулларыңда
Иркәлисең безне, сөясең.
Кирәк чакта безне орышасың,
Әйе, чамасын да аның беләсең.
Матур да син, шундый ягымлы син,
Кояшка тиң синең карашың.
Алларыңа ятып, башны куйсак,
Җилләр кебек назлап аласың.
Якын кешем, иң-иң якын кешем,
Йолдызларны килә сиңа аласым.
Ниләр генә эшләсәм дә, әни,
Бик аз булыр аның барысы.
Әни! Синең йөрәк җылың белән,
Алга таба килә атлыйсы.
Син бит, әни – минем ышанычым
Йолдыздай, син, күктә балкыйсың.
Аяктан екса тормыш,
Чәчләремнән минем сыйпыйсың,
Бар җаныңны, киңәшләрең биреп
Кулдан тотып яннан атлыйсың.
Мең рәхмәтле сиңа гомер буе, әни.
Барысы өчен чиксез рәхмәтле.
Булганыңа рәхмәт синең, әни,
Шундый бөек, олы йөрәкле.

## Хәкимуллина Альмира Алмаз кызы, 21 яшь

***

Бүген, кичә, иртәгә
Мәгънә эзлим сүзләрдә,
Сере ябык кешегә
Саклана тик Күкләрдә

Бүген – сайлау вакыты
Бас аякка, тик торма,
Оныт кичә булганын
Киләчәк сере шунда!

Иртәгә ни була ул?
Бармы соң мәгънәсе?
Кешегә бирелмәгән шул
Гомер азагын беләсе.

**Халикова Энҗе Илнур кызы, 20 яшь.**

***

Саф мәхәббәтен көтә.
Оча күңелем еракларга
Әйтерсең лә ул – бер кош,
Сылу егет миңа эндәшә:
– Күктә очма җиргә төш…

Хыялым минем кошка охшаган
Теләми җиргә төшәргә…
Кошлар да бит җиргә төшә
Нигә миңа төшмәскә ?

Юк, һаман алга ыргыла ул…
Төрле планнар кора,
Саф күңелле чын кеше бул
Бәхет менә шуннан тора.

Шундый матур уйлар белән
Хыялым җиргә төште
Хыялымдагы сылу егет
Кинәт исемә төште.

Мин хыялланып очканда,
Ул башканы инде тапкан.
Саф булмаган мәхәббәте
Аны бик тиз югалткан…

Үкенә егет бик үкенә…
Хыялый кыздан гафу үтенә.
Акыллы кыз гафу итми,
Чын саф мәхәббәтен көтә.

**Хафизова Рәсилә Динарт кызы, 19 яшь**

## КҮЗЛЕГЕМНЕ САЛДЫМ

Күзлегеңне саласың да,
Карыйсың бу дөньяга.
Ачык түгел йөзләр янда,
Баралар каядыр алга.
Метро, автобус, машина –
Кеше тула, ашыга.
Кемнең кем икәнен белми,
Телефоны – каршында.
Күзлегеңне саласың да,
Бозык дөнья күрәсең.
Төсләр аша аерасың,
Йөз-чыраен белмәссең.
…
Күзлегеңне киясең дә,
Бар да ачык, сүрәтле.
Хисләр тышка ыргылмыйлар,
Урынында, күр әле.

**Алинә Хәбибуллина, 19 яшь**
*Җитәкчесе: Хәбибуллина Сөмбел Габдулла кызы*

## ҮЗЕБЕЗНЕ ҖУЯРБЫЗ

Арадагы чакрымнарны без әле юк итәрбез,
Картада буялган җиргә бер мәл барып җитәрбез.
Зәмһәрир суыкта дүрт йөз аерылуны җиңәрбез.
Без кышкы җилдән кызарган йөзләр белән чибәрбез.
Бәхет белән кисешүен телим һәркөн юлымның.
Шимбә көнне син миндә бул, ә мин синдә булырмын.
«Юләр», – диеп көлүләргә, үртәүләргә чыдарбыз.
Телефонның будкасына кереп , җылынып чыгарбыз.
Атылган йолдызларны без кесәләргә җыярбыз.
Бар дөньяга гашыйк булып, үзебезне җуярбыз.
Онытылып, урамнарның кирәклесен үтәрбез.
Кинога кереп, җылыга изрәп йоклап китәрбез.
Бәхеттән яки башыбыз, йә Җир шары әйләнер.
Тартылуга түзә алмый, күңелләр нык бәйләнер.
Елармынмы, аңлагач та иртән сигез тулуын,
Бу көтелгән очрашуның төштә генә булуын?

Ела, дустым, күз яшьләрен кояшка ук чөярбез.
Мәхәббәтле күзләр белән без барыбер чибәрбез.

**Хуҗина Зәринә Рамил кызы, 20 яшь**
*Җитәкчесе: Хуҗина Гөлназ Рәфис кызы*


## СИНЛЕ КИЛӘЧӘК

Бармакларың әкрен генә
Урап уза битемнән.
Әгәр тисә иренемә,
Калтырана бөтен тән.
Ә ул таный кулларыңны,
Кабул итмәс башкасын.
Нәфис тәннең җылылыгын
Синең куллар сакласын.
Тәнем тоялмый башласа,
Сине оныта калса,
Берүк, бәгърем, борчылма,
Калбем бар ич, ләбаса.
Бер елмаеп карасаң да,
Шунда ук сизә йөрәк.
Ешлыгын арттырып куя,
Әйтә ул: «Тик син кирәк».
Тавышыңа да күнеккән,
Әйтерсең, Моцарт көе.
Ошатмас калбем башкасын,
Синле җир – аның өе.
Әгәр бер мәл йөрәкне дә
Юк итсәләр галәмдә,
Сындырсалар, таптасалар,
Берүк, бәгърем, рәнҗемә.
Сөякләрем нык бит минем.
Алар исән мәңгегә.
Синекен дә яттан белә,
Тик аларга берегә.

Тартылу көче бар икән,
Физика шулай диде.
Безнең сөякләр хакында
Ник язмагандыр инде?

Кайда гына булсак та без,
Юллар киселмәячәк,
Минем аша тапшырыла
Ходай язган киләчәк.

# Чәчмә әсәр



# 12-14 яшьлекләр

**Галиева Әдилә Мөнир кызы, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Гарипова Наилә Габдрәшит кызы*

## КОШЧЫКЛАР «ҮСТЕРДЕМ»

Узган елның май аенда утынлыкта чиелдаган тавышлар ишетеп сагаеп калдым. Карасам, кечкенә генә ояда сап-сары томшыкларын киереп ачкан кош балалары! Алар шундый кечкенәләр, үсеп, очып китәселәренә күңел ышанмый хәтта. Фотога төшереп алыйм әле дисәм, шул арада ике сиртмәкойрык баш өстемдә әйләнеп оча башлады. «Ә-ә, сезнекеләрмени болар? Китәм, китәм, хәзер, фотога төшереп алыйм да», – дип сөйләнә-сөйләнә, оялы агач кисәген кире урынына куйдым.

Бер атна әти-әниле кошларны күзәттем. Башта оя янына әти кош килеп куна, тирә-якны күзәтә һәм, үзенчә тавыш чыгарып, әни кошны чакырып китерә. Әнкә кош авызындагы җимне балаларына ашатканнан соң, икәүләшеп очып китәләр. Алар киткәч, хәвефләнеп мин дә ояны күзлим – берәр усал мәче килеп алып китмәгәе, дим. Аллага шөкер, андый аяныч хәл булмады тагын. Әллә күрми калдым, әллә бу чыннан да шулай, әти кош бер генә тапкыр да җим алып килеп ашатмады. Ә менә сакчы ролен бик шәп башкарды. Әни кошның җитезлегенә хәйран калырлык, кай арада табып өлгерә диген! Аналык инстинкты кошларда да бар икән. Иртәдән кичкә кадәрле җим эзләп йөргән әни кошны кызганып без дә ярдәм итештек. Төрле «тәмлүшкә»ләр белән сыйларга тырыштык. Әмма әнкә кошның аларга бик исе китмәде, сайлап кына ташыды ул безнең сыйны балаларына. Иң кызыгы – ул нәни кошчыклар ничек шулай бөтенесе бергә тигез итеп ачып куя икән сары томшыкларын?

Өч атна дигәндә, кошчыклар ояны бушаттылар. Әти-әниле кошлар аларның очарга өйрәнүләрен читтән генә күзәтеп тордылар. «Менә болай итеп очалар аны» дигәндәй, очып та күрсәттеләр. Бары тик берсе генә очарга авырлык белән өйрәнде. Без аңарга ярдәм итәргә тырышып мәш килдек. Ниятебезне дөрес аңламадылармы,

баш очына дистәләгән сиртмәкойрык җыйналды – карале син боларны! Без кошчыкны тынычлыкта калдырып, өйгә кереп киттек. Иртән чыкканда, әти-әниле сиртмәкойрыклар да, нәни кошчык та юк иде инде. Мәчегә ризык булмагандыр, яклаучылары әнә никадәр иде бит, дип юаттык үзебезне.

Карале син, кошлар бер-берләренә ярдәм итә икән бит! Ә без? Безгә акыл, фикерләү сәләте бирелгән, әмма бер-береңә ярдәм итешү юк. Берәрсенә авырлык килсә, читтән генә күзәтеп, куанып торабыз, шулай бит? Авырганын ишетсәк – «Шул кирәк!», нидер булганын ишетсәк – «Әйбәт булган!» – дибез. Матур сүз, изге теләк белән ярдәм кулы сузарга кирәк бит! Бүген – ул, ә иртәгә үзебез шул кеше хәлендә калырга мөмкинбез...

**Гәрәева Чулпан Рәфыйкъ кызы, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Төхвәтуллина Резедә Фарис кызы*

# ЧИШМӘ ТУРЫНДА ХӘТИРӘ

Көмеш чишмәдә кояшның нурлары вак-вак тәңкәләргә аерылып күзләрне кызыктырып ялтырыйлар. Шул вак, кечкенә «тәңкә нурларны» тотыйм дип, кулны суга тыгуым була – кояш гүя мине үртәгәндәй, ул тәңкәләрне башка җиргә күчерә. Инде аннан да «шук» тәңкәләрне тотыйм дип үреләм, алар тагын башка җирдә пәйда була да куя! Чишмәнең минем белән үртәп уйнавыдыр инде бу! Әй чишмәм, саф сулы чишмәм! Синең көмеш сулы, шат булып агуың мине сокландыра, сиңа рәхмәт кенә укый . Бу сихәтле суыңны авыз итеп кем генә сусавын басмагандыр.

Хәтерлисеңме, моннан биш-алты еллар элек синең хәлләрең бик аяныч иде. Мин әле ул чагында кечкенә бала, сиңа ярдәм итәрлек хәлдә түгел идем. Син, яныңа килгән саен, моңсуланып, гүя ярдәм сорап ага идең. Тирә- ягыңны вак таллар, чүп- чар басып киткән иде. Инде кай заманнарда ук куелган улагың да черегән, хәтта ярылган да иде. Моны күреп минем (әле кечкенә генә кызчыкның!) йөрәгем әрни иде.

Менә бервакыт иптәш кызларымнан уйнап кайтып килә идем, берсе синең яныңа ук тирес чүмәләсе өеп киткәнен күрдем. Күрдем дә, без кешеләр явыз шул, табигатьнең торкасы булган чишмәбезне дә саклый алмыйбыз бит, дия-дия синең агымсу юлыңны чүп-чардан арындыра, чистарта башладым. Юк шул, бу нәни куллар әллә ни майтара алмады. Аннары көчем дә шулкадәр генә!

Өйгә кайткач әтием:

– Кызым, нишләдең, кайда болай пычрандың? – диде. Ә мин бар җыелган ачуымнан, шул чишмәгә булыша алмаган гарьлегемнән кычкырып елап җибәрдем:

– Әти, чишмәне, чишмәне бүлгәннәр! – дидем тагын да ярсып.

– Ничек бүлгәннәр?

– Аның ага торган юлына тирес түккәннәр!

Әтием йодрыкларын йомарлап, тешләрен кыса төшеп:

– Кайсы акылсызы су юлын бүлде икән? – диде. –Кызым, синең шул чишмә өчен өзгәләнүең чын кешечә, әйдә, кызым, иртәгә барып чишмәнең агымсу юлын, аның тирә- ягын чистартып кайтабыз, – диде.

Иртәгәсен без әтием белән чишмәнең тирәсен чүп-чардан, теге түгелгән тирестән чистарттык. Чистартып бетергәч әтием:

– Кызым бу бит данлыклы Дымбылат чишмәсе, бу чишмә турында авылдашыбыз Шәүкәт Галиев горурланып шигырь язган. Ул кыйблага карап ага. Шуңа күрә без аны мондый хәлдә калдырырга тиеш түгелбез, – диде.

Әтием әйтте дә, эшләде дә. Чишмәгә авыл агайлары җыелышып бура бурап куйдылар, улагын тимердән озын итеп ясап, тирәсен кечкенә өй итеп тотып алдылар. Бизәкле тәрәзәләр уеп, матур челтәрләр элделәр. Ә шул өйчек эчендә имәннән идәннәр дә куйгач, ул Дымбылат тагын да ямьләнде.

Инде беркөн иртән әти белән әнинең ниндидер бәйрәм турында сөйләшкәннәрен ишетәм:

Бәйрәмне Әлфия алып бара, самавырлар куеп чәйләр эчәрбез, уеннар оештырырбыз, – диләр. Ә мин тиз генә төшенә алмыйча:

– Нинди бәйрәм? – дип сорадым. Әнием:

– Дымбылат чишмәсе бәйрәме, кызым, – диде.

...Бик күңелле, шигырьле, җырлы бәйрәм булды ул. Бөтен авыл халкы җыелган иде. Кайсы Дымбылатка бүләккә чүмеч, тастымал, сөлгеләр алып килгән. Барысы да әтиемне мактады, аңа рәхмәт әйтте.

Бүген әтием безнең арада юк инде. Бар кеше дә ул чишмәне «Дымбылат чишмәсе» дип атаса, ә мин эчемнән генә «Рәфыйкъ чишмәсе», әтием җан өргән чишмә бит бу, дим.

Бу бер чишмә язмышы гына. Безнең Апас районы Олы Бакырчы авылында шундый чишмәләр өчәү. Аларның да үз хатирәләре, истәлекләре бар. Хәзерге вакытта алар да бик яхшы хәлдә. Мәхмүт, Кара кизләү һәм Дымбылат чишмәләренең сихәтле, көмеш сулары мәңге саекмасын!

**Кәримов Гайсә Госман улы, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Фадеева Гүзәл Хәмзә кызы*

## УМАРТАЧЫ МАЛАЙ

Яратам да инде җәйге иртәне!

Тагын бер яңа көннең тууын күзәтү бик күңелле. Җәен иртә яктыра башлый. Беренче кояш нурлары акрын гына йоклаган җир өстенә сибеләләр. Алар барлыкка килү белән, елга өстендәге томан да ашыкмыйча гына күтәрелә башлый, чирәм өсләрендә миллионлаган утлар кабына. Ләкин җир өстендәге чык озак яктыртмый шул. Һәр минут саен кими бара. Тирә-якка төрле үләннәрнең татлы исе тарала. Һава саф һәм хуш исле.

Иртәнге якта бик тыныч. Әйтерсең лә, җир, ниндидер могҗиза көткәндәй, сулыш та алмыйча тын калган. Менә инде кошларның күңелле чыркылдавы ишетелә, кайдадыр сандугач сайрый. Кошлар да яңа көнне шатланып каршы ала.

Иртәнге тынлык юкка чыга башлый. Тирә-юньдә барысы да яңа тавышлар белән тулылана. Көн җылына. Инде иртәдән үк эссе булачагы аңлашыла.

Мин кечкенәдән иртә торам. Шулай килеп чыга инде: арылып тәмләп тә йоклана, йокы туеп, иртә дә уянылына. Рәхәт бит ул кояш белән бергә уяну! Башта бераз урын өстендә ятасың, бер күзеңне ачасың һәм тәрәзәгә карыйсың. Ә тәрәзә кояш нуры белән капланган. Анда якты күкнең бер өлеше һәм зифа агачларның яшел яфраклары күренә. Шунда ук һава торышының чын-чынлап җәйге булуына сөенәсең. Стеналар буйлап кояш куяннары йөгерә. Аларны күрәсең дә елмаясың. Шунда ук күңелгә рәхәт була!

Менә бүген дә, гадәттәгечә, мин иртә тордым. Бөтен өйгә таралган яңа пешкән коймак исе мине аш бүлмәсенә җәлеп итте. Әни иртәнге чәй табынын тизрәк өлгертергә тырышып, йөгерә-йөгерә ризык әзерли, чөнки әтинең, көн ккызулана башлаганчы, умарталыкка барып җитәсе бар. Ә әбием тәрәзә төбендә чәчәк атып утырган үзенең яраткан гөлләренә су сибеп йөри.

– Эй, улым, бигрәк иртә торасың инде! Җәйге елларында да рәхәтләнеп йокламыйсың! – дип, әбием мине каршы алды.

– Әби, минем йокы туйды инде! Минем дә әти белән умарталыкка барасым бар.

– Әйе, улым, бал кортларының, ояларыннан аерылып чыгып, очып китә торган чаклары. Умарталыкта хәзер синең ярдәмең бик кирәк, – дип, әти дә безнең сөйләшүгә кушылды.

– Барам, әти, барам! Умарталарны карау миңа бик ошый. Синнән мин инде күп нәрсәләргә өйрәндем.

Иртәнге чәйне эчеп, озын-озакка сузмыйча, без юлга кузгалдык. Кояш әле югары күтәрелеп өлгермәгән, шуңа да карамастан, көн кызуы инде сизелә иде.

– Әниең ясаган тәмле чәй тиз бетәр бүген, улым! – дип, әти дә көлеп куйды.

Безнең умарталык авылдан бары тик бер чакрым ераклыкта булган урман аланында урнашкан. Умарталыкта утыз ике баш умарта бар. Минем бабам һәвәскәр умартачы булган. Бабамның умартачы булып китүе дә бик кызыклы. Ул турыда миңа әбием сөйләгән иде.

Алар гаилә корып җибәргән елны, бүгенге кебек җәй башының кызу бер көнендә, аларның ишегалдында үсеп утырган алмагачның ботагына каяндыр умарта күче килеп сырган булган. Моны күреп, бабам югары очта яшәүче умартачы Мансур абыйга дәшкән. Ул, үз чиратында, агачка сырган кортларны махсус савытка әкрен генә җыеп алган. Шул арада умартачы абзый, читтән генә эш барышын күзәтеп торган бабама, бал кортларының мавыктыргыч яшәү рәвеше турында сөйләп өлгергән.

Галимҗан бабамның күзләрендә нык кызыксыну уянганын күргәч, Мансур абый җыеп алган бал кортларын аңа калдырырга уйлый. Шул ук көнне, балта эшләренә оста булган бабам, тиз генә умарта оясы ясап куя. Кич җиткәч, умартачы абзый ярдәме белән, җыеп алынган умарта күчен үзе ясаган ояга урнаштыра. Бөтен күңелен биреп, шул кортларны тәрбияләүгә алына. Шул көннән башлап бабамның умартачылык эшчәнлеге башлана. Үзенең тырышлыгы һәм осталыгы ярдәмендә Галимҗан бабам, чын мәгънәсендә, умартачыга әверелә. Бөтен гомерен шул эшкә багышлый. Берничә дистә еллар буена бабам үзенең умарталыгында җитештерелгән тәмле, шифалы балы белән якын-тирә авылларда яшәүче кешеләрне тәэмин итеп торган.

Үз эшенең дәвамчысы булыр дип, бабаем бу һөнәргә әтиемне дә өйрәтеп калдырган. Кызганычка каршы, бабам якты дөньядан иртәрәк бакыйлыкка күчкән. Шуннан соң әлеге эшне әтием тулысынча үз өстенә алган.

Буыннан-буынга күчеп килүче һөнәрне миңа да өйрәтүне әти үзенең бурычы дип саный. Бал кортларын хәстәрләү һәм үрчетү эшендә булган бөтен нечкәлекләрне миңа эзлекле рәвештә өйрәтергә тырыша…

Эх, җәйге урман! Ул сер һәм могҗизалар белән тулы. Биредә үзенчәлекле атмосфера хөкем сөрә. Анда тормыш үз чираты белән уза, һәм бу режимны бозу берәүгә дә рөхсәт ителми.

Урманга килү белән сулавы җиңелрәк булып тоела, кәефләр яхшырып китә. Эссе көнне анда салкынча. Биек нарат һәм чыршылар күккә үреләә. Баш өстендә яшел түшәм дигән тәэсир барлыкка килә. Һавага яфраклар, үләннәр исе таралган. Нинди генә кошларның сайравы ишетелми монда! Матур тукраннар төрле бөҗәкләрдән агачларны дәвалыйлар. Урманда яшәүче хайваннарга кунаклар килүен хәбәр иткәндәй, бер минутка да тынмыйча, саескан кычкыра. Ояларда нәни кош балалары чыркылдый.

Умарталык өстендәге бал кортларының гөжләве җәйге урман табигатенә өстәмә бер сихри ямь бирә. Алар шундый тавыш чыгарып безне каршы алалардыр төсле тоела миңа. Әйе, шулай булырга да мөмкин, чөнки көн дәвамында безнең, җиң сызганып, алар белән бергәләп эшлисе эшләребез күп бит.

Шушы матурлыкка сокланып торганда, умартачы өенең ишекләрен ачып өлгергән әтием миңа дәште:

– Улым, Кәрим, әйдә өйдән алып килгән әйберләрне тиз генә кертеп куябыз да, битлекләрне киеп, эшкә керешәбез.

– Киләм, әти!

– Көн кызулана төшкәч, аерылып чыгарга җыенган оялар кузгалырга мөмкин. Соңга калмыйк тагын!

Кичтән хәстәрләп калдырган битлекләрне кидек тә, әти белән умарта ояларына таба юнәлдек. Без килгәндә беренче кояш нурлары белән уянып чыккан бал кортлары иртәнге чәчәк серкәләрен, ашыга-ашыга, үзләренең ояларына алып кайталар иде.

Әти, озак уйлап тормыйча, беренче умарта оясының капкачын ачты. Бал кортларын бераз тынычландыру өчен төтен җибәрде. Кәрәзләр өстенә җылылык өчен куелган мендәрчекләрне алып, махсус эшләнгән элмәкле тимер ярдәмендә салмак кына кәрәзләрне чыгара башлады. Ул арада мин усалланып кәрәзләр өстенә күтәрелә башлаган бал кортларына, әкрен генә төтен җибәреп, аларны нык тузынып китүдән тыеп тордым. Әти кулына тоткан кәрәзләрне бик сак кына әйләндергәли, чөнки бал кортлары кискен хәрәкәт ясаганны бер дә яратмыйлар.

Оя эчендә бары да яхшы булса, әтинең йөзләре нурланып китә:

– Болары яхшы эшләгән, улым! Ана корт йомыркаларын тигез итеп салган. Бу оя аерылырга уйламый. Кәрәз читләрендә яңа төзелгән ана казаннары күренми, димәк, эшче кортлар ана кортның эшләвеннән канәгать.

– Кәрәзләрнең барсын да карап чыгабызмы соң, әти?

– Юк, улым. Боларын артык борчымыйк. Монда барысы да тәртиптә! Ябып куябыз да, икенчесенә күчәбез.

Шушы рәвешле, без беренче рәттә урнашкан ояларны күзәтеп чыккач, әти миңа карап:

– Кәрим, әйдә аз гына ял итеп алабыз, улым. Чәй дә эчәсең килгәндер. Көн бик кыздыра бит, – диде.

Чыннан да, үземнең дә тамак бик кипкән иде. Шунлыктан мин әтигә каршы килмәдем. Без акрын гына умарта өенә таба юнәлдек. Әни тәмләп ясап җибәргән чәйне эчеп сусауларны бастык, аның коймаклары белән тамак ялгап алдык. Башлаган эшне дәвам итербез дип уйлап торганда, умарталыкның арткы рәтендәге кырый оядан бик күпләп кортлар күтәрелә башлаганын күрдек.

– Тизрәк барыйк, улым! Анда кортлар аерылып чыгарга уйлыйлар ахрысы! – диде әти.

Ике дә уйлап тормадык, битлекләребезне кидек тә, шунда йөгердек. Барсак, чынлап та, оядагы кортларның күбесе, бер күч булып, өскә күтәрелә башлаган. Әти әлеге хәлгә күз салды да, миңа карап:

– Тиз генә сыргакны алып кил, Кәрим! Мин оядан ана кортның чыкканын күзәтеп торам. Аны тотып кала алсак, чыккан кортлар

читкә очмаячаклар. Ничек тә аларны үзебездә калдырырга кирәк! – диде.

Мин тиз генә умарта өенә терәп куелган сыргакны алып килдем. Юкә агачыннан эшләнгән озын сабыннан ике куллап тотып өскә күтәреп тордым. Кортлар сыргакка эленгән кәрәз исе килеп торган чүпрәккә сыра башладылар. Ул арада кортларның гөжләгән тавышы тагы да көчәйде. Минем битлек тышлыгында арлы-бирле йөрүче кортлар саны да артты.

Мондый очрак безнең умарталыкта беренчесе түгел. Шулай да андый минутларда күңел түрендә ниндидер бер куркулык барлыкка килә. Ләкин мин аны әтигә сиздермәскә тырышам. Ни әйтсәң дә, мин бит умартачылар нәселеннән! Аннары инде өч ел әтиемә булышып азмы-күпме тәҗрибә дә тупладым. Беренче тапкыр әтиемә ияреп монда килгәндә миңа тугыз гына яшь иде. Кечкенәдән үк мин кортлар янында эшләргә, аларның бал җитештергәнен күзәтеп йөрергә хыялландым. Бәләкәй булганлыктан мин әтинең эшләгәнен читтән генә күзәтә идем. Умартачы хезмәте бик авыр һәм күп сабырлык, тырышлык таләп итә торган җаваплы эш. Шуңа да карамастан бу һөнәр миңа бик ошый, чөнки ул мине сихри көчкә ия булган табигатькә якынайта. Ә бу исә миңа бер төрле җан рәхәтлеге бирә.

– Менә ана корт та чыкты, улым! Өлгердек болай булгач! – дип, әти сөенеп куйды.

Ул шулай дигәч, оя каршына, кортларның чыгу юлы уңаена көйләп куелган киң тактага мин дә күз төшердем.

– Менә, Кәрим, ана корт шушы була инде, – дип, такта өстендә мыжлап торган эшче кортлар арасыннан ашыга-ашыга чыгып килүче кыска канатлы, озынча гәүдәле һәм зурлыгы буенча башкалардан аерылып торган ана кортка төртеп күрсәтте әти.

Шуннан әтием аны сак кына алып махсус бәләкәй читлеккә урнаштырды. Без сыргакка җыела башлаган кортларның бер күч булып җыелып беткәнен көтеп тордык. Янәшәләрендә ана корт булмагач, бал кортлары беркая да очып китмиләр.

Кичкә таба бу кортларны әтием яңадан ояга урнаштырды һәм ана кортны алар янына җибәрде. Мондый хәлдән соң умарта кортлары аерылып чыгып китү халәтеннән кире кайталар.

Шулай мәшәкатьләнеп көннең узганын сизми дә калдык. Көн дәвамында эшли торгач арылды, тамак та ачты. Без, әйберләребезне җыеп, әкрен генә кайтыр юлга кузгалдык.

Капка төбенә кайтып туктаганда инде көннең кызуы шактый сүрелгән иде. Безне ишегалдында тавык-чебешләрне барлап йөрүче әбием каршы алды. Бүген умарталыкта бал кортларын үзебездә алып кала алу сөенече эчемә сыймый иде. Ул хәбәр белән тизрәк бүлешәсем килде.

– Әби, әби, бүген кортлар аерылып чыгарга уйлаганнар иде! Без аларны очырмадык, алып кала алдык! – дип, әбигә әйткәнемне сизми дә калдым.

– И-и, улым! Һәр тырышлыкның һәрвакытта үзенең уңай нәтиҗәсе була! Бу тормышта гел шулай тырышып яшәргә кирәк! Тырышмыйча уңышка ирешеп булмый шул, улым! – дип, әбием мине җилкәмнән сөеп куйды.

Әбиемнең бу сүзләреннән соң арганлыгым кимегән төсле булды. Чыннан да, балачактан яраткан минем бу һөнәрем киләчәк тормышымда да якты маяк булып үз урынын алыр дигән фикер туды. Шул турыда уйлый-уйлый, мин бу сөенечемне әниемә дә җиткерим дип, ашыга-ашыга, өйгә кереп киттем.

**Мирхәйдәрова Азалия, 14 яшь**

# БӘХЕТ

Төшендә ул әбисен күрде. Әбисе аңа, елмаеп, нәрсәдер әйтте. «Нәрсә әйтте соң әле әби», – дип исенә төшерергә тырышты Нәфисә. Иренең янында юклыгын күреп, чәй эчәдер дип уйлады ул.

Торып киенә башлады. Көзгегә күз салды. Битендәге җөйгә озак кына карап торды. Элек Нәфисә сәгатьләр буе, үз-үзенә сокланып, көзге каршында басып тора иде. Ә хәзер йөзендә, хуҗасының соклануыннан мәхрүм итеп, тимер рәшәткә төсле җөй ята.

Бүген ире белән УЗИга барачаклары исенә төшкәч, Нәфисәнең күңелен шатлык биләп алды, ул, иркәләп эчен сыйпап куйды. Юынгач, аш бүлмәсенә керде, ире юк иде, аның кайдалыгын уйлый-уйлый чәй әзерләде. Ишек ачылганы ишетелде. Менә ире күренде. Аның кулында бик матур чәчәк бәйләме иде. «Хәерле иртә, әнисе», – дип, ул Нәфисәгә чәчәк бәйләме сузды һәм аны кочаклап алды. Фирдүс хатынын бик ярата, аны бәхетле итү өчен, барын да эшли иде. Чәй эчкәч, алар хастаханәгә киттеләр. Иренең янында булуы Нәфисәгә рәхәтлек бирә иде. Чиратлары җитеп, алар кабинетка керделәр. Табибә Нәфисәне кабул итә башлады. Экранда сабый күренде. Табибә аның гәүдәсенең өлешләрен үлчи башлады, бераздан, экраннан күзен ала алмый торган Фирдүскә карап:

– Сезнең кызыгыз булачак, – диде елмаеп. – Әнисенә охшаса, чибәрләрнең-чибәре булыр.

– Иң мөһиме: сау-сәламәт, бәхетле булсын, – диде Фирдүс белән Нәфисә бертавыштан. Табибә аларга карап, елмаеп куйды. Кинәт Нәфисәгә эсселе-суыклы булып китте. Күз алдыннан бүгенге төше үтеп китте, әбисе әйткән сүзләр исенә төште: «Бәхетле бул, балам!»

УЗИ үткәч, алар кайтырга чыктылар. Алар икесе дә бәхетле иде. Нәфисә эченнән: «Бәхет өчен матурлык түгел, мәхәббәт, бер-береңне хөрмәт итү кирәк», – дип уйлады. Бу сүзләрнең хаклыгын ул үз тормышы белән раслады.

Нәфисә бик матур бала булып туды. Үскән саен, аның гүзәллеге артты гына. Әти-әнисе чиксез сокланды, горурланып туя алмады

аның белән. Нәфисә үзе дә үзен бик ярата иде. Бу ярату аның акылын томалады, күкләргә күтәрде. Әбисе аңа һәрвакыт: «Матурлыгың белән масайма, кызым. Артык кычкырып торган матурлык бәхетсезлек китерә», – дия иде. Нәфисә әбисенең бу сүзләреннән көлә генә, эченнән: «Әби үзе карт, ямьсез буганга, миннән көнләшә», – дип уйлый иде. Җиткән кыз булгач, ул барлык авыл егетләрен диярлек йокыдан калдырды. Алар арасында ире Фирдүс тә бар иде. Ул Нәфисәләрнең күршесендә яши иде. Кечкенә чакта алар бергә уйнадылар, бергә балалар бакчасына йөрделәр. Үсә төшкәч, бергә мәктәпкә киттеләр. Нәфисә Фирдүскә күрше малай итеп кенә карый иде. Ул үзенең булачак тормыш иптәше итеп, бик бай һәм бик чибәр егетне күз алдына китерә иде. Ә Фирдүс бу үлчәмнәргә әз генә дә якын килми иде.

Мәктәпне бетереп, шәһәргә киткәч, Нәфисә Фирдүс исемле кеше барлыгын да онытты. Монда бөтенләй икенче дөнья иде. Нәфисәне чаялыктка, үткерлектә үзеннән калышмаган, әнәдән-җептән генә киенгән чибәр шәһәр егетләре әйләндереп алды. Ул алар арасыннан иң-иңен сайлап алды.

Беркөнне, шәһәр буйлап машинада йөргәндә, егете белән Нәфисә юл һәлакәтенә эләктеләр. Егете бик җәрәхәтләнмәгән булса да, Нәфисә бик нык имгәнде. Барыннан да бигрәк, йөзе танымаслык хәлгә килгән иде. Хастаханәдә яткан вакытта әти белән әнисе, әбисе аның кырыннан китмәделәр. Нәфисәнең авыр хәлдә булуын ишетеп, Фирдүс тә аның янына хәл белергә килде. Тик чибәр, бай егете генә күренмәде. Ә Нәфисә, аның килмәячәген сизсә дә, көтүен дәвам итте. Беркөнне, Фирдүс, тагын бер тапкыр килеп киткәч, Нәфисә әбисеннән:

–Әби, нигә минем егетем дә Фирдүс кебек хәлемне белергә килми икән? – дип сорады.

Әбисе төсе уңган моңсу күзләре белән оныгына карап:

Ярatса, килер иде, – диде.

Әбисенең бу сүзләре кызның йөрәгенә энә булып кадалды. Нәфисәнең күңеле бу сүзләр белән килешмәсә дә, акылы аның дөреслеген аңлады. «Ул, чыннан да, минем үземне түгел, ә матурлыгымны гына ярата иде бит. Аның килүе дә мин-минлегем

өчен генә кирәк бит. Мин үзем дә аны яратмыйм, аның чибәрлеген һәм байлыгын гына ярата идем бит», – дип уйлады ул.

Әкренләп Нәфисәнең күңелендә тынычлык урнаша башлады. Моңа Фирдүснең хәл белергә килеп йөрүләре дә ярдәм итте. Алар бик нык дуслашып киттеләр. Фирдүснең күз карашларыннан ук Нәфисәне элеккечә яратуы күренеп тора иде.

Ниһаять, Нәфисәнең җәрәхәтләре төзәлде, берничә җөй генә калды. Хастаханәдән чыккач та, ул Фирдүс белән аралашуын дәвам итте. Озакламый Фирдүс аңа тәкъдим ясады. Нәфисә инде үзенең матурлыгын югалтса да, тагын да кыйммәтлерәк байлык-гомерлек яр булдыруын аңлаган иде.

Алар өйләренә кайтып җиттеләр. Нәфисә машинадан төште, күккә карады. Көн ап-аяз. Кояш үзенең җылы нурлары белән адәм балаларының битен назлый иде.

– Аллаһ Тәгаләм, барчабызга бәхетләр насыйп ит, – дип пышылдады Нәфисә.

**Хафизова Алсу Марат кызы, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Хафизова Фәридә Зәки кызы*

## БӘЛӘКӘЧНЕҢ РӘХМӘТЕ

Җәйге кызу көннәрдә авылда әби белән бабай янында ятудан да рәхәт нәрсә юктыр! Көннең кичкә күчеп барган вакыты. Мин үземнең туганым белән велосипедта йөрергә чыктым. Без кибеттән кириешки сатып алдык та, клуб ишегалдына кереп, әнидән качып кына ашарга булдык. Ни өчен качыпмы? Әни шул кириешки, чипсы кебек ашамлыкларның зыяны турында гел сөйләп кенә тора. Кәефен төшерәсебез килмәде.

Беренче булып Самат күреп алды ул бәләкәй песи баласын. Без аның янына йөгердек. Ә ул качу турында уйламый да. Көчкә-көчкә генә атлап, безнең яныбызга килде. Без аны тоткач, куркып киттек. Ул бик нык калтырый иде. Әзрәк торгач, песи тынычланды. Без аның бик-бик ач икәнен аңлап алдык. Аны нык жәлләдек. Шундый матур, тәти, йомшак песине кем ташлый алсын инде? Бәхеткә каршы, без бит кибеттән кайтабыз. Песи баласына, кетчупка манып, бер кириешка бирдек. Ул әкрен генә башын күтәрде дә кетчупны ялады, бик ошатты булса кирәк. Без – Самат, мин, песи баласы – өчәүләп тәмләп кенә ашап бетердек шул «әни яратмый торган» ризыкны. Кечкенә генә кетчуп савытын песи алдына куйган идек, ул рәхәтләнеп ялый да башлады. Песиләрнең кетчуп яратканын күргәнем булмаганга, аны күзәтеп тору бик кызык булды. Песинең бите кып-кызыл. Ул ал теле белән яланып, битен чистартырга тырышты, ләкин килеп чыкмады. Ә иң кызыгы: ул инде без берничә минут элек күргән песигә тамчы да охшамаган иде.

Үзебезнең дә, песи баласының да эчәсе килгән иде. Мин тиз генә өйдән сөт алып чыктым. Сөтне салуым булды, песиебез үзенең нәзек ал теле белән, чопыр-чопыр китереп, эчә дә башлады. Ул шундый мәзәк, аңа ак мыек үскән, диярсең. Песинең мыекларын кулъяулык белән сөрттек. Уйлаштык та песи баласына Бәләкәч дип исем бирдек. Караңгы төшә башлады. Бәләкәч белән иртәгә күрешергә дип, саубуллаштык.

Икенче көнне ул шул ук урында безне көтеп торды. Бу юлы без аңа казылык һәм сөт алып чыктык. Бәләкәч тиз генә казылыкны

ашады, сөт эчте. Каян гына килеп чыкты соң бу яңгыр болыты. Песине күтәреп өйгә чаптык. Аны верандага алып кердек тә өстенә юрган яптык. Үзебез дә аның янында калдык. Яшен яшьнәгәч, барыбыз да юрган астына качтык…

Бер елдан соң, без аны тагын күрдек. Бәләкәч беркем янына да килмәде. Бары тик безнең яныбызга гына килде, чөнки ул безне таныды. Ул инде үзе әни булырга әзерләнә икән. Аның эчендә нәни генә йөрәк тибә. Ул ач булмаса да, без алып чыккан сөтне яратып эчте. Без бик нык шатландык.

**Әмир Шәрәфиев, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Билалова Резеда Рашат кызы*

# ХАТ

Егылып аягын сындырды Муса. Менә хәзер мәктәпкә дә бара алмыйча, өйдә утыра инде. Башка вакыт булса, укытучылар килер иде янына. Килә алмыйлар, каникулга киткән җирдән алар да өйләренә бикләнде. Кытайдан короновирус килгән, ди, ул йогышлы ди, борын-авыздан эчкә керә дә, каты авырыйсың, ди. Бөтен кешегә өйдә утырасы хәзер. Әнисе кафеда эшли иде, хәзер ул да эшкә бармыйча өйдә утыра. Ул да кибеткә ипи-сөткә, башка әйберләр алырга гына чыгып керә.

Ә урамда – яз. Матур инде ул яз! Чыпчыклар чыркылдый, сыерчыклар сайрый. Карлар эреп бетеп килә. Асфальт чиста. Башка чак булса, Муса малайлар белән велосипедын алып, урамга чыгып китәр иде. Айратлар, Азатлар, Егорлар – бергәләшеп велосипедта чабарлар иде. Тәрәзәдән карый, урамда беркем дә юк. Алар уйный торган җирне кызыл тасма белән бәйләп куйганнар. Күңелсез! Ярый әле өйдә телефоны бар. Ул дәресләр беткәч, Тик-токтан кызык-мызыклар карый, дусты Әмир белән уен уйный. Берзаман ул да туйдыра, бер аякка сикереп әнисе янына килә, аннан бергәләшеп шашка, өстәл уены уйнап алалар. Сыйныфташлары хәлен белергә дә килә алмыйлар, башта бер-ике тапкыр «Как дела?» – дип язып маташканнар иде, аннары оныттылар. Менә шуңа күңелсез Мусага. Аның урамда уйныйсы, сөйләшәсе килә. Сөйләшергә ярата ул. Тик телефонда утыручылар гына аның белән сөйләшергә бик ашкынып тормый.

Әнисе бүген кибеткә чыккан иде. Бер хат тотып кергән. Мусага дип язылган. Ул хатны тырышып-тырышып укырга тотынды. Ә укуы авыррак, ул татарча язылган иде. Бу алар кайчандыр бер өйдә яшәгән кечкенә Мәрьямнән булып чыкты. Ул Мусаның аягы сындырган икәнен әнисеннән белгән дә, хәлен белеп хат язган. «Ничек хәлләрең? Аягың авыртмыймы? Син ниләр белән шөгыльләнәсең? Әйдә миңа татарча шуларны яз», – дип сораган иде күршесе. Мусага кызык һәм күңелле булып китте. Бер аякка сикер-сикерә кәгазь, ручка алып килде, хат язарга утырды. «Привет, Марьям!» – дип

язды ул. Юк, привет русча була, татарча язарга кирәк, дип, привет сүзен сызып ташлап, «Сәлам!» – дип язып куйды. Хәлләрен татарча язу өчен аңа әле шактый тырышырга туры киләчәк иде. Ләкин ул күңелсезләнмәде, менә бит кечкенә дусты аны онытмаган. Ә татарча язарга өйрәнү Мусага тормышта бик кирәк булачак. Татар малае татарча белергә, татарча хат язарга тиеш ул!

# 15-18 яшьлекләр

**Абдрахманова Ләйсән Айрат кызы, 16 яшь**

*Җитәкчесе: Абрахманова Илсөяр Айрат кызы*

## ИМТИХАН

Бүген дә төнлә уяндым. Бу – хәзер минем өчен гадәти хәл инде. Як-ягыма карандым. Әле яктырмаган. Тирә-юньдә тынлык. Башкаларны уятмас өчен, аягыма да киеп тормыйча, тәрәзә буена килдем. Шулай йоклый алмаганда, еш кына тәрәзә каршына киләм мин...

Урамда да тып-тыныч. Эт өргән, машина йөргән тавышлар да юк. Табигатьтә давыл алдыннан була торган халәткә охшаган иде бу тынлык . Тик шулай да бу тынлык куркытмый, киресенчә, мин ниндидер күңел тынычлыгы, ләззәт кичерәм. Бүген артык тыныч иде шул... Хәтта сәер. Тик шулай да рәхәт. Бу рәхәтнең вакытлыча гына булуын да, моннан соң бүтән булмаячагын да аңлыйсың, әмма рәхәт! Бәлки, шушы хакыйкатькә төшенгәнгә күрә ләззәтледер дә ул!

Биек йортлар, бетмәс-төкәнмәс багана утлары арасыннан күкне, йолдызларны эзләп табу авыр иде. Күпме генә тырышсам да, бүген мин йолдызларны күрмәдем. Моңа әзрәк кәефем төшсә дә, күңелемә якын алмаска тырыштым....Бик озак эзләгәч кенә, күккә ашкан йортлар арасында каңгырап йөрүче тулы ай күренде. Йолдызлар эзләү белән мавыккангамы, мин аңа игътибар итмәгәнмен икән. Ә бит ул шундый тулы, шундый якты, шундый матур!!! Әмма ялгыз! Минем тулы айны быел беренче күрүем иде... Тулы ай күрү – бәхетсезлек, кәеф төшенкелеге дип саналганын белсәм дә, артыгын уйламаска тырыштым. Юк! Бүген бары да әйбәт булырга тиеш!..

Бүген имтихан! Менә ул – минем төнге йокымны урлаучы, мине тәмле төшләремнән аеручы. Юк, монда имтихан гына гаепле түгел. Дөресен генә әйткәндә, һәрвакыт шулай: нинди генә сынау булмасын – имтиханмы, контроль эшме, диктантмы – мин

тыныч кала алмый идем. Курку дип тә әйтеп булмый инде аны... Тик шулай да...

Әйе, бүген рус теленнән имтихан. ТЕЛДӘН! ОФЛАЙН! Унынчы февраль. Бу дата беркайчан да җитмәс кебек иде, дөресрәге, мин аның җитүен теләми идем. Юк, мин әзерләндем! Мин аңа бик күп әзерләндем. Әзерләндем генәме соң?! Башны бәрә-бәрә укыдым. Барысын да беләм, әмма барыбер үземдәге борчылу хисен тыя алмыйм. Шуңа күрә, белсәм дә, хәлдән тайганчы укый идем. Ничек борчылганымны, күпме яшь түккәнемне бары үзем генә беләм. Башкалар: «Ни булды?» – дип сорамасыннар өчен, елмаясым килмәсә дә елмаерга тырыша идем. Әти-әниләр: «Борчылма инде», – дигәч тә, «Юк ла, борчылмыйм, җиңел ич ул», – дип кенә әйтә идем...

Сәгать 4:50не күрсәтә. Тиздән бу төн дә узачак, таң атачак. Имтиханга берничә сәгать кенә калып бара – бераз йоклап алырга кирәк. «Бары да әйбәт булачак», – дидем дә мендәремә капланып яттым. Тик бу юлы еламадым. Шыңшып, башкаларны уятасым килми иде. Барысы да әйбәт булачак! Шулай дип ышандырырга тырыштым үземне...

Таң атты. Гадәттәгечә, әнием битемнән үбеп уятты. Мин кәеф булмавын белгертмәс өчен артыгын сөйләшмәдем, бары елмайдым гына. Ашыйсым да килмәде. Әнием, орышмасын өчен генә ашарга туры килде.

Кинәт кенә әниемнең: «Киткәндә, көзгегә карап елмай, кызым, ул да сиңа елмаер. Шул вакытта, көнең дә әйбәт үтәр», – дигән сүзләре исемә төште. Елмайдым. Хәтта көннең әйбәт үтәчәгенә ышанып та куйдым.

Мәктәпкә әтием машина белән илтеп куйды. Гел шулай, эшкә китәр алдыннан, ул мине мәктәпкә кертеп чыга. Машинадан төшкәндә дә, мәктәпкә кергәндә дә, бөтен кешегә елмайдым. Тик сыйныф бүлмәсенә кергәч, канатларым сынды: сыйныфташларым биремнәрнең нинди буласын кичтән үк белгәннәр икән, тик миңа гына әйтмәгәннәр. Алар текстны ятлаганнлар, монологны да өйләреннән үк төзеп килгәннәр иде. Йөземә борчылуымны чыгармаска тырышып: «Текстыгызны укып кына чыгыйм әле», – дип сорадым, тик арадан берсе дә үзенең текстын бирергә теләмәде.

Алай гынамы, Регина хәтта: «Булды инде, Ләйлә, мыжгыма әле», – дип кычкырып атты. Мин тораташ кебек катып калдым. Кемнәр белән укыйм мин?! Ә бит шушы сыйныфташларымның һәрберсе, нидер кирәк булган саен: «Ләйлә, булыш әле»,– диеп, миңа киләләр! Ә үзләре??? Әйе, мин аларның миңа чын дус булмауларын, көнләшүләрен күптән белә идем, тик сыйныфташ хакына булса да…Эх…

Мин аларда имтихан җаваплары булуын беркемгә дә әйтмәдем, «әләкче» дигән сүзләрен ишетәсем килмәде… Әлбәттә, алар имтихандагы биремнәрне әйбәт эшләделәр. Бик елмаеп, канәгать булып чыктылар. Әле җитмәсә: «Авыр иде. Тырыштык инде», – дигән булдылар…

Керергә минем чиратым җитте. Бит очларымның януын, аякларымның дерелдәвен аңлатып бетерерлек түгел иде. Мин бик борчылдым, югаласым, ишек төбеннән йөгереп китеп барасыларым килде. Сыйныф җитәкчебез Ания Айдаровнаның:» Әйдә кер инде», – дигән тавышы гына мине туктатып калды.

Мин кердем. Утырдым. Сөйли башладым. Рус теле укытучысы яныма килеп басты да, кашын-күзен җимереп, алдымдагы текстка төрткәли башлады, кулындагы кызыл ручкасы алдымдагы кәгазьне сырлап бетерде. Бәйләнүенә түзә алмадым, бит алмаларыма кайнар яшьләр тәгәрәде. Сөйләп бетердемме, юкмы - белмим. Рус теле укытучысының: «Ай-яй!!! Шунда да!!! Ужас!!!» – диюе генә хәтеремдә. Ишекне ябып, чыгып чаптым. Тик кая чапканымны гына белми идем.

Бәдрәфкә кереп бикләндем. Тиз генә кесәмнән телефон алып, әниемә язарга керештем. Ләкин: «Эшли алмадым», – димәдем, «Әни, чыктым. Бары да әйбәт!» дигән СМС китте әниемә. Әле бер ел элек кенә каты авырудан терелгән әниемә барысын да сиздерергә, аны борчырга ярамый иде. Салкын су белән битләремне юдым. Тынычлангач кына, башымны аска игән килеш, сыйныф бүлмәсенә кердем…

Арткы партада көлгән тавышлар ишетелде. Үземне тынычландырырга тырышып: «Аллага шөкер, бетте», – дип, күзләремне йомдым. Әмма Ания Айдаровнаның: «Ләйлә, аңлыйм, хәзер борчылырсың инде, тик синең сөйләгәнең яздырылмаган. Тагын бер

кат сөйләргә туры киләчәк», – дигән сүзләрен ишетеп, аптырап калдым, шыңшып елый башладым. «Ник мин? Нигә һаман минеке?» – дип ярсыдым...

Ул да түгел, «Кайда йөри ул?!» – дип кычкырып, рус теле укытучысы ишекне ачып җибәрде. Аның төс-кыяфәте куркыныч, бөтен йөзенә мине күралмавы язылган иде. Ул мине тынычландырасы урынга, кычкырып, җилтерәтеп, кабинетка алып кереп китте. Мин шешенгән, елаудан күзләрем кызарган хәлдә компьютер каршына кереп утырдым. Кулларым, аякларым дерелди; ничек сөйлим бу халәттә? Укытучыга күтәрелеп карарга да куркам: аннан миңа әллә нинди салкынлык, нәфрәт бөркелә иде. Ярый әле компьютер җансыз: синең кайгыңны да, шатлыгыңны да бертигез кабул итә; аның каршысында кем утырса да – директор баласымы, әллә гади ишегалды себерүче баласымы – якламый да, әрләми дә.

... Сөйләдем. Тавышымның калтыравыннан тәрәзә пыялалары зыңлап тора, йөрәгемнең чыгып төшәрдәй булып тибүеннән бүлмә диварларында кайтаваз яңгырый кебек иде. Бу хәлгә компьютерның да җаны әрер иде, әмма рус теле укытучысыныкы түгел!! Ул, тавышына тимер чыңнары, әллә нинди яшелле-мешелле төсмерләр кертеп: «Бар, чык!» – дип ысылдады. Чыктым. Тик яшьләремне тыеп кала алмадым... Миңа хәзер бөтенесе дә барыбер иде: елавымны башкаларның күрүе дә, имтиханымны бирә алмавым да, укытучының нәфрәте дә! БА-РЫ-БЕР!!!

Әмма иң кызыгы, ә бәлки, иң кызганычы дүрт-биш минуттан соң башланды: минем беренче сөйләгәнемнең дә яздырылган булуы ачыкланды. Бу хәбәрне ишеткәч, мин агарындым, бер мизгелгә йөрәгем тибүеннән туктап калган кебек булды. Күңелемдә актарылып дулкын күтәрелде дә кисәк кенә тынып калды. Нәрсә бу?! Минем борчылучан икәнемне белә торып, миңа юри ике тапкыр имтихан бирдертү, сөйләгән вакытта бүлдереп, минем нервларымда уйнау, яшелле-күкле тавышлар белән кычкыру ник кирәк булды икән?!. Кемне мыскыл итте укытучы?! Минеме?! Әллә «Укытучы» дигән бөек исемнеме?! Кем имтихан бирде бүген: минме, әллә улмы?

Бу вакыйгадан соң мин тәмам үзгәрдем: сөйләшмәс, елмаймас булдым, төшенкелеккә бирелдем. Бөтен дөньяны гаепләдем.

Көннәр, айлар үтте. Тынгысыз, йокысыз төннәр дә үтте... Күңелдә үпкә калса да, аңга килдем. Барын да аңладым: монда тулы ай да, йолдызлар чыкмавы да гаепле түгел, көзгегә карап елмаюның да катнашы юк. Бу – бары тик үсү. Бу – Зур тормышка аяк басу... Гаделсезлек тулы зурлар тормышына...

**Азизов Зөфәр Фәннур улы, 17 яшь**
*Җитәкчесе: Евсеева Лариса Рамил кызы*

## МӘГЪНӘСЕЗ КИЧӘЛӘР, ЛӘКИН КАДЕРЛЕ КОЧАКЛАР

*ә син сөйкемле.*

Валентин Подольский мәктәп бәйрәмнәрен сөйми иде. Бөтен сыйныф бер түгәрәккә җыелып, укытучының уртага утыруын сөйми иде; Вероника Анатольевнаның берәрсенә басарга кушуын, бу бәхетсездән башкаларга берәр ямьле сүз әйттерүен, үзенә дә чират житүен – боларның барысын да күрәлмый иде ул.

Егет әнисен кочакларга ярата иде. Моны ул «син бүген шундый чибәр» кебек, аның каравына, кирәксез мактаулардан күпкә файдалы саный иде. Аның уйлавынча, сөйләмгә комплиментлар кертү ул – ялагайланып, кешене үзеңә җәлеп итү. Валентин «тәмле» сүзләрнең ихлас булуына ышанмый иде.

Бу тормыш тәҗрибәсе җитмәү дип аталамы?

*сиңа бу көлмәк бик тә килешә.*

Бөтен сүзләрне берәр төскә буяп булса, малай кызыл төсне «романтика»га гына багышлар иде. Гөлчәчәкләр. Күңелдә дөрләп янучы ут. Ярсуланып типкән йөрәктәге кан. Бер сүзгә бигрәк күп көч һәм вакыт түгеп, үзенең дә буялганын сизми калуы – аяныч. Карашлар төсмерләрен алыштыралар: берәүләре яктыралар, кайсылары, киресенчә, төссезләнәләр…

Валентин, киемнәрен «үткән»нең ярында калдырып, чиксез Мәхәббәт диңгезенә чумарга хыяллана иде. Моны унике яшьлек бала да булдыруына ышана иде ул, ләкин үзендә бу хәләтне унтугыз-егерме яшьләрендә генә көтә иде. Алайса хәзер аны нинди хисләр били соң?

Тамара А., аның йокламавының бүгенге сәбәбе, ниндидер искиткеч яктылыгы белән үзенә җәлеп итүче сәләте белән башка кешеләрдән аерылып тора иде. Подольский магнитның бүтән ягы, минуслы заряды белән, теләсә кайсы секундта борылу мөмкинлеген аңлый иде. (Димәк, бөек француз галиме Ампер физика ярдәмендә мөнәсәбәтләр теориясен дә аңлата белгән). Әмма хәзер Валентин

үзенең стереотипларына карамастан Тамарага әллә ни кадәр матур, тәмле сүзләр яудырырга әзер.

Бу күз төшерү дип аталамы?

*сине йолдызлар белән чагыштырырга телим.*

Унике яшьтә кызыклы очрашулар уйлап табу авыррак шул. Атна дәвамында кулдан тотышып йөрүләрне, очрашканда елмаюларны һәм кочаклашып хушлашуларны ниндидер могҗиза белән тәмамларга кирәк иде. Йолдызлы күккә карарга берәр өй түбәсенә чакырудан артык тагын нәрсә эшли ала ул?

Егет кызгылт сары төсле күлмәк өстенә үтүкләгән мантиясен киде. Күршедә яшәүче сыйныфташлары аның киенү зәвыгын ошатмаганнарын бер белдергәннәр дә иде хәтта... Мантиядәге кечкенә тишек Валентинга көнләшүләренең дәлиле иде: бик тә килешә иде инде үзенә бу киеме.

Шампуньнән килгән бөтнек исе муенындагы әтисенең одеколоны исен каплый иде. Яңа аяк киемен киеп, көзге алдында елмайды да чыгып китте.

Романтик очрашуга кадәр ун минут калып бара иде. Анда соңга калып булса да, өйгә кичке сәгать уннан соңрак кайту мөмкин түгел иде: әти-әнидән шелтә аласы килми. Алар сүзен тыңламау ихтирамсызлык күрсәтү булыр иде.

Бу гашыйк булу дип аталамы?

*«романтика»ны кара корым белән буярга*

*мөмкинлекне беркем дә аңламас.*

*гөлчәчәк энәләре белән яралый,*

*көл эчтән яндыра. ул кычкыра.*

Инде егерме минут көтүенә үпкәләп, авыр сулыш алды. Үтә салкыннан мантия инде коткармый; суык аяктан җилкәләргә кадәр бик җитез менә.

Тамара килмәде, бер сүз дә әйтмәде.

Ләкин Валентинда кыз соңга калып кына, тиздән килеп җитәр дигән өмет яши. Ул китәргә ашыкмый әле: күңелсез кайтып, ни өчен кәефсез булуын аңлатасы килми аның. Йолдызлар компаниясендә калгач кына, астрономия белән мавыгуын сизеп ала.

Ярты сәгать эчендә йолдызлар яктырак яна башладылар. Валентин торып басып, мантиясенә ныграк төренә. Әкрен генә баскычтан төшә башлый, ләкин ул инде хәзер егылудан курыкмый һәм соңгы баскычларны сикереп уза. Өенә таба юнәлә. Фатирга керер алдыннан ирен кырыйларын күтәреп, йөзенә елмаю маскасын киеп куя. Ишектән кергәч:

– Гафу ит! Соңга калдым! – дип аш бүлмәсеннән сузылып караучы әнисенә эндәшә. Ул бик киң елмаярга тырыша: соңга калып кайту сәбәбенең мөһимлеген арттырырга кирәк бит. Әнисе бер сүз дәшмичә, янына килеп, улының кулларын кабашлый башлый. Ә күзләре белән малайның йөзен бораулый. Кинәт ана баласын күкрәгенә кысып, баш түбәсен үбеп ала:

– Мөгаен, ул килә генә алмагандыр, – дип пышылдый. Бу сүзләрдән бала, әнисен кочып һәм аңа ныграк сыенып, үкереп елап җибәрә. Бер минут чамасы шул килеш торганнан соң, малай җиңеллек тоя башлый. Мәхәббәт хисеннән йөрәге дә, куллары да җылына. Моннан артык берни кирәкми аңа: юатулар дә, тәмле, җылы сүзләр дә…

Бу – Мәхәббәт.

**Хаҗиева Айлия Айдар кызы, 15 яшь**

*Җитәкчесе: Хаҗиева Әлфия Галинур кызы*

# ЗӘҢГӘР ТҮБӘЛЕ ЙОРТ СЕРЕ

Тукайның авылы тау башында салынган кебек, минем өем дә тау башында урнашкан. Һәм, беләсезме, бу – бик зур бәхет! Салкын кышларда буран, яз көннәрендә җил дулап борчыса да, тау башыннан ямьле авылыбыз уч төбендә генә күренеп тора. Җәйге кичләрдә мин тау кырые буенча йөгерергә чыгам, һәм авылның гүзәллеге миңа ап-ачык күренә: әнә тигез итеп тезелеп киткән йортлар, җомга көннәрендә мунча торбаларыннан чыгып утыручы төтен, Изгеләр чишмәсе һәм Әкәй тавы артына качып баручы кечкенә кызыл кояш. Тик мин аларга артык игътибар бирмим – күзләрем бары тик бер йортка текәлгән: ул миңа балачагымны искә төшерә…

Башкалар өчен бу йорт бүтән авыл өйләреннән берни белән аерылмыйдыр: зәңгәр түбә, зәңгәр капка, капка төбендә – әче миләш, ә ишегалдының уртасында – ялгыз каен. Элек анда минем иң якын дустым яши иде. Хәзер беркем дә яшәми. Ә ни өчен бу йорт бушап калды соң?

… Кечкенә чакта минем дусларым бик аз иде. Бик йомык, хыялый бала идем. Балалар бакчасында берүзем генә почмакта уйнап утыра идем. Кешеләрдән читләшү, аралашмау – минем турында. Башкалар мине сәер дип уйлаганнардыр, шуңа минем белән уйнарга теләмәгәннәр. Көннәрдән бер көнне минем шул сәер, моңсу дөньям күгендә кояш балкыды – минем белән Зилә дуслашты. Без бер-беребезнең капма-каршысы идек: әнә ул, Зилә, бер тиктормас, чыр-чу килеп торучы, гел нидер такылдап торучы шук кыз. Һәм үзенең дуслыгы белән ул мине бәхетле итте.

– Йоклама инде, тор әйдә! – бакчада төшке йокы вакытында Зилә торып утыра иде дә, котыра башлый иде. – Рәхәтләнеп уйныйк! – дип, караватында торып басып, сикереп-көлеп, малайлар белән сугышып бетә иде. Үзе һаман мине уята: – Тор инде-е-е!

Ә мин аны аңламыйм. Рәхәтләнеп, җылы юрганны кочаклап, тәмле төшләр күреп йоклыйсы гына килә.

Шул вакытта, чыр-чуны ишетеп, йокы бүлмәсенә тәрбияче кереп килә. Апаның усал карашын күрүгә, Зилә котырган җиреннән юрган астына кача, янәсе, хәзер әләгәчәк. Тик тәрбиячenең:

– Эх, сезне… – дигән сүзләре генә ишетелә, әмма бу сүзләр шул кадәрле көчле ки, алар бөтен баланы кире йокларга яткыза һәм бүлмәдә тынлык урнаштыра.

Мәктәптә исә без Зилә белән аерылмас дусларга әйләндек. Аерылмас дию бик үк дөрес булмас: икебезне дә малайлар белән бер партага утырттылар. Тәнәфескә кыңгырау чылтырадымы, култыклашып, мәктәп коридорларын әллә ничә кат иңләп чыгабыз. Зиләнең әтисе мәктәптә хезмәт дәресен укыта, шуның янына кереп чыга Зилә. Төрле инструментларны кулына алып: «Әти, моның белән нәрсә эшлиләр? Син дәрестә малайларга бу әйберләр белән эшләргә өйрәтәсеңме? Эх, безгә дә хезмәт дәресе керсә иде!» – дип, әтисен аптыратып бетерә. «Кызым, күлмәгеңне пычратасың. Куй чүкечне. Сезне, кызларны, чигәргә өйрәтерләр», – дия әтисе.

Төгәл хәтерлим: өйдә дә тынгы бирми дустым. Көн саен шалтырата миңа. Кичке ашны ашарга гына утырабыз, телефон чылтырый. «Миңа инде бу!» – дип йөгереп чыгып китәм, үзем эчтән генә елмаям, бүтән кешенең андый көн саен шалтыратучы Зиләсе юк лабаса!

– Исәнмесез, тыңлыйм, – дип, телефонны алам һәм тавышны калынайтып сөйләшәм.

– Исәнмесез, Алиягә бирегез әле.

– Ә ул өйдә юк.

– Алдалама инде, Алия! Мин бер өй эшен дә белмим! Әйтеп чык әле.

– Тә-әк. Анда татар теленнән бар иде бугай.

– Ә, аннан – 68нче күнегү, математикадан мисаллар чишәсе, рус теленнән диктантка әзерләнәсе. Шулаймы?

– Әйедер инде…

– Рәхмәт, Алия, пока! – Ул телефонны куя, пип-пип-пип дигән тавышлар гына ишетелә. Ә мин уйлыйм: «Өй эшләрен белмим дигән була!»

Малайлар белән талашырга ярата иде инде Зилә! Бер егет белән гап-гади карандашны бүлә алмадылар. Ул карандаш инде ашалып, очлары тешләнеп беткән. Теге малайның ачуы чыга: «Минеке ул! Күрәсеңме әнә, тешләнеп беткән, кызлар алай карандаш ашап утырмый бит инде!» Ә Зилә аның сүзләрен тыңлап та тормый, миңа сөйли: «Кара син аны, минем карандашымны алмакчы була. Минеке ул, мин гел карандаш очын тешләп утырам ич!». Озак тарткалашкач, Зилә барыбер карандашны «законлы» рәвештә үзенә кайтарды. Шундый әрсез инде үзе!

Бадминтонга да бергә йөрдек без. Дәресләр беткәч, тамак ачса да, мәктәптә калабыз, бадминтон түгәрәге башланганны көтәбез. Озак көтәргә туры килә, ашыйсы килә җитмәсә, нишләп кенә кайтып китмәгәнбез икән шунда? Тик кенә утырабыз-утырабыз да, безгә күңелсез була башлый. Шуннан, кызык ясарга теләп, мин Зиләдән сорыйм:

– Зилә, сиңа кем ошый?

– Хмм… Малайларданмы?

– Нәкъ шулай.

– Ул малай безнең класста укымый, тик мин аны яратам.

– Кем соң ул, әйт инде-е-е!

– Әйтмим! Син башта әйт!

– Ә мин беренчерәк сорадым!

– Ярар, ярар. Минем иң яраткан малай ул… минем әти!

– Менә ничек икән! Алай кызык түгел бит инде. Дөресен әйт, Зилә.

– Ә мин чып-чынлап сөйлим. Беләсеңме, мин әтине ничек яратам! Ул да мине ярата, әнине дә ярата. Ул шундый әйбәт!

Зиләнең яраткан әтисе бер көнне бадминтонга да килде әле. Язгы кояшлы иртә иде. Якшәмбе булуга карамастан, түгәрәккә шактый бала җыелдык. Спортзалга зур тәрәзәләр аша кояш нурлары керә, күзләр чагыла. Ләкин шундый рәхәт, яз җитүгә бала күңеле ничек шатлана! Дус кызым да бик бәхетле иде, көлеп-сикереп, әтисе янында бөтерелде. Зилә ул көнне гел әтисе белән генә уйнады, гүя аны үзенең яныннан җибәрергә курыкты… Эх, бу бәхетле минутлар мәңге булса иде!

Чыннан да, язның искитмәле көне иде ул. Гөрләвекләр ага башлаган, күкрәкләргә язның үзенә генә хас саф һавасы, каен суыдай баллы исе кергән чак. Апрельнең табигатьне уяту сәләте бар, ул җирне кардан ача башлады. Шуңа да бу көннән авыл халкы бары тик шатлыклы хәбәрләр генә китерер дип көтте. Ләкин бу көн безнең баглаган өметләрне акламады: ул бик начар хәбәрләр китерде...

Зиләнең әтисе үлде.

Ышанасызмы..?

Үлде...

Ул вакытта мин бу сүзнең нәрсә икәнен аңламадым. Мин ышанмадым, ә Зилә? Ул нишләгән, бу хәбәрне ничек кабул иткән? Әтисе, йөк машинасын рәтләгәндә, астында күкрәге белән кысылып калган. Кеше бар, ә бер мизгелдә ул юк. Бер мизгел, бер ялгышлык – һәм кеше юк.

Үлде... Үлем белән килешеп буламы?

Кечкенә, тормышка гашыйк, әтисен бик нык яратучы Зиләнең дөньясы кисәкләргә коелып төште. Бу кызчыкның нинди хисләр кичергәнен аңларга тырышу кирәкме?

Үлем... Нәрсә ул? Аңлыйсызмы, бу сорауга җавапны белмәү яхшырак. Үлемнең нәрсә икәнен беләсең икән, димәк, йөрәгеңдә яра бар, якын кешеңне югалткансың. Зиләнең, кечкенә кызчыкның, йөрәгендә дә яра барлыкка килгәндер. Ул ышанмагандыр. Аннан бик күп елагандыр. Мин аның янында була алмадым. Зиләнең нинди халәттә булуын, нәрсә кичергәнен һич аңлый алмадым.

Бик озак килмичә торды ул мәктәпкә. Килгәч, бик уйчан, авызына су капкандай, сөйләшми торган булды. Бары тик моңсу, хәтта өметсез, куркулы күзләре аның сагышы турында сөйләде. Мин аңа терәк була алмадым. Хәер, мин, кечкенә бала, ничек булышыр идем аңа? Бәлки мин аны кысып кочаклап, аның нәрсә кичергәнне сөйләгәнен тыңласам, дустыма җиңелрәк булыр иде. Ул үзен ялгыз хис итмәс иде. Дуслар кайгыда сынала. Мин сыналмадым. Мин анда кечкенә идем, тик бу мине аклыймы?

Зилә нәни йөрәгендә, чиксез сагышы белән бергә, әтисен дә йөртте. Ул әтисен бик еш искә ала иде. Үлем турында бик еш уйлана

башлады ул. «Әтием хәзер башка дөньяда, ләкин безнеке кебек йортта яшидер, мөгаен, – диде ул бер тапкыр, – һәм алар җәннәттә бу дөньяда эшләргә өлгермәгән эшләрен бетерәләр, дип ишеткән идем. Минем әтине теге көнне өйдә йомырка тәбәсе көтеп тора иде, ул аны ашамады. Тиздән ашарга керәм, дип чыгып китте, ләкин кире кермәде...»

Мәктәпкә яңа хезмәт укытучысы килде. Аның кабинеты яныннан үтеп барганда, Зилә кинәт туктап калды.

– Ни булды?

– Эй... Бу укытучыны әти дип торам. Күзгә күренде... костюмы әтинеке шикелле икән, – диде дустым. Ул букчасын тотты да, үзенең моңсу уйларын читкә ташларга тырышып, тиз-тиз атлап китте.

Зилә мәктәптән иртәрәк кайтып китә башлады. Ул кайчак парта кырыена кереп посып, әнисенә шалтырата иде. Мәктәптән кайтып киткәнгә, кайбер сыйныфташларның ачуы килде. Алар бер әйберне истән чыгардылар кебек: кич җиткәч, без көн саен әтиләрнең кайтканын сагынып көтәбез, ул берәр тәмлүшкә алып кайтмасмы, дип уйлыйбыз. Ә Зилә көтә алмый. «Ул бит ятим, әтисез! Аңлагыз шуны!» – дип кычкырасы калган миңа шул вакытта.

Шактый вакыт үтте. Җәй көне Зилә башка шәһәргә күченде. Алар яшәгән йорт бушап калды. Зәңгәр түбә астында хәзер кеше юк. Алар ишегалды уртасында үскән каенны, капка төбендә утырган миләшне ялгыз калдырдылар. Мин моны аңламыйча калгандай булдым. Без саубуллашмадык, гел күрешеп торыйк дип сүз куешмадык, ләкин дөрес эшләдек.

Нигә дөрес эшләдек? Зилә күченгәннән соң еллар үтте, без үстек. Элек бер-беребезнең иң якын дуслар булганыбызны да оныттык сыман, бик кызганыч. Аның хәзер яңа дуслары, яңа тормыш. Без бик сирәк язышабыз, бик аз аралашабыз. Быел мин аның туган көненә озы-ы-ын котлау язып, теләкләремне җиткердем, һәм ул аңа коры гына «Рәхмәт!» – дип җавап язды, йөрәк өстәде. Аннан соң без аралашмадык.

Еллар узды. Тик һаман ышанасы килми. Иртәгә мәктәпкә барсам, каршыма шаян, гел нидер тыкылдап торучы Зилә килеп чыгар да, мине кулымнан өстерәп, класска алып кереп китер шикелле.

… Җылы кичләрдә мин йөгерергә чыгам. Игътибарым – зәңгәр түбәле йортта. Хәзер инде каенга һәм миләшкә иптәш булып, зәңгәр түбә астында башка, чит кешеләр яши. Чит-ят булсалар да, мин аларга бәхет һәм бүгенге көннән тәмен белеп яшәүләрен телим: иртәгеге көннең нинди булып туасын беребез дә белми.

# 📖 19-25 яшьлекләр

**Кадыйрова Фирүзә Илфировна, 22 яшь**

## ХАМЕЛЕОН

– Роберт, кил әле.

– Ашыга идем…

– Күп вакытыңны алмам.

– Әйе,тыңлыйм сезне?

– Дамир белән тынышмыйсыз дип ишеттем?

Егет бераз сүзсез торганнан соң:

– Кем әйтте? Булганы юк андый хәлнең.

– Аладама инде, Роберт, беләм бит: биш мең сум бурычың бар синең аңа.

Роберт дәшмәде. Иреннәрен кысып, башын түбән иде. Аннан як-якка каранып алды.

– Шул хакта сорарга гына туктаттыгызмы? Мин ашыгам, – диде ул күзләрен каядыр читкә төбәп.

– Роберт, мин бит сиңа булышырга телим. Хәлеңне бик яхшы аңлыйм.Дамир белән тиз арада дуслашырга, бурычыңны кайтарырга кирәк сиңа. Югыйсә әти-әнисенең эшне зурга җибәрүләре бар. Әйе, аңлыйм инде, хәзер үк моны эшләргә синең мөмкинлегең юк. Ярый да башкаларга өйдән атна саен акча, тәм-том җибәреп торалар. Әниең үзе генә шул, өстәвенә кечкенә сеңлең дә бар.

Роберт сүзсез генә авыр сулап куйды. Әтисе аларны ташлап, каядыр китеп югалганда аңа әле 5 кенә яшь иде. Инде үсә төшеп, мәктәпкә керер вакыт җиткәч, әнисе аны «Мин бик тырышсам да, сиңа ата тәрбиясе бирә алмам», –дип хәрбиләр укый торган мәктәп-интернатка укырга кертергә уйлады. Әлге мәктәп шактый ерак урнашканга күрә, Роберт өйенә я айга бер, я ике генә кайта торган булды.

– Роберт, Роберт дим, син мине ишетәсеңме? – укытучычысының тавышы егетне уйларыннан бүленергә мәҗбүр итте.

–Мин аңа барсын да кайтарам. Әни икенче атнага акча җибәрәм диде.

– Әниеңне борчымаска иде инде, Роберт. Беләсең бит, ул болай да сезнең өчен көне-төне авыр эштә бил бөгә. Сиңа мин үзем булышам.

– Ничек?

– Ничек дип, бер яхшы тәкъдимем бар. Игътибар белән тыңла. Эш җип-җиңел. Сиңа бары тик бер укытучының дәресен бозарга гына кирәк була һәм вәссәлам. Шуның белән синең бөтен бурычларың үзләреннән үзләре юкка чыгар...

– Аңламадым? Ничек инде бозарга? Сез ни сөйлисез?!

– Яле, каушама син. Аннан гына берни булмас. Сиңа да, укытучыга да. Кайберәүләр үзләрен артык әллә кемгә куя башлады монда... Акылга утыртырга кирәк. Минем белән андый шаярулар барып чыкмас!

Роберт ни әйтергә белми аптырап калды. Дөресрәге ул үз колакларына үзе ышанмады.

– Юк,юк... Мин, мин... Мондый адымга бара алмыйм, гафу итегез.

– Шулаймени? Хм, ну, үзеңә кара Роберт... Узган атнаны гына спортзал тәрәзәсен таш атып җимерүеңне оныткансың ахры син?

– Мин ватмадым аны, сез кем беләндер бутыйсыз, – диде Роберт берни аңламыйча.

– Юк, син ваттың! Штрафын да син түлиячәксең! Дөресрәге, ниең түлиячәк. Рәхмәт әйтер инде ул сиңа. Молодец, улым, дияр.

– Сез нидер бутыйсыз...

–Мин берни дә бутамыйм, Роберт, берни дә. Яле, уйлап кара, кемгә ышанырлар? Сиңамы, әллә миңамы?

Роберт, ниһаять, нинди капкынга килеп капканын аңлап алды. Укытучысына каш астыннан карап, йөзен сытып куйды. Күз алдына әнисенең көне-төне эшләп, яргаланып беткән куллары, моңсу-уйчан, талчыккан йөзе килеп басты. Юк! Болай да күп михнәт күрде аның әнисе улы аркасында,бу хәбәрне дә җиткерсәләр, йөрәге түзмәс...

ДӘВАМЫ БАР

**Гайнетдинова Индира Фәннүр кызы, 19 яшь**

# ҮТКӘННӘРГӘ СӘЯХӘТ

Колакларны чыңгылдатып яңгыраган каты тавышка сискәнеп уянып киттем. Купе ишекләре шыр ачык булу сәбәпле, күрше вагоннардан аермачык ишетелгән тавышлар төшемне бүлделәр. Татлы йокымнан аерылып, башымны йомшак мендәрдән күтәрә алмыйча азапланган килеш, яртылаш ачык күзләрем белән тирә-юньне күзәттем. Карачкы кебек караеп күренгән агач-әрәмәлекләргә, кыйшайган түбәле йортларга, буш басуларга, төтен, тузан белән ысланган каралты-куралаларга карап бару тәмам туйдырды. Күзне ял иттерердәй, күңелгә куаныч бирердәй берәр манзара, тормыш, кайнап торган кала-сала очрасын иде, ичмасам. Ачык тәрәзәләрдән биткә салкын җил өрә – быел җәй салкын килде. Тән буйлап бәбкә йоны йөгерә, ә күз алдыннан калейдоскоп кебек сурәтләр алмашына: үткәне, бүгенгесе, киләчәк. Алар арасында балачак кына – якты һәм җылы. Шулай тирән уйлар диңгезендә йөзеп утырган арада, янәшәдә утырган, саргаеп арыган гәҗитне тырыша-тырмаша укып азапланган Дилфат бабайга күзем төште. Янында берничә калын китап һәм фотосурәт ята. Фотода исә милли китапханәдән күренеш. Борынгы биналардагы үзгә ис һәм китаплар дымы бер аңкышка агып чыга да, әсәрләнеп каласың. Бер карасаң, үзе бик җидти профессорга охшаган, бер карасаң, чи авыл бабайларыннан бер дә ерак китмәгән. Пошына-пошына ниндидер хезмәтләр актара, күп тә узмый, шаркылдап көлеп җибәрә, тагын укый, тукталып тирән уйга бата, киредән авызы колакта, ә колак еракта. Укыганын йомшак кына тавыш белән тагын берничә тапкыр кабатлап ала. Әйе, шундый киң күңелле карт инде ул, Дилфат бабай; тарих белән кызыксына, гомере буе бик күп илләр буенча сәяхәт кылган, йөзләгән шәһәрләрләрдә эзен калдырган.

Әле кичә генә танышкан булсак та, бабай турында бик күп мәгълүмат тупларга өлгердем. Эчкерсез ич, киң күңелле, гел сабый бала кебек инде үзе. Янында кечкенә генә буйлы, ак яулыгын чөеп бәйләгән Зифа әби иртәнге чәй әзерләп азаплана. «Сөймим шушы поезд ризыкларын. Гомерем буе картым белән дөнья гизеп йөреп, тәмам бизеп беттем инде шушы ««ярымфабрикат» ризыкларыннан.

Менә ичмасам, авыз итегез, үз йортымда пешкән җылы ризык...» – дип сөйләнә-сөйләнә, кабарып пешкән, борыннарны кытыклап, вагон буенча таралган хуш исле ризыкларын өстәлгә китереп куйды. Уянганымны күрсәтмәскә тырышып, шыпырт кына ятсам да, Зифа әби минем торганны сизеп алып, үзенең сый-нигъмәтләрен миңа да кыстый-кыстый ашатты. Чыннан да, өй ризыгы телләрне йотарлык тәмле инде ул, авызда эреп китә. Ә Дилфат бабай исә,тарихка башы-аягы белән чумып элекеге еллар буенча сәяхәт кыла иде. Әбинең сөйләнгәннәрен колагына да элмәде. «Килеп җитәбез ич, уян!» – дип, дәшкәч кенә кинәт сискәнеп көрән төстәге, маркалар белән ябештерелеп беткән чемоданын утыргыч асытыннан тартып чыгарып тиз-тиз тутырырга кереште.

Зифа әби белән Дилфат бабай шәһәрдән биш-алты чакырымлык авылга юл тоталар иде. Шәһәр ыгы-зыгысыннан туеп, гомерләренең көзентыныч тормышта үткәрәселәре килә, шуңа күрә кечкенә урыс авылыннан йорт сатып алганнар. Дилфат бабай туган йортын калдырып чыгып киткәндә аңа нибары сигез-тугыз яшь чамасы булган, шуңа күрәаларга мондый күченеп йөрү эшләре бернинди авырлык тудырмый, киресенчә, яшьлек елларына алып кайта. Тик язмышлары гел шулай язгы чәчәктәй атып утырмаган шул. Икесе тиңрәхимсез һәм дәһшәтле Бөек Ватан сугышы елларын узган бөек кешеләр. Әле ул вакытта сигез-тугыз яшьлек сабыйлар булсалар да, ачы һәм ач, авыр еллар мәңге хәтердән чыкмаслык булып йөрәкләрендә уелып калган. Тик сугыш елларына әйләнеп кайтып сөйли китсәң, алар сүзне икенче якка борырга керешәләр иде. Дилфат карт аеруча сугышның барлык авырлыгын үз җилкәсендә күтәреп йөрткән кеше: рәхимсез сугыш әти-әнисен дә, алты бертуган сеңлесен дә алып киткән. Вагондагы халыкның гөр килүе йокымнан арындырмаса, әле дә фашистлар белән сугышып йөргән булыр идем. Янәсе, сугыш башланган яки мин үткәннәргә кайтканмы, билгесез, ләкин бомбалар гөрелдәве ишетелә. Ә башымда бердәнбер уй: ник качмадым мин бу илдән ?!... Һәм шул вакыт бабай сүземне бүлдерде: «Сугыш бит ул, улым, гасырлар дәвамында синдәйләрне генә түгел, алпавыт ирләрне, көчле хатыннарны изеп үзенә буйсындырган тулы бер организм. Ә син, ә без – лаеклы нәселебезне дәвам итүче нәзберек кенә кешеләр, ләкин без көчлерәк, чөнки без шул тулы бер көчле организмга күзгә-күз

карашып каршы торганбыз». Зифа апа сүзебезгә кушылып: «Язмыш булгач, төрле хәлләр була инде: үксетеп елата да, канга батырып кыйный да, эчләр шомарып катканчы көлдертә дә дигәндәй... Әйдә, кайгылы хәлләргә караганда, рәхәт вакытлар күбрәк булды түгелме соң, Дилфаткаем, шуларны сөйләп узыйк», – дип, кыенсынып кына елмаеп, күңелне ярып үтеп керерлек җылы караш ташлады. Күрәм, әле дә йөрәкләреннән кан саркый, тик шулай да әлеге ике яшь йөрәкле кешедә бәхет дигән нәрсә бар яклап ташып тора иде. Алар яшәү ямен бөтен җаны-тәне белән тоеп, гөрләп яшәргә ашкынып торучы изге йөрәкле кешеләр.

ДӘВАМЫ БАР

**Мусина Ләйсән Илнур кызы, 21 яшь.**

## ХӘЕРЛЕСЕН НАСЫЙП ИТ

Галия Сафина мәктәптә инглиз теле укыта. Яшь, өметле мөгаллимә. Факультатив итеп кытай телен дә алып бара. Бишенче «В»ларның сыйныф җитәкчесе дә. Мәктәптә икенче елын гына эшли. Мәктәпкә эшкә килергә атлыгып тормаса да, дүрт ел институт тәмамлаганым әрәм булмасын, эшләп карыйм, дип кайтты ул район мәктәбенә. Аңа карата хезмәттәшләренең, мәктәп директорының да хөрмәте зур, чөнки үз фәнен бик яхшы укыта Галия Хәлилевна. Нинди бәйге, конкурс булса да аны гына җибәрергә торалар. Бүген дә «Яшьлегем-хөрлегем» эшләүче яшьләр фестиваленә концерт номеры әзерләп, мәш килеп укытып, тормыш тәгәрмәчендә тиендәй «тәгәрәп» йөргән көннәре...

***

Чәршәмбе көн. Башка көннәрдән әллә ни аермалы берни юк бүген дә. Дәресләр иртәнге сигездә башланды. Биш сәгать инглиз теле, аннары бер сәгать алтынчыларга кытай теле укытты Галия. Кытай теле дигәннән, аны үткәрергә бөтенләй яратмый. Фәнен ярата, тик менә «факультатив» дигән исем бирелгәнгә күрә, балаларның бер дә исләре китми. Шуңа күңеле төшә кызның. Дәрес дип аталучы фәннәрдә, ичмасам, билге өчен дип булса да тыңлап, кушканны эшли укучылар. Тик менә кытай теле дәресендә хәлләр мөшкел. Җитмәсә, дәресләрдән соң, балалар тәмам хәлдән тайгач бит ул факультативлар.

***

«Факультатив» үткәреп чыкты да, ухылдап эш өстәленә ауды кыз. Лимон кебек сыкканнар диярсең, бер дә хәле юк. Күзләрен йомып яткан килеш, яңа укытып чыккан кытай теле дәресен янә күз алдына китерде. Алмаз, гадәттәгечә, иң арткы партада ашханәдән алып чыккан ипи кисәге кимереп утырды. Түп-түгәрәк зәңгәр күзле, сары чәчле бу малайга сүз әйтмәде инде Галия. «И бала, бала. Тамагын ачмени соң шулхәтле. Ипинең дә каты, «кибән» башы бугай, йомшагы юк идеме икәнни», – дип кенә уйлап куйды. Балачакта гел ашап торасы килә шул. Сөйләшеп алсаң гына да ашыйсы килә башлый. Ә болар идәннән түшәмгә тузан

күтәрерлек итеп котырышалар. Ничек ашыйсы килмәсен, ди. Шуңа күрә дәрес булмаса, ашауларына каты бәрелми укытучы кыз балаларның. Җитмәсә, Алмаз кебек «тәти» малайларга ничек сүз әйтәсең. Программаны үзләштереп бара, укытучыга каршы дәшми. Беренче партада утыручы Тимур белән чагыштырырлык та түгел. Бу тыңлаусыз малайга түзәр чамасы калмады укытучының, дәрес саен яңа «шөгыль» аның. Я симәнке чиртә, я ручка эченә кәгазь бөтәрләп тыгып иптәшләренә шуны өреп утыра, я калганнарны сөйләштерә. Кайбер көннәрне парта астыннан чыгарып булмый үзен. Бүген тагын да «мавыктыргыч» шөгыль тапкан. Галия тактага кытай иероглифлары язган арада телефонын алып «Контра Страйк» уйный башлаган. Укытучы бу кыланышка юл куймады. Малайның телефонын алып, «сенсорлы дустын» әти-әнисе белән килеп алырга кушып, үзенең «сейф»ына бикләде. Ул арада арткы партадагы кызлар белән малайлар да «чыш-пыш»лашып алды. «Укучыларны тынычландырып «факультатив»ның яртысы узып та киткән икән. Әйтәм тагын бернигә дә өлгерә алмадык», – дип уфтанды кыз. «Факультатив» бетүне хәбәр итеп кыңгырау шалтырады. Укучылар авыр сумкаларын бер як җилкәләренә асып, шапы-шопы, мыш-мыш килеп, этешә-төртешә кабинет ишегеннән коридорга атылды. Кием элгеч янында да бер-берсен үртәшеп, озак кына мәтәвекләнделәр. Гадәттә, иң беренче чыгып чабучы Тимур гына әкренәйде бүген. Телефонсыз калуына нык ачуы килгән малай ишеккә иң ахыргы булып атлады. Җәллätәсе килеп, күзләрен сыта-сыта ялган яшь тамчылары чыгарырга тырышты. «Кытай телегез шул китаянкаларыгызга гына кирәк булса инде», – дип мыгырданып, ишекне тибеп кенә япты да, ташбака кебек өстерәлеп кенә чыгып китте.

***

Чираттагы дәрес башлануны хәбәр итеп кыңгырау шалтырады. Галия чак-көч, кирпеч кебек авыр тоелган башын күтәрде. Үз башы баш, менә монда тагын егерме ике баш кереп тулган. Тезелешеп бишенчеләр утыра. Исенә төште кызның, класс сәгате бар бит! Мәктәп күләмендә уздырылучы «Нәүрүз»гә әзерләнәчәкләр. Бөтенләй онытылган. Тиз арада үзен рәткә китерде кыз, сыйныфны җыйды. Чарада катнашасы бишенче сыйныф «Нәүрүзбикә»се сайланды. Парлы бию биисе егетне дә билгеләделәр. Сыйныфның

«рәссам»нары стена газетасы ясарга алынды. Галия калганнарга күмәк концерт номерында башкарылачак җырны өйрәтте. Кырыйдан карап торсаң, бал кортларының бал җыюын хәтерләтә иде кабинеттагы әзерлек.

ДӘВАМЫ БАР

# Балалар әдебияты



# Конкурстан тыш катнашучылар

**Камалиева Динә Ришатовна, 11 яшь**

*Җитәкче: Зарипова Гөлшат Искаковна*

## «СВЕТОФОРНЫ КЕМ УЙЛАП ТАПКАН?»

Борын заманда яшәгән, ди, бер карт бабай. Ул вакытта машинаны яңа гына уйлап чыгарган булганнар. Кешеләр машиналарда йөри башлаганнар. Тик бик күп бәрелешләр булган. Бу бабай уйлаган, уйлаган да, светофор дигән җайланма ясарга булган. Светофорга өч күз куйган. Тик аларны нинди төскә буярга белмәгән. Бабай урманга барып, җәнлекләр белән киңәшләшкән. «Беренче күзен кызыл ит», – дигәннәр аңа. Бабай «Ни өчен?» – дип сораган. Җәнлекләр: «Кызыл – кан төсе, куркыныч төс. Светофорда кызыл төс янса, кешеләр дә куркачаклар, юл аша чыкмаслар. Икенче күзе сары булсын. Сары – көз төсе. Көзен без кышка әзерләнәбез. Кешеләр дә юлны чыгарга әзерләнеп торсыннар», – дигәннәр. Бабай: «Ә өченче күзен ниндигә буйыйм?» – дип сораган шулчак. Җәнлекләр: «Яшел! Чөнки яшел – ул җәй. Җәен безгә рәхәт, куркыныч янамый. Ашарга күп, рәхәтләнеп урман буйлап йөрибез. Яшел төс янса, кешеләр юл аша чыксыннар», – дип бертавыштан җавап биргәннәр икән. Бабай җәнлекләрне тыңлаган да, алар өйрәткәнчә эшләгән. Шулай итеп, бүген безгә яхшы таныш булган светофор өч төсле булып калган.

**Сәйфетдинова Камилә Илдар кызы, 11 яшь**
*Җитәкчесе: Габделхәева Гөлия Рөстәм кызы*

## «МИН АНЫ КӨТТЕМ...»

Язгы кояшлы иртә… Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары нәни кызның битен йомшак кына сыпый, назлый, иркәли … Эх, шундый рәхәт, хәтта торасы да килми. Әминә йомшак юрган астында иркәләлә-иркәләнә әкрен генә күзләрен ачты. Тукта! Бу төшме, әллә өнме соң? Аның янында кечкенә генә матур бер эт баласы уйнап йөри иде. Үзе ап-ак, йомшак, маңгаенда кечкенә генә бер тап бар. Ул матур, зәңгәр күзләрен тутырып, койрыгын төрле якка селкеп Әминәгә карап тора иде. «Әнием, әнием…», – диеп кычкырып җибәрде кызчык шатлыгыннан. Әкрен генә ишек ачылды. «Туган көнең белән! Туган көнең белән! Туган көнең белән, Әминәкәебез!» – дип җырлый-җырлый әтисе белән әнисе керде. «Кызым, күз нурым туган көнең белән сине», – диде әнисе. «Рәхмәт, әнием, рәхмәт, әтием! Минем бүген иң бәхетле көнем, – диде Әминә.

Әйе, Әминә күптәннән шушындый кечкенә генә эт баласы турында хыялланган иде. Ул ничәмә тапкыр әтисе белән әнисеннән сораган иде, хәтта кыш бабайга да хат язган иде. Менә бүгенге бәйрәм иртәсендә аның хыялы чынга ашты. Хәзер Әминәнең кечкенә генә тугъры дусты бар. Ул аңа бик тиз арада исем дә уйлап тапты.

«Әни, ул минем Йолдызкай була».

«Ярар, кызым», – диде әнисе. «Бик матур исем, Йолдызкайның үзенә дә бик килешеп тора».

Йолдызкай белән бик тиз дуслашып киттеләр. Көндезләрен бергә уйныйлар, йөгерәләр, кичләрен әкиятләр укыйлар. Дөресрәге Әминә укый, ә Йолдызкай тыңлап ята. Менә шулай сизелмичә көн артыннан көн, айлар үтә. Йолдызкай да әкренләп төрле осталыклар бүзләштереп килә. Җәйләрен ул каз бәбкәләрен чәүкәләрдән саклый, көтүдән сыерларны каршы ала, яисә озата. Ул Әминә өйрәткән барлык командаларны да белә. Ят дисән ята, тор дисән тора, утыра. Ә Әминә мәктәптә булганда, ул өйне саклый. Менә шушындый «акыллы җан».

Әминә бүген мәктәптән иртәрәк кайтты, чөнки аларның бүгеннән укулары тәмамланды. Әй, рәхәт инде ул ял итүләре.... Гадәттәгечә ашап эчкәннән сон, кыз урамга чыкты. Ул күзләре белән Йолдызкайны эзләде, чакырды, тик эт беркайда да күренмәде. Әтисе белән әнисе, кайтыр әле, берәр җиргә киткәндер, диде. Инде кич җитә башлады, ә Йолдызкай юк та юк. Ул кичтә эт өйгә кайтмады. Икенче, өченче көнне дә юк.... Әминә бик нык борчылды, елады, дустын сагынды. Һәркөнне Йолдызкай кайтыр дип, аның тәлинкәсенә ашарга салды, тик тугъры дусты кайтмады. Шулай итеп, көн артыннан көн үтте, инде 1 айдан артык вакыт үтеп тә китте. Әминәнен әти-әнисе Йолдызкайның табылуына өметләрен эзделәр. «Кызым, ул еракта, аңа анда рәхәт», – диделәр. Тик менә Әминә һаман да ышана һәм көтә иде. Кайтыр, һичшиксез кайтыр, дия килде үзүзенә.

Җәйге кояшлы иртә... Кояшның җылы нурлары Әминәнең алсу битләрен иркәләп, йомшак кына сыпырып куя төсле. Тәрәзә капкасы төбендә күгәрчен гөрли, өй алдындагы miләш агачына кунып сандугачлар сайрый. Нинди рәхәт! Шушы иртәнге тавыш күңелгә ниндидер бер тынычлык, рәхәтлек өсти. «Тукта! Бу нинди тавыш! Йолдызкай!», – дип урыннан сикереп торып тәрәзәгә килде. Ни күзе белән күрсен... Әминәнен йокы бүлмәсе тәрәзәсе каршында «хау-хау» өреп, койрык болгап, ап-ак йонлы, маңгаенда карап таплы Йолдызкай басып тора. Ә аның янында йомры йомгак төсле өч кечкенә эт баласы. Берсе ак, икесе коңгырт төстәге йомшаккайлар...

# 📖 12-14 яшьлекләр

**Исламова Камилә Айрат кызы, 12 яшь**

*Җитәкчесе: Фәрваева Резедә Әнвәр кызы*

## «СЫНАЛГАН ДУСЛАР»

Борын–борын заманда, яшәгәннәр, ди, бер ишек алдында Песнәк, Чыпчык һәм башка кошлар. Һәркайсы үзенең тормышы белән яшәгән. Песнәкнең бик тә аралашасы килгән, ләкин Чыпчык андый булмаган. Яратмаган ул башка кошларны....

Матур, кояшлы авыл иртәсе. Тирә – якта «чүт-чүт» итеп кошлар сайрый. Әллә кайдан күренеп торган шундый искиткеч бизәкле өй кыегына Карлыгач килеп кунды. Аның янында иптәше дә бар иде. Алар бергәләшеп тырыша-тырыша оя ясарга керештеләр. Иң элек бергәләшеп планын төзеделәр, нинди материал кулланачаклары турында фикер алыштылар. Ананнан соң инде балчык, салам белән аралаштырып бик матур оя ясадылар. Оялары бик ныклы, тотрыклы, җылы, матур килеп чыкты. Һәм рәхәтләнеп шунда яши башладылар.

Бу ишегалдында сары түшле Песнәк күптәннән яши иде инде. Ул һәрвакыт эшчән, балаларын яхшы итеп карый. Аны башка кошлар да хөрмәт итәләр. Песнәк чисталыкны бик ярата, эшчән, башкаларга ярдәмчел.

Песнәкнең Карлыгач белән бик тә дуслашасы килә башлады. Беркөнне күчтәнәчләр алып, ул аларга кунак булып килде. Үзенең эчкерсезлеге, ярдәмчеллеге белән ул Карлыгачка бик ошады. Карлыгачны ул тирә-яктагы басу- кырлар, урман- күлләр белән таныштырды. Алар гел бергә очтылар, кич җитсә, табигатькә сокланып, өй кыгында утырдылар, бергәләшеп бала чыгардылар. Һәрвакыт бер-берсенең хәлен белеп, ярдәмләшеп тордылар.

Шушы ук ишегалдында Чыпчык та яши иде. Ул бу ике дуснның тугрылыгыннан бик тә көнләште. Аның да Карлыгач белән күңел ачасы , аралашасы килә иде. Шуңа күрә дә ул аларның араларын бозу өчен сәбәп эзли башлады.

Менә беркөнне Карлыгач дустына үзенең кунаклар җыячагын әйтте. Аш өстәле әзерләшергә Песнәкне чакырды:

– Иң якын, ышанычлы дустым син, Песнәк. Сиңа ышанып торам берүк килми калма, зинһар, – диде ул ялынып.

– Һичшиксез, киләм, дустым, бер дә борчылма, – дип җавап бирде Песнәк.

Иртән иртүк торып, балаларын ашатып, юындырып, ул Карлыгачларга юл алды. Аның каршысына Чыпчык елап килеп чыкты. Ә безнең Песнәк бит бик тә ярдәмчел, авыр вакытта булышучы да, ул шунда ук Чыпчыкны юатырга керешге:

– Туктале, дустым, елама, яхшылап аңлат кайгыңны, бәлки мин булыша аламдыр сиңа?

– Улым белән кызымны әбиләренә булышырга җибәргән идем. Кызым кайтты, улым һаман кайтмый, мөгаен адашып калгандыр, – дип, тагы да ярсып елап җибәрде Чыпчык.

– Туктале, борчылма әле син, я, әйдә, бергәләшеп эзләп кайтабыз улыңны, – дип юатты аны Песнәк. Ул инде үзенең Карлыгач өенә барып, өстәл әзерләшергә барасы икәнен онытып та җибәргән иде. Ә мәкерле Чыпчыкка шул гына кирәк тә, бик тиз ризалашып, Песнәкне алып та китте. Чынлыкта бит, Чыпчыкның балалары әтиләре белән болынлыкка күңел ачарга киткән булган.

Карлыгач Песнәкне бик нык көткән-көткән дә, өстәлне берүзе генә әзерләргә булган. Ю-ю-юк үпкәләмәгән ул аңа. Аның да гаиләсе бар, үз мәшәкатьләре бар, дип уйлаган.

Урман буйларыннын, чишмә яннарыннын, алаланнардан эзләгәннәр Чыпчыкның улын. Караңгы төшкәч кенә өйләренә кайтканнар. Билгеле инде, Чыпчыкның гаиләсе бөтенесе дә өйдә булган. И-и-и сөенгән инде Песнәк күршесенең улы табылуга.

Икенче көнне ике дус арасындагы гауганы карарга дип, Чыпчык ишегалдына чыгып утырган. Ни күрсен, Карлыгач белән Песнәк гөр-гөр килеп, чәй эчеп утыралар. Чыпчыкның бик тә ачуы килгән. Уйлаган начарлыгы барып чыкмады бит. Һәм ул икенче төрле хәйлә корырга уйлый башлаган.

Ямьле җәй әкрен генә үтеп киткән, Карлыгач гаиләсе белән җылы якларга китәргә әзерләнә башлаган. Песнәк бик борчылган, якын дусты, сердәше китә бит.

Ә Чыпчык яңа хәйлә уйлап тапкан, Песнәк янына килгән. Һәм:

– Туганнарымның ояларын хуҗаның мәчесе җимереп төшергән, кышны чыгарга монда кайтырга җыеналар. Син бит минем иске ояга урнаштың, тиз арада бушат ояны, – дип әмер биргән.

Песнәк инде моның хәйләсен аңлаган булган шул, ләкин Чыпчыкның апасының гаиләсендә балалары күп икәнен ул белгән, шуңа күрә дә ояны аларга бирергә уйлаган. Саубуллашырга дип дусты Карлыгач янына кергән:

– Карлыгач, дустым, сиңа кадәр мин китәргә булдым бит әле. Саубуллашырга кердем синең белән, бәлки бүтән күрешә дә алмабыз, – дигән.

– Ни сөйлисең син? – дип юаткан аны Карлыгач. – Син минем якын дустым, туганым кебек якын син миңа. Беләсеңме? Без озакламый юлга кузгалабыз, сине кем, кайда көтеп тора? Бернигә карамыйча, гаиләң белән безнең ояда каласың, – дигән ул Песнәккә.

Песнәк сөенеченнән дустын кочаклап елаган. Чын күңеленнән рәхмәтләр әйтеп, гаиләсе белән Карлыгач оясына күченгән. Әле ул балалары белән Карлыгачны авыл башына кадәр озата да барган. Яз көне каршы алачагына ышандырып, аларны озатып калган.

Мескен Чыпчык, шулай итеп, һаман дуслаша алмыйча йөри, ди. Шулай шул, чын дусларны бернинди очракта да аерып булмый. Песнәк белән Карлыгачның дуслыгы сыналган дуслык шул ул. Чынлап та, килеп карасагыз, безнең өй кыегындагы карлыгач оясында песнәк яши бит! Килеп күрегез, кунакка чакырам сезне!

**Гараева Ильвина Ильгизәр кызы, 13 яшь,**
*Җитәкчесе: Сәхәбиева Альбина Мансур кызы*

## «ЧЫН БУЛА КҮРМӘСЕН!»

«Дошманнар килә, немецлар килә! – дип кычкырды кемдер. Чынлап та, урамда хәрби киемдәге ят кешеләр күренде. Мине берсе тотып ала язды хәтта. Бер ишек алдыннан икенче ишек алдына коймалар аша сикерә-сикерә чабам. Тоттырмаска тырышам. Немец: «Ком, ком!» – ди. Аның янына тагын берсе кушылды. Ярый әле физкультура дәресләрендә йөгерергә остарып беткән идем, күп кенә ярышларда алдынгы урыннарны алгалыйм. Шулай итеп, куыша-куыша, чаба-чаба урманга килеп җиттек. Куаклар арасына яшерендем. Немецлар да туктап калдылар. Үзләренчә сөйләшәләр: «Зеер гут, зеер шон!» (Бик яхшы, бик ямьле). Табигатебезне, әйләнә-тирә ягыбызны мактыйлар! Безнең шундый гүзәл туган ягыбызның байлыкларын талап, халыкларны үтереп һәм кол итеп яшәтмәкчеләр.

Китаплардан укыганнарым, кинофильмнардан караганнарым исемә төште. Алар шәһәр-авылларны яндыралар, самолетлардан бомбалар ташлыйлар, танклардан аталар, иген кырларын таптыйлар, йортларны җимерәләр. Ә балаларны исә алып китәләр. Каннарын алып үзләренә яралы сугышчыларына салалар һәм башка шундый явызлыклар эшлиләр.

Шундый дошманнарның икесе – куак артында гына. «Эх, кулымда мылтыгым булса иде, дөмектерер идем!» – дип уйлауга куак арасында бер пистолет күренде. Аны кулыма алып, курокка басуым булды – бер атуда ике немецны үтердем! Һәм… шул вакыт йокыдан уянып киттем. Белсәгез иде шул чакта ничек сөенгәнемне! Бу хәл төшемдә генә икән!

Ватаныбыз инде күптән дошманнардан азат. Безнең бабаларыбыз тынычлыкны моннан 75 ел элек яулап алган, аларны туган илебездән куып чыгарган.

Илебездә генә түгел, бөтен дөньяда тынычлык булсын, халыклар дус-тату гомер кичерсеннәр иде. Тормышның кадерен белеп, шушы аяз күкебезгә сөенеп, тормышның ямен-тәмен белеп, куанып яшәргә язсын иде. Дошманнарны төштә дә күрмәскә иде!

**Закирова Камилә Равил кызы,12 яшь**
*Җитәкчесе:Миңнеханова Гөлназ Миңнебай кызы*

## «БАТЫР ЙӨРӘКЛЕ КУЯН»

Яшәгән, ди, бер Куян. Көннәрен, дуслары белән уйнап, урманда, болында үткәргән.

Бервакыт Куянны әтисе чакырып ала да: «Улым, мин картайдым инде, әниең дә яшь түгел. Син – безнең бердәнбер балабыз. Сиңа өйләнергә вакыт. Безне оныклар белән шатландырсаң, бик тә бәхетле булыр идек,» – ди. Куян әтисен хөрмәт иткән һәм аның сүзен тыңларга булган. Ул бит, дөрестән дә, хәзер әти-әнисенең бердәнбер баласы…

Бу хәл күп еллар элек булган… Куянның абыйлары-апалары, энекәшләре-сеңелкәшләре бик күп булган. Көннәрдән беркөнне алар өйдә үзләре генә калганнар: әти-әниләре ашарга эзләргә чыгып киткәннәр. Бервакыт тавыш ишетелгән. Зуррак куян балалары аңлап алганнар: бу ниндидер ерткыч хайван, аларны ашарга килгән. Алар кечкенәләргә тавышланмыйча гына качып-посып утырырга кушканнар. Тик нәни куян балалары моны аңлап бетермәгәннәр шул… Ишегалдына якын килеп, Төлкенең үзенә үк барып чыкканнар. Ә ул аларны берәм-берәмләп тотып ашый башлаган. Ә аннан соң инде, бөтен ояны таркатып, калган зур куян балаларын да ашап бетергән. Бары тик безнең Куяныбыз гына исән калган, чөнки ул почмакта качып, тын алырга да куркып утырган. Төлке, бөтенесен дә ашап бетердем дип, китеп барган…

Инде кайтыйк безнең көннәргә… Куян әтисенең сүзләреннән соң уйлаган- уйлаган да, болында үзе белән уйнап үскән Куян кызына өйләнергә булган.

Гөрләтеп туй үткәргәннәр болар. Ә күпмедер вакыттан соң, Куяннын балалары туа. Алты онык белән шатландыра ул әти-әнисен.

Шулай бергә-бергә күңелле яшәп ятканда, боларның ояларын Төлке таба. Куян өйдә булмый ул чакта. Төлке шулай ояны саклап йөргән, тиздән берәрсе чыгар да тотып ашармын дип өметләнгән. Күп тә үтми безнең Куяныбыз өенә кайтырга юнәлә. Караса,

оялары янында Төлке йөри. Бу бит шул Төлке! Ул аны бик яхшы исендә калдырган була. «Бу Төлке минем туганнарымны юк итте. Балаларымны да, бөтен гаиләмне дә мин Төлкегә бирмәячәкмен!!! Күп еллар элек мин кечкенә генә бер куян баласы идем. Төлкегә каршы берни дә эшли алмадым ул чакта. Ә хәзер мин үстем, җитезләндем, мин Төлкенең үзеннән дә акыллырак һәм, кирәк булса, хәйләкәррәк тә була алам», – дип уйлап куя. Шунда ук Куян Төлке каршына чыга да: «Кара әле, Төлке, син мине эзлисең бугай?!» – дип кычкыра. Төлке, моны күрү белән, ояны саклаганын оныта. Куян үзе аның каршысына килеп чыга бит! Җитмәсә, Төлке берничә көн ашамаган була. Ачлыктан ул Куянга ташлана. Безнең яшь, җитез һәм хәйләкәр Куяныбыз болынга таба чабып китә. Төлке аның артыннан куа, тик, берничә көн ашамаганга, хәле бетә. Шулай йөгерә торгач, Куян үзенең уйнап үскән болынына килеп чыга, ә Төлке һаман аның артыннан йөгерә. Шунда ук Куяну дустын очрата. «Дустым, булыш бу Төлкедән котылырга», – дип әйтә ул аңа тиз генә. Шулай дип әйтүе була, Куянның дусты, Төлкегә якынрак килеп, кычкыра башлый: «Кара әле, Төлке, мине тота алырсыңмы икән?!» – ди. Төлке моны күрә дә, бу Куян миңа якынрак дип, аның артыннан йөгерә башлый. Ә безнең Куяныбыз Төлкегә тагын кычкыра: «Син мине куып тота алмадың инде! Аны да тота алмассың!!!» Шулай диюгә, Төлкенең ачуы килә һәм ул безнең Куяныбыз артыннан йөгерә башлый. Бу вакытта Куянның дусты тагын аңа кычкыра. Болай да ач Төлкенең тәмам башы әйләнә һәм ул ике куянны да күздән югалта.

Юкка гына «Ике куян артыннан кусаң, берсен дә тота алмассың», – дип әйтмиләр бит. Шулай итеп батыр йөрәкле, акыллы, хәйләкәр һәм тапкыр Куяныбыз үзенең гаиләсен Төлкедән коткарып кала. Ул бүтән тапмасын дип, икенче оя кора һәм алар анда күченеп китәләр. Әле дә булса шунда бергә-бергә яшиләр, ди.

Куянның батырлыгы, акылы һәм үзенең көченә ышануы аңа бик ярдәм итә. Кайвакыт бу сыйфатлар Куянга гына түгел, сиңа да, миңа да бик кирәк булып чыга шул.

**Миниәхмәтова Азалия Ринат кызы, 12 яшь**
*Җитәкчесе: Әбрарова Фәнзия Якуп кызы*

## «ТИЕН БЕЛӘН КУЯН ДУСЛЫГЫ»

Караурманның бер аланында Төлке белән Тиен очрашканнар. Төлке белән Тиен качышлы уены уйныйлар икән. Агачтан агачка сикереп, алар бик арыганнар. Бигрәк тә тиен талчыккан, сусаган. Төлке:

– Әйдә мин сине Бүре абзыйларга кунакка алып барам. Аларда шифалы су эчәрбез, – дигән.

Боларны куак арасыннан Куян тыңлап тора икән. Төлкенең хәйләсенә ул бик тиз төшенгән. Тиеннең тиздән Төлке һәм Бүрегә азык булачагын аңлаган. Ул болар янына йөгереп чыккан да:

– Әй, җәнлекләр, ни хәлләрегез бар? – дип сораган.

Төлке Бүрегә кунакка барачакларын әйткән.

Куян:

– Миндә кишер пәрәмәче, кишер чәе бар. Тиен башта миндә хәл алсын. Аннан икәүләп Бүре абзыйга барырбыз, – дигән.

Төлке аларны Бүреләрдә көтәчәген әйткән.

Шулай итеп, Куян Тиенне үлемнән коткарган. Тиен аңа рәхмәтен белдергән. Алар икесе бик дуслашканнар. Хәйләкәр Төлкене оста алдауларына сөенгәннәр, шатлыктан рәхәтләнеп көлгәннәр. Бүре белән Төлке Тиенне, Куянны көтә-көтә арып беткәннәр. Бүре Төлкене алдакчы дип атаган. Шул көннән алар арасындагы дуслык бозылган.

**Хәкимуллин Шамил Фаил улы, 12 яшь**

*Җитәкчесе: Хәкимуллина Хәмдия Равил кызы*

## «КЫРМЫСКАЛАР АЛАНЫНДА»

Ниһаять, җәйге каникуллар җитте. Шәһәр балаларының ял итеп, көч җыеп килә торган урыны ул – авыл. Шамил дә сеңлесе Мәдинә белән авылга– әби-бабайлары янына кунакка кайтып китте.

Бүген әнисе казан кабартамалары пешерде. Тәмле итеп чәй эчкәч, авылдан бик ерак булмаган Ибраш урманына сәяхәткә барырга дип хәл иттеләр. Әбиләре юл күрсәтә-күрсәтә, балачагын сөйләп бара торгач, урман авызына да килеп җиттеләр. Менә ул – Ибраш урманы. Урман акрын гына шаулап, кешеләрне сәламләде. Калын урман эченнән юл сузылып киткән. Юл кырыенда үскән абага куакларын, сары һәм «бишни», ак чәчәкләрне карый-карый, урман эченә үттеләр. Ә алда – алан. Аланда зәңгәр һәм яшел төсләр белән буялаган умарта оялары күренде. Кызганыч, умарта оялары буш булып чыкты. Әллә умартачылар ояларны вакытында карап тормаганннар, әллә кыш салкын килгән, белмәссең.

Алан кырыенда зур һәм кечкенә кырмыска оялары күренеп тора иде. Шамил белән Мәдинә кызыксынып кырмыска ояларын күзәтә башладылар. Урман кырмыскалары зур, кызгылт төстә. Алар тыз-быз йөгерешә, каядыр ашыга, тиз-тиз нәрсәдер эшли. Бер төркем кырмыскалар вак чыбык-чабык ташый, кайберләре ашарга эзләп чыгып йөгерә, ә кайсылары аркаларына азык төяп кайтып та киләләр. Кырмыскаларның ояларын карап тору бик күңелле һәм кызыклы булды. Аларның өйләре зур сарайны хәтерләтте.

Әниләренең дә кечкенә вакытта шушы урманга килгәне булган икән. Ул мәрхүмә әбисе Мәгъмүрәнең кырмыска оясы өстенә утырып, аяларына шифа алганын искә төшерде. Кырмыскалар махсус сыеклык чыгаралар, аз күләмдә кулланганда, алар кешеләргә ярдәм итәләр икән.

Балалар, аларың әни-әтиләре һәм әбисе урманда фотога төшеп, сары мәтрүшкә чәчәкләрен җыеп әле озак йөрделәр. Аннары басу буенда үскән зәңгәр күк чәчәкләрнең матурлыгына сокланып, үз өйләренә кайтып киттеләр. Урмандагы кырмыска оясы «гүләп», үз дөньясында кайнап, урман эчендә җанлы йорт булып торып калды.

**Габитова Рания Радик кызы, 15 яшь**

*Җитәкчесе: Габитова Рәзинә Рүзәл кызы*

## «БАКАЛАР ЯЗМЫШЫ»

Көннәрдән бер көнне, әллә кайчан: табигатьнең агусыз, һаваның зарарсыз вакытында, үләннәр арасындагы чыкларда коенып, зур шома ташлар өстендә кызынып, яшәгәннәр, ди, бик матур, сылу бакалар. Тормыштан шундый канәгать, ди, болар, рәхәтләнеп иртә-киченбик матур итеп, сузып-сузып, сандугачлардан да уздырып, җырлыйлар да икән болар. Болынлыкта көнозын кошлар тавышы, чебен-черки, бал кортларының, тагын әллә нинди бөҗәкләрнең безелдәве, бакалар җыры белән яңгырап торган, ди.

Беркөнне карга тыңлап-тыңлап торган да, көнләшүдән шартлар дәрәҗәгә җитеп:

– Әй, бакалар, бигрәк матур җырлыйсыз, бар җиһанның ямен җибәрәсез, ди, икән. Сандугачларга комачаулыйсыз, алар һавада очалар, агачларны бизәп, оя коралар. Ә сез үлән арасында яшисез, сезнең матурлыгыгызны беркем күрми, ни дип шатланасыз, дигән.

– Без бит шушы табигатьне яратып, шушы гүзәл җирдә яшәвебезгә шатланып җырлыйбыз, – дигәннәр бакалар.

– Әгәр сез тавышыгыз белән безнең матур сайравыбызга комачауламасагыз, безгә ничек рәхәт булыр иде, бөтен кешеләр, җанварлар безне генә тыңларлар иде, – дигәннәр кошлар.

– Әгәр сез җырламасагыз, безнең матур безелдәшүебез еракларга ишетелер иде, – дигәннәр, бөҗәкләр, бал кортлары.

Сез шулкадәр матур җырламасагыз, усал малайларның таш атарга килүләрен ачыграк ишетер идек, дигәннәр шаян тиеннәр.

– Ә без төлке, бүреләрнең ауга чыгуларын ерактан ук сизенер идек, дигәннәр куяннар.

Шулай итеп, барлык җанварлар бергә җыелышып, Убырлы карчык янына килгәннәр, ди .

– Убырлы әбекәй, чибәркәй, бу бакалар бөтен дөньяны басып алырлар, бөтен җирне матурлыкка күмәрләр, без ямьсезләр нишләрбез соң? –дигәннәр. Убырлы карчык уйлаган да, әфсен-

төфсеннәрен укып бер нәни бака баласының ботыннан тотып, бер төкергән икән, бөтен бакалар шунда ук ямьсезләнеп калганнар, матур күлмәкләре тимгел-тимгел соры, кара төскә кергән, йомшак, нәфис тиреләре җыерчыкланып, чирканыч булып калган. Бакалар бик кайгырганнар, утырып, елап та алганнар. Җырлап күңел күтәрелмәс микән дип, сайрап та караганнар. Ләкин җыр урынына бакылдау гына ишетелгән.

Шулвакыт бер бака суда коенып чыгарга уйлаган. Су астындагы тынлыкка исе киткән бәләкәй баканың.

– Әйдәгез, елга, күл буйларында яшик. Суларга төшеп, төнбоекларга утырып, бакылдарбыз, – дигәннәр бакалар.

Икенче бака баласы эссе көнгә чыдый алмыйча, караңгы базга хәл алырга төшкән. Андагы тынлыкка исе китеп, монда күпме теләсәң, шулкадәр бакылдарга була, ямьсез кыяфәтебезне беркем дә күрмәс, дип уйлаган.

– Әйдәгез, кайберләребез караңгы базларга, җир асларындагы куышлыкларга кереп яшик. Анда бездән беркем дә көнләшмәс, – дигән бака башлыгы.

Шул көннән башлап бакалар су төпләрендә, караңгы базларда, ташландык коеларда яшәп яталар икән. Ләкин хәзер бик бакылдашасылары да, сикерә-сикерә уйныйсылары да килми башлаган. Шуңа күрә бакалар бик салмак, әкрен йөрергә, иренеп кенә сикерергә өйрәнеп киткәннәр. Күбрәк почмакларга елышып, салкын дымлы урыннарда яшеренеп кенә яшәргә күнеккәннәр.

Язгы айларның бик матур, кояшлы көннәрендә болынлыкларны сагынып, бик сирәк кенә, кояш баеганда, елый-елый бакылдашалар икән. Менә ни өчен бака тавышын без яз, җәй көннәрендә генә ишетәбез икән.

Шуңа күрә, беркайчан да кешеләрнең һөнәрләрен яманларга, көнләшергә ярамый икән. Һәр кеше, һәр җанвар үз урынында матур, үз урынында файдалы ул.

# 15-18 яшьлекләр

**Ситтыкова Эльвина Айрат кызы, 16 яшь**
*Җитәкчесе: Ситтыкова Гөлүсә Гинар кызы*

## «КЫЗЫЛ ЧӘЧЛЕ ЗӘРИНӘ»

Яз – елның соклангыч вакыты! Табигать уянып, тормыш белән тула. Якты кояш көн саен җылырак була, кар эреп, йорт һәм агачлар түбәләрендә боз сөңгеләренә әверелә. Балалар сикерешергә ярата торган зур күлләвекләр барлыкка килә. Ерак аралардан кошлар очып килә, һәркайда аларның моңлы сайраулары ишетелә. Соңрак агачларда беренче яфраклар чыга башлый. Яңа елда беренче яңгырны да онытырга ярамый, ул шундый күңелле, дәртле, җылы булып күренә! Ә саф җил, теге йомшак җилме? Яз җитү белән бөтен дөнья буяулар, хуш исләр, илһам белән тула!

Әнә шул кояшлы көннәрнең берсендә, сары лаләләр үсеп чыккач, урманда барлык хайваннар уянгач, сандугачлар шатлыклы вакыйга турында Кояш авылының һәр кешесенә дә хәбәр иттеләр инде. Нәрсә булды дип сорыйсызмы? Хәзер белерсез дә. Бу авылда ирле-хатынлы Булат белән Гөлназ яшәгән. Аларны барысы да ярата һәм ихтирам итә иде: алар барысына да чын күңелдән ярдәм иткәннәр, читләргә килгән бәла-казалар яныннан беркайчан да узмыйлар, беркемне дә гаепләмиләр. Булат белән Гөлназ һәрвакыт тирә-юньдәгеләргә аңлап карыйлар. Әгәр берәрсе алардан киңәш сораса, дөрес юлны күрсәтергә тырышалар.

Бу кояшлы көндә аларның кызлары туды. Бөтен авыл нәнине карарга һәм әти-әниләрен котларга җыелды. Кызы бик чибәр иде: иреннәре алсу иреннәре, бит очлары йом-йомшак, түгәрәк йөзен ямьләп коңгырт күзләре балкып тора. Әмма, тора-бара Зәринәне (кызларына шулай дип исем биргәннәр) күргәч, бөтен кеше курка торганга әйләнә. Чөнки кызчыкның чәчләре кып-кызыл булып үсә башлый. Нәкъ әкияттәге убырлыныкы төсле. Шул вакыттан соң бу гаилә белән беркем дә сөйләшми, хәтта аларны күрергә дә теләми башлый. Шулай итеп, алар өчәүләп яши башлыйлар. Вакыт уза,

Зәринә эти-әнисе кебек яхшы, юмарт кыз булып үсә, ләкин аның дуслары булмый, чөнки барысы да аннан курка, гәрчә ул гади бала булса да. Кыз, елап, күп тапкыр әнисеннән сорый: «Ни өчен без үзебез генә? Ни өчен беркем дә безнең белән аралашырга теләми? Болар барысы да минем чәчем аркасындамы? Мин убырлы карчыкмы?!» Ә әнисе аны һәрвакыт тынычландыра килде: «Син убырлы карчык түгел, син – мин белгән иң чибәр кеше. Монда синең гаебең юк, кешеләр безнең тышкы кыяфәтебезгә еш кына карап торалар, безне эчтән белергә теләмиләр».

Кешеләр урамда тыныч кына йөри алсын өчен, Зәринә өйдән төнлә генә чыга. Ул һәрвакыт елга буендагы бер үк урынга бара иде. Анда ул, үзен аңламауларын белсә дә, көлә-көлә балыклар белән сөйләшә. Аннары ул күккә карый, йолдызларга һәм айга соклана.

Шундый төннәрнең берсендә ул яр буенда ята иде. «Йолдызлар, сез шундый бәхетле, сез һәрвакыт азат һәм матур, сез ямьсез булсагыз да, кешеләр сезгә караудан туктамаячаклар», – ди. Ләкин кисәк яңгыраган «Ни сөйлисең?» дигән тавышка сискәнеп китә.

– Син кем? Нишләп йөрисең монда, хәзер төн ич, – дип куркып сорады Зәринә.

– Мин синнән шуны ук сорарга теләгән идем. Минем исемем Азамат, төнлә тынычрак булганга, балык тотарга килдем.

– Мин – Зәринә, һәрвакыт төнлә йөрим, чөнки барысы да кызыл чәчемнән куркалар.

– Барысы да убырлы дип уйлыймы сине? – дип көлеп җибәрде малай. –Бу бит ахмаклык.

– Ләкин күбесе моңа ышана.

– Мин синнән курыкмыйм, әйдә, дус булыйк.

– Әйдә, – диде Зәринә елмаеп. Аның коңгырт күзләре балкый башлады, хәзерге кебек ул беркайчан да бәхетле булмады. Бу – аның беренче дусты, һәм кем белә, бәлки аның тагын да күбрәк тә булыр.

– Һәр төнне шушында очрашачакбыз.

– Яхшы, мин риза.

Бу төнне балалар дөньядагы бөтен нәрсә турында сөйләштеләр. Зәринәгә барысы да кызыклы иде, чөнки ул дөнья турында бик аз белә иде, тик әнисе сөйләгән һәм китапта укыган нәрсәләр генә. Ә

Азамат мәктәпкә йөрде, анда укытучы барысын да аңлатып бирде. Алар йолдызлар, табигать, кошлар һәм дуслыкның нәрсә икәнлеген турында сөйләштеләр, малай балык тотарга өйрәтте. Зәринә үзенең кызыл чәчләрен турында беренче тапкыр онытты.

– Соң инде, – диде Азамат, – иртәгә күрешербез. Исеңдә тот, син – бик яхшы кеше. Хуш!

– Сау бул!

Өйгә кайткач, Зәринә көчкә йокыга китте. Ул бүген ниләр булганын, иртәгә Азамат белән яңадан очрашырбыз дип шатлануын уйлый иде.

Икенче көнне Зәринә озын толымнарын матур итеп үрде, иң яхшы күлмәген киде, дустына тәмле ризыклар әзерләде. Кояш баегач, елга ягына таба китте. Ярга җиткәндә, ул ашъяулыгын япты да күчтәнәчләр куйды. Ул Азаматны яңадан очратачагына үзе дә ышанмый иде. Кояш тора башлаганчы, ул дустын бик озак көтте. Азамат килмәде. «Димәк, син миңа ялганладың. Син дә миннән куркасың, ә кичә, мин үпкәләмәсен өчен, калдың», – дип уйдан гына Азамат белән сөйләште. Шула арада мөлдерәп яшьләре ага башлады.

Аның елаган тавышын елга буеннан очып үткән тылсымчы хатын ишетте. Өстендә кыска җиңле зәңгәр күлмәк, кара чәчләрендә ак энҗе бөртекләре күренә, ә арттан чәчәкләр белән бизәлгән яшел канатлар.

– Ни булды? Ни өчен шундый сөйкемле кыз елый? – дип сорады тылсымчы.

-Бөтенесе минем кызыл чәчемнән куркалар, – дип, Зәринә елый-елый сөйли иде. – Дустым бардыр дип уйлаган идем. Без бүген очрашырга тиеш идек, ләкин ул килмәде. Димәк, ул да миннән курка.

– Син кешеләр синең чәчләрең аркасында куркалар дип уйлыйсыңмы? Бәлки, бу дөрестер дә, ләкин мин тылсымчы буларак әйтә алам, чәч төсе синең убырлы булу/булмавыңны билгели алмый.

– Ә тылсымчылар ничек барлыкка килә? – дип сорап куйды Зәринә, елавыннан туктап.

– Барысы да бик гади: әгәр кеше бу дөньяга яхшылык китерә икән, әйләнә-тирәдәгеләр турында кайгырта, беркайчан да беркемне дә баладә калдырмый икән, бер мизгелдә аңа күктән йолдыз төшә һәм бу кешене тылсымчыга әвереледерә. Шуны да истә тотарга кирәк: әгәр кеше үз гомерендә бик күп начар эшләр эшли һәм үзе турында гына уйлый икән, йолдыз сине убырлыга әйләндерәчәк.

– Мин дә тылсымчы булырга һәм барысын да сөендерергә телим, ләкин моны миңа ничек эшләргә? Минем белән беркем дә аралашмый.

– Мин бу дөньяда барысын да күрәм һәм беләм. Азаматка синең белән дус булу ошый. Кичә ул синең белән бик рәхәтләнеп сөйләште. Минемчә, аның килмәскә башка сәбәбе булгандыр. Иртәгә шушы вакытта ярга кил, ул да килер.

– Зур рәхмәт сиңа. Синең белән танышуыма мин бик шатмын. Ә исемең ничек синең?

– Минем исемем – Ләлә. Озакламый тагын очрашырбыз әле. Хуш, Зәринә.

– Хушыгыз.

Икенче төнне Зәринә, гадәттәгечә, елгага таба китте. Кыз үз күзләренә үзе ышанмады: яр буенда Азамат утыра иде. Зәринәне күргәч, малай, тиз генә торып, аны кочаклап алды. «Кичә минем әнием авырый иде, мин аның белән калдым. Килмәвем өчен гафу ит», – диде Азамат. Дусты аннан курка дип уйлаганга, Зәринәнең кабат кәефе кырылды.

– Мин барысын да аңлыйм, һәм синең әниең белән калуыңа шатмын. Хәзер аның белән бар да яхшы дип өметләнәм?

– Әйе.

– Азамат, минем кичәге көнем турында сиңа шулкадәр күп нәрсә сөйлисем бар.

Зәринә дустына тылсымчы Ләлә белән очрашуы турында, барысын да бәян итте.

– Беләсеңме, Азамат, мин дә тылсымчы булырга телим, ул чагында берсе дә миннән курыкмас.

– Бу – яхшы яңалык. Әйдә иртәгә мин сине дусларым белән таныштырырмын.

– Мин сиңа моның өчен бик рәхмәтле булачакмын.

Икенче көнне иртән Зәринә тыштагы балалар сөйләшүеннән уянды. Бу Азаматның дуслары иде: ике малай һәм ике кыз . Берсе, тизрәк чыксын дип, Зәринәгә кул болгый. Кыз йөгереп чыгып китә.

– Хәерле иртә, Зәринә. Бу – Алия, Алинә, Тимур һәм Марат.

Балалар бик тиз дуслашып киттеләр. Азамат дусларына Зәринәнең убырлы булмавын, аның белән аралашу бик күңелле булуын аңлатты. Алар туктамыйча көне буе уйнадылар, бер-берсенә кунакка йөрделәр һәм кызыл чәчле кызга инде беркем дә нинди дер начар сүз әйтмәде. Аларның көлешә-көлешә уйнауларына башка балалар да килеп кушылдылар. Бу көнне Зәринә дөньядагы иң бәхетле кыз иде. Ул һәр авыл кешесе белән дуслашырга өлгерде: кечкенәләрдән алып олысына кадәр, һәркайсына ярдәм итәргә, яхшылык эшләргә тырышты. Инде кич җитте, барысы да өйләренә кайтырга җыендылар. Кинәт Азамат кычкырып җибәрде:

Карагыз, карагыз, йолдыз төшә.

Чыннан да, күк йөзеннән якты йолдыз төшеп килә, ләкин ул Зәринәгә якынлашкач, кешеләр тагын да күбрәк гаҗәпләнделәр. Ут якынайганнан якыная барды, аннан тылсымчы күренде.

– Без әле очрашырбыз дип әйткән идем бит, – диде Ләлә елмаеп. – Тылсымчы булырга лаеклы икәнлегеңне исбатлагансың.

Зәринәнең кызыл чәчләре бөдрәләнеп сары энҗе белән капланганнар, яшел итәге алтын күлмәк белән алмашынган һәм иң гаҗәбе – аның аркасы артыннан күбәләк кебек ике зур ак канат килеп чыккан. Мондый матурлыкка бөтен кеше сокланды.

– Рәхмәт, Ләлә! Мин сиңа ничек рәхмәт әйтә алам? – диде Зәринә, очарга тырышып.

– Иң мөһиме – бу дөньяга яхшылык һәм яктылык алып кил. Кешеләр яхшы һәм игелекле эшләр башкарганда, бу дөнья гүзәлләнә. Икенчеләре моны күреп, шулай ук эшләргә тырышалар, бу исә яхшылыкны шактый арттыра һәм аны бөтен планета буйлап тарата. Шуңа күрә, минем уйлавымча, яхшылык дөньяны коткарачак, иң мөһиме моңа ышанырга, һәм көн саен әйләнә-тирәдәгеләр өчен яхшы гамәлләр кылырга тырышырга кирәк.

Шулай дип, Ләлә юкка чыкты. Шуннан соң Зәринә үзенең әти-әнисе белән көн саен авылны карап йөрде, башкаларга чын күңелдән ярдәм итте.

**Тагиров Т.А., 15 яшь**

**Җитәкчесе:Рәхмәтуллина Рәмзия Рафик кызы**

## «КЕЧКЕНӘ ПАРТИЗАН- АЗАТ»

Азатның әнисе кирәкле әйберләрне әзерләп, арып-талып бүлмәсенә кереп ятты. Яткач та ана бик озак йоклый алмый ятты. Ә бит иртәгә кич улына шундый зур эш йөкләнә. Шул уй аның башыннан һич китмәде.

Кич. Ана ун яшьлек улын юлга әзерләде. Азат әнисенең бер сүзен дә онытмаска тырышып, бик игътибар белән тыңлады…

Азат тиешле урынга барып җиткәндә, урманда – әнисе әйткән жирдә нигәдер беркем дә юк иде. «Бәлки, кайсы жиргә барырга кирәклекне аңлап бетермәгәнмендер», – дип уйлап, аптыраган рәвештә, юлны кыскартып, куе урман эченнән ерак түгел бер аланга юл тотты. Шулай ашыга-ашыга йөгереп барганда, кинәт, җир убылып аска төшеп киткән кебек тоелды. Күзләрен ачканда инде, төн уртасы иде. Капшана-капшана Азат үзенең базда ятканын абайлап алды. Әмма ничек кенә чыгарга талпынса да, ул аннан чыга алмады. Азатның йөрәге чыгардай булып типте. Куркуыннан ул: «Әни! Әнием!» – дип кычкырып җибәрүен үзе дә сизмичә калды. Шулчак ниндидер кечкенә генә ут күренде. «Нишләп билгеләнгән җирдән киттең?» – дигән тавыш ишетелде. Разведкадан кайткан партизаннар, аның килүен көтеп-көтеп тә түземлекләре беткәч, ни булганны тиз аңлап, эзләргә чыкканнар икән.

Алар Азатның әнисе җибәргән кием-салымны, аш-суларны алып, бик зур рәхмәтләр әйтеп малайны кайтыр юлга озатып саубуллаштылар.

Кечкенә партизанның бу килүе соңгысы түгел иде әле.

# 19-22 яшьлекләр

**Камаев Ринат Азат улы, 20 яшь**

## «САГЫЗ»

«Мин бизнесмен булдым әле,
Сагыз саттым мәктәптә.
«Акча, – дидем, – беркемгә дә
бирмим, – дидем, – рәхмәткә»

*Факил Сафин*

– Сагыз, «НУ ПОГОДИ!» сагызы. Бер сагыз – өч тиен. Бары тик бүген генә: ике сагыз алсагыз, өченчесе – бушка. Авызны сафландыра торган сагыз! Бөтнекле сагыз, шәһәр сагызы!

Тавышы беткәнче кычкырды Рәзил, бөтен коридорга ишетелерлек итеп кычкырды. Барысы да белсен, барысы да ишетсен, Рәзил сагыз сата! Авылда туып-үскәннәрнең сумаладан башканы күргәне юк, тешләрен тартып чыгарырдай ул сумаланы авызларына кабарга ничек башларына килгән диең! Сыйныфтагыларның башлары сагыз исеннән исерер дә шунда ук онытырлар үртәүләрен. Алайса, гел бәйләнеп йөриләр.

– Сагыз, тәмле исле сагыз! Башкаладан кайткан! Өч сагыз ике сагыз бәясенә! Оялма, кил, бары тик алты тиен.

Әтисе посылка итеп җибәргән иде аңа ул сагызларны. Яңа ел бүләге итеп. Үзе килеп китә алмаса да, бүләкләрдән калдырмый иде улын. Туган көнгә – кояшта ялтырап торган сәпит, яңа елга – каб тулы тәм-том, уку елы башланганда бер капчык төрле төсле карандашлар, буялар җибәрә иде аңа әтисе. Авыл башлыгы кызы Алиядә дә андый буяулар юк әле. Ә күпме машина җибәрде аңа әтисе! Кечкенә чакта тезеп куяр иде ул аларны капка төбенә. Авыл малайлары күзләрен түгәрәкләндереп узып китәләр иде.

– Хуш исле сагыз! Сез дә шәһәр күчтәнәчләрен татып карагыз! Бер кабы егерме биш тиен! Килегез, карагыз, хуш исле сагыз!

«Аз гына үс инде, соңыннан кире башкалага алып китәрмен», – диде аңа әтисе. Өч ел үтте, әтисе һаман алып китми. Әллә оныткан

ул аның турында? Юк ла, нишләп онытсын, ди, инде үзенең улын, ай саен нидер җибәреп тора бит. Күрше урамда торучы абыйсы да үскәнем дип кенә йөри. Мәскәүгә кире китәр өчен, тагын күпме үсәргә кирәк икән?! Кешеләр, үскәч, акча эшли дип, сагыз сатарга чыкты бит инде ул. Бәлки шул чакта әтисе килер дә аны бу авылдан алып китәр. Тәвәккәлләп карасаң була инде.

– Сагыз, бөтнек тәме белән сагыз! Сумала тешкә кысыла, ә монсы йомшак, озакка җитә! Килегез, алыгыз! Өч тиенгә бер сагыз, алты тиенгә өч сагыз!

Самат ник йөри инде монда? Тагын берәр нәрсәне чәлдерергә тора әллә? Читкә карый-карый күзләре дә кылыйланып беткән инде. Тагын килә. Бу юлы нинди сәбәп уйлап табар? Нәрсә ди? «Булат сорады, акчасын соңыннан бирермен дип әйтте», – диме? И-й, күзгә карап алдый теге. Булмас, берсен дә бушка бирмим, башта түләсен.

– Әй, куй сагызны! Самат, тотам бит барыбер!

Бер генә бирде Рәзил кулына, Самат сизми дә калды сагызының төшеп киткәнен. «Ах, син!» – дип, күкрәгенә һава җыеп, сугарга теләгән Саматның башына Рәзилнең икенче йодрыгы менеп төште. Ике яшькә олырак дип тормады, үзенекен кире кайтарды Рәзил.

Куркуы әллә ни күрсәтмичә, тыныч кына кире урынына – сагызлар тезелгән тәрәз төбе янына килеп басты. Тизрәк әтисе белән күрешер өчен, Саматише алдакчыларга бирешмәскә кирәк, кыю булырга кирәк. Кыю булсаң, димәк син тагын да зуррак, димәк син тагын бер башка үсәсең.

– Сагыз! Бөтнекле сагыз! «НУ ПОГОДИ!» сагызы, кем ала!?

**Хуҗина Зәринә Рамил кызы, 20 яшь**
*Җитәкчесе: Хуҗина Гөлназ Рәфис кызы*

## «ДУСЛАР»

Камилә иртә торды. Җәйге кояш нурлары кызның күзләрен шунда ук кытыклап уятты. Ул бүген җиләккә бара бит. Кичә кичтән кәрзиннәрен, ял вакытында ашарга дип ипи, йомырка, кыяр-помидорларын да әзерләп куйды.

Менә Камилә күтәренке кәеф белән юлга чыкты. Каршысына Илнур очрады.

– Урманга барасыңмы, Камилә? Барма, анда куркыныч. Анда бүре, аю, җен- пәриләр яши. Белмисеңмени?

– Яшәсә, нишләтим, ди? Миңа җиләк җыярга, шушы кәрзинне тутырырга кирәк. Тимәсләр әле.

– Курыкмыйсыңмыни?

– Ю-у-ук.

– Мин дә синең белән барам. Берәр нәрсә була калса, саклыйм! Мин бит егет кеше, – диде алты яшьлек Илнур үзеннән бер яшькә кечерәк кызга.

– Әйдә, бар соң, күңелсез булмас.

Киттеләр болар икәүләп җиләк җыярга. Камилә инде хыялланып эре-эре, кып-кызыл җиләкләрне күз алдына китереп барды. Менә алар бер кечерәк кенә аланлыкта кып-кызыл җиләкләргә тап булдылар. Тик шунда, койрыгын болгый- болгый, хәйләкәр төлке килеп чыкты.

– Әй, сез, нишлисез монда? Бу бит минем территория, минем җиләкләрем. Камилә, мин бит сине таныйм. Авыл башында гына торасың түгелме?! Куяннар асрыйсыз, ахрысы… Җиләкләрне куяннарга алмаштыра алам.

Төлкенең бу сүзләрен ишеткәч, Илнур Камиләнең кулыннан тарта башлады:

– Әй, Камилә, тизрәк китик моннан, җиләксез яшәп булыр, ичмасам, куяннарның гомерен саклап калыйк, я безне ашар ул төлке.

– Тик тор әле, Илнур, – ди елмаеп Камилә. – Төлке, мин сиңа куяннарны бирер идем дә бирүен, менә шул кәрзинемне тутырмыйча өйгә кертмәсләр шул мине.

– Бигрәк зур икән кәрзинең. Мондагы җиләкләр белән генә дә тулмас бу. Әй, син, малай, карап торма, җыярга булышыйк Камиләгә, тизрәк, – диде төлке, куяннар турында уйлап.

Болар өчәүләп бар җиләкне җыеп та бетерделәр. Тик кәрзин генә тулмады. Киттеләр урманның эченәрәк кереп. Матур итеп кошлар сайрый, төрледән- төрле гөмбә, чәчәкләр үсә, колак төбендә бөҗәкләр бызылдаган тавышлар ишетелә. Боларның һәммәсен күзәтә кыз, аңа монда ошый, аңа монда рәхәт. Күп тә үтми, тагын аланлыкка тап булалар, монда җиләкләр кызыл, өзеп авызга гына кабасы килеп тора.

Илнур бер җиләкне авызына кабуга, кайдандыр соры бүре килеп чыкты.

– Әй, нәрсә калган сезгә минем җирлектә?! Төлке туташ, балаларга ияреп сиңа йөрү бер дә килешмәс.

– Тукта әле, тукта әле, Бүре әфәнде, тыңла әле мине. Бу Камилә бит: авыл башында тора торган кыз. Алар күп хайван асрыйлар, ялгышмасам, сарыклары да бар бит әйеме, Камилә? – диде төлке.

– Әйе, 55 сарык асрыйбыз без, барысы да симезләр, итләре бигрәк тәмле инде.

Селәгәйләре агып торган Бүрегә Төлке: «Бүре әфәнде, безгә шушы кәрзинне тутырырга кирәк, алайса Камиләне өйгә кертмиләр. Кәрзинне тутырып бетерсәк, сиңа – сарыкларны, ә миңа куяннарын бирәчәк. Шулай бит?» – диде.

– Бирәм инде, әлбәттә, төнгә калмыйча, тизрәк кәрзинемне тутырырга кирәк, шул гына.

Бүре ике дә уйлап тормады, сарыкларны күз алдына китерде дә шунда ук риза булды. Дүртәүләп бу аланлыктагы эре җиләкләрне дә җыеп бетерделәр. Тик әле кәрзин тулмады. Дүртәүләп алга таба җиләк эзләп киттеләр. Күрәләр, шундый зур алан тулган җиләкләр белән, барысы да эре, кып-кызыллар, алма кадәр шушы җиләкләрне калдырып китү – оят. Әнә алар: «Камилә, мине өз, өз», – дип кыч-

кырып торалар. Кызның кулы кагылуы булды, шунда алпан- тилпән аю килеп чыкты.

– Нәрсә оныттыгыз сез минем аланымда, нишләп йөрисез монда, нәрсә кирәк сезгә?

Төлке куркып калды, койрыгы белән битен каплады, Илнур агач артына посты, бүре читкәрәк атлады, Камилә калтыраулы тавышы белән: «Җи-и-ләк-кә-ә килдем», – диде.

– Ничек килдең, шулай кит, – диде аю, ә сез, Төлке туташ, Бүре әфәнде, нишләп йөрисез бу балалар белән, аңламый торам?

– Кара әле, Аю әфәнде, бу кызлар, ялгышмасам, бал кортлары тота, аларда бал бик күп. Шулай бит, Камилә, – диде Бүре.

– Әйе шул, Бүре дустым, 35 умарта оясы тотабыз, бал бездә бик күп.

Илнур, аптырап, берни әйтми карап торды. «Ярар бездә 15 умарта бар, тик бит Камиләләрдә сарыклар да, кортлар да юк», – дип уйланды малай эченнән генә.

– Алай икән, – диде Аю.

– Менә, Аю әфәнде, безгә шушы кәрзинне тутырырга кирәк, алайса, кызны өйгә кертмиләр. Җиләк җыеп бетерсәк, төлкегә – куяннар, миңа – сарыклар, сиңа бал булачак аңлыйсыңмы?

Аю озак уйлап тормыйча, ризалыгын белдерде. Бишәүләп бик тиз генә кәрзинне тутырып та куйдылар.

– Рәхмәт сезгә, дусларым, булыштыгыз, авыл эченә кермәгез, мин сезне килеп чакырырмын, – диде кыз. Ә аннан соң әнисе янына уңышы белән мактанырга йөгерде. – Әни, әни, минем дусларым барлыкка килде. Алар миңа булыштылар, әнием. Кара кәрзингә, син төбен дә тутыра алмассың, дигән иде. Дуслар булганда бар да була. Ләкин бу «дуслык»ның икенче ягы да бар әле… Киңәшең кирәк, – диде һәм түкми-чәчми барлык булган хәлне сөйләп бирде.

– Ярый, кызым, бер дә борчылма син. Керсеннәр өйгә, авыз итәрлек ашавыбыз, итләребез бар. Илнурның әтисе бал да керткән иде әле, – диде әнисе.

Почмакта шыпырт кына басып торган Илнур көлеп куйды.

– Бар, Илнур, дусларыбызны чакыр, – дип боерды аңа Камилә.

Шулай итеп, Төлке, Бүре, Аю, Камилә һәм Илнур якын дуслар булып киттеләр. Камиләләр җиләк сатып, 55 сарык һәм 35 умарта оясы алды. Бүре, Аю, Төлке дә каршыларына куелган ризыкка канәгать булдылар.

# Публицистика



# 📖 12-14 яшьлекләр

**Зарипова Регина Ринат кызы, 13 яшь**

*Җитәкчесе: Зарипова Гөлназ Җәүдәт кызы*

## МИН – АЛТЫН УРТАЛЫКТА

Конкурентлык гомер-гомердән килгән күренеш. Бүген дә тантана итә. Ул җәмгыятьнең аерылгысыз бер өлеше дисәм дә ялгыш булмас. Нинди генә өлкәне алсак та конкурентлык күренеше ярылып ята. Сату өлкәсендә – кибетләр, мәсәлән, безнең районда «Арыш мае», «У нас», «Олимп», «Идел» һ.б. белән, аптеклар – безнең районда «Табиб», «Имплозия», «Бережная» һ.б. белән ярыша, кәрәзле элемтә өлкәсендә – безнең районда «Билайн», «Мегафон», «МТС», «Теле2» һ.б белән конкурентлык итә. Ә мин үзем шәхсән яхшы билгеләргә уку теләге белән сыйныфташларым арасында конкурентлык итәм.

Конкуренцияне көндәшлек дип күзалдына китерәм мин. Әлеге күренеш яхшымы, әллә начармы? Бу сорауга җавап бирә алмыйм. Әйбер сатып алганда, сайлау мөмкинлегебез бар, уку мәсьәләсенә килгәндә – ул күренеш нәтиҗәсендә яхшырак уку максат барлыкка килә. Тик яхшылык артыннан куып, кешенең ни дә булса барып чыкмаса, бу кешедә күңел төшенкелеге барлыкка килергә дә мөмкин дип уйлым. Мин, әлбәттә, алтын урталык яклы. Йомгаклап шуны әйтәсем килә: конкурентлык булган, бар һәм булачак та.

**Хафизова Алсу Марат кызы, 14 яшь**
*Җитәкчесе: Хафизова Фәридә Зәки кызы*

# ЙӨРӘГЕМӘ МАЙ БУЛА

Замана баласы – кем ул? Техниканы яхшы белүче, смартфон белән куллана алучы, бәлки яңа жаргон сүзләр белүчеме? Минем уйлавымча, замана баласы – ул заман ритмына күнегүче, ләкин, шул ук вакытта, үзенең милли үзенчәлеген онытмый торган бала. Хәзерге заманда цифрлы технология, техника – белем алу чыганаклары бик күп.

Төрле телләрне дә күп белергә кирәк. Инглиз, немец, француз һәм башка күп чит телләр балага киләчәктә кирәк була ала. «Сандугач җырын җырлыйм дип, үз җырыңны онытма,» – дигән мәкаль баланың күз алдында торырга тиеш. Башка күп телләрне белеп тә, үзеңнең телеңне белмичә, йөрәгең белән сөйләшә алмыйча ничек яшәргә кирәк?!

Яңаны өйрәнү, сүз дә юк, бик яхшы. Гел яңаны өйрәнергә кирәк. Яңа формула, яңа бирем, яңа сүз, яңа кеше, яңа тел. Яңаны өйрәнеп кенә, гомернең тәмен саклап калырга була. Яңа белемне искесе белән чагыштыра алсаң, бу инде – гомернең яңа тәмен аңлап була дигән сүз. Бу белемнәрне тагын да арттыра.

Минем туган телем, әнкәм-әткәмнең теле ул – татар теле. Бөек Тукай, Җәлил, Такташ, Туфан сөйләшкән тел. Әби-бабам, әти-әнием, туганнарым, дусларым сөйләшә торган үз телем! Үз телемә мәхәббәтне миндә кечкенә яшьтән үк үстерделәр. Минем гел туган телемдә сөйләшәсем, аны өйрәнәсем килә. Ул бик бай. Татар телендә сөйләшү йөрәгем өчен май була. Бу тел бит чынлап та матур, шундый матур, моңлы тел!

Күп кеше өчен туган теле йөрәгенә якын дип уйлыйм. Ләкин кайберәүләр туган тел аларга киләчәктә кирәк булмый дип уйлый. «Хәзер бу телдә авылда әбиләр генә сөйләшә», – дип ялгыша. Ләкин без – замана балалары – туган телебезне, традицияләребезне, күңелебезне сакламасак һәм үстермәсәк, моны кем эшләр? Без – татар төркемендә укучылар – үзара туган телебездә аралашабыз, дәресләрдә сирәк яңгырый торган яңа сүзләр белән танышабыз

да сөйләмебезгә кертергә тырышабыз. Безнең төркем бик дус һәм ул иҗади яктан сәләтле укучыларны берләштерә. Туган телебездә оештырылган төрле кичәләр, бәйгеләр бездән башка үтми. Иҗади проектларда бик теләп катнашабыз, призлы урыннар яулыйбыз. Һәрчак татар телен өйрәнүебезгә куанып яшибез. «Без – татарлар!» дип горурланып йөрибез. Туган тел һәм әдәбият дәресләренә сөенеп керәбез, гел яхшы билгеләр генә алып укыйбыз. Ә башкача була да алмый! Без бит – милләтебезнең киләчәге, өмете, ышанычы!

Телне үстерер өчен, татар теле темасына зур конференцияләр үткәрү генә кирәк түгел. Алардан файда күп түгел. Җанында татар рухын сакларга кирәк! Иртән – «Хәерле иртә», кичен «Тыныч йокы», – дисәң, син инде татар телен саклыйсың дигән сүз. Гаиләдәге өлкәннәргә «әбием», «бабаем» дип өзелеп дәшә алсаң, ничек куана алар! Милли бәйрәмнәрне күтәп ала белсәң, туган телеңдә басылучы вакытлы матбугат белән таныш булсаң, инде үсә төшкәч, милли ризыклар белән гаиләңне сыйлый алсаң, милли киемнәргә игътибар бирсәң, кечкенә вакытта алган тәрбияңне саклап, балаларыңа да тапшыра алсаң, татар милләтенә лаеклы булып яшәвеңне раслау булыр иде.

Без генә сакларга теләгән әйберне саклый алабыз. Безнең киләчәгебез бездән тора. Бүгенге көнебезнең нинди булуы, бүгенге телебезнең нинди булуы да бары бездән тора!

**Николаева Алинә Сергей кызы, 13 яшь**
*Җитәкчесе: Хаҗиева Ләйсән Мансур кызы*

## КӨЗНЕҢ СИХРИ БИЗӘКЛӘРЕ

Табигать һәрвакыт үзгәреп тора. Ел фасыллары алмашынган саен, табигать тә яңа киемнәрен кия. Менә хәзерге вакытта, үзенең алтын яфраклары белән, көз килеп җитте.

Бу ел фасылы, башкалары белән чагыштырганда, аеруча матур, сихри, тылсымлы, алтын һәм моңлы. Иң беренче булып, яшел туннарын алтын күлмәккә зифа кеннарыбыз алмаштыра, ә аннан соң, алардан калышмыйк дип, башка агачлар да, ярыша-ярыша, берсеннән-берсе матур сарылы-кызыллы, кишер сарылы күлмәк кияләр. Алар шулай итеп, үзләренең уңыш бәйрәмен каршы алу өчен, әзерлекләрен күрсәтәләр. Кояш аларга, тагын да матур булу өчен, үзенең нурларын сибә, яңгыр да, аларның күлмәкләрен энҗе бөртекләре белән бизәү өчен, гел явып тора. Ах, карагыз әле! Нинди матур күлмәкләр!

Кырларда эш кайный. Безнең игенчеләребез көнне-төнгә ялгап эшли. Эшләп бетергәч тә алар, үзләренең лаеклы ялларын алып, кышка аяк басарлар, ләкин әле уңыш бәйрәмен уздырасы бар… Бу бәйрәмдә аларга агачлар җил белән үзләренең моңлы көйләрен сузып-сузып җырларлар. Уңыш бәйрәме узып киткәч тә, салкын көннәр башланыр, агачлар шәрә калыр, кошлар да сагыш тулы күңелләре белән җылы якларга очып китәрләр. Туган якларында калган җәнлекләр, кышка әзерләнә башлагыз! Сезне салкын кыш көтә…

# 15-18 яшьлекләр

**Хаҗиева Айлия Айдар кызы, 15 яшь**

*Җитәкчесе: Хаҗиева Әлфия Галинур кызы*

## ЖУРНАЛИСТНЫ АЯКЛАРЫ ГЫНА АШАТМЫЙ

XXI гасыр журналисты! Бу профессия һәрдаим үзгәреп-камилләшеп тора, яңа технологияләр белән ныграк бәйләнә, хәтта «ясалма интеллект»ны да әлеге өлкәгә яраклаштырдылар. Бүгенге журналист шушы үзгәрешләрне урап узса, яхшы контент ясый аламы? Заманча журналист нинди сыйфатларга ия? Әлеге язмадан белерсез.

**Журналист – киң кырлы профессия.** Хәзерге заман журналисты бик ачык һәм кызыксынучан булырга, психологияне яхшы аңларга тиеш, чөнки аның эше 80%ка кешеләр белән аралашудан тора. Уникальлек, үз-үзеңә ышаныч, харизма, җаваплылык – шулай ук, чын журналистларга хас сыйфатлар. Мәгълүматны табып, аны укучыга кызыклы итеп тәкъдим итәр өчен, журналист түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш:

- мәгълүмат чыганакларын бәяли белү,
- бер ситуациягә төрле яктан карау,
- тикшеренүләр уздыру,
- чыганакларның дөреслеген тикшерү һ.б.

**Текст язу нечкәлекләре.** Чын журналист һәрвакыт текстлар язуда оригинальлеккә омтыла, чөнки шаблонлы җөмләләр укучыларны туйдыра. Язмалар җиңел укыла һәм үз аудиторияңә аңлашыла торган булырга тиеш. Оста журналистлар киң масштаблы, детальләргә бай текст язалар, ләкин аны эмоциональ яктан бәяләмиләр – укучының ситуациягә карата үз фикерен булдыру мөмкинлеге туа. Журналистиканың төп максаты – мәгълүмат бирү, шуннан чыгып, XXI гасыр журналисты үз алдына әлеге бурычларны куя:

- мәгълүматны тиз арада җәмгыятькә җиткерү,
- кешегә үз фикерен булдыруда юнәлеш күрсәтү,

- дөреслеккә, хаклыкка омтылу,
- культура байлыкларын пропагандалау.

**Интернет – заман журналистының уң кулы.** XXI гасырда журналистларга Интернет, глобаль технологияләр зур ярдәм күрсәтә. Зур тизлек белән эшләүче Интернет журналистка оперативлырак эшләү мөмкинлеге бирә. Мәкаләләрне җиңел генә гаджетларга язарга һәм үзгәртергә була. Аннан тыш, журналист теләсә кайсы мәгълүматны Интернет челтәреннән эзләп таба. Димәк, хәзерге заман журналисты цифрлы технологияләр белән бер адымда барырга тиеш.

**Сайт булдыру – яңа мөмкинлекләр ачу.** Газета-журналларның күпмедер өлеше сайтларга күчә. Сайт булдыру аларның популярлашуына ярдәм итә. Бүгенге көн журналисты сайтларның мөмкинлекләрен куллана белергә тиеш. Ул сайтларда күбрәк текст урнаштыра, укучылар белән сайт аша элемтә төзи, аудиториясен киңәйтә, яңа рубрикалар ясый ала.

**Роботлар журналистларны алыштыра?!** Журналистларның һәм «ясалма интеллект»ның бәйләнеше бармы соң? Әйе, чөнки, Интернет чыганаклары буенча, хәзер алга киткән илләрдә роботлар кечкенә журналистик текстлар яза. Аларны кеше кулыннан язылган мәкаләдән аерып булмый. Бәлки киләчәктә «ясалма интеллект» безнең илдә дә эшли башлар. XXI гасыр журналистлары аны дөрес кулланырга өйрәнергә тиеш, һәм шулчакта роботлар мәгълүматны җәмгыятькә җиткерү юлын җиңеләйтәчәк, ләкин журналистларның эшләрен тулысынча үз өсләренә алмаячак.

**Конвергентлы журналистика** үзендә журналистиканың бөтен өлкәләрен сыйдыра. Ягъни, бу төр журналистика белән шөгыльләнүчеләр текст та яза белергә, фотога да төшерергә, микрофонга да сөйли белергә тиеш. Нәтиҗә ясыйбыз: XXI гасыр журналисты конвергентлы журналистикага өйрәнергә тиеш.

2021 елда үткән «Алтын каләм» фестиваленең спикерлары XXI гасыр журналисты сыйфатлары турында үз фикерләрен белдерә:

**Роман Серебряный:**

«Бүгенге журналистлар кыю һәм оператив. Алар гражданнарның фикерен яклый, фактларны тикшерә, һәрвакыт белем алырга

омтыла. Хәзерге журналистларга Интернет һәм гаджетлар гына түгел, беренче чиратта, үзләренең белемнәре ярдәм итә».

**Эдуард Хәйруллин:**

«XXI гасыр журналисты универсаль булырга тиеш. Минемчә, һәрбер кеше массакүләм мәгълүмат чыганакларының бер өлешенә әверелә ала, чөнки беребезнең дә мөмкинлекләре чикләнмәгән. Хәзерге заман журналистына ярдәмгә ноутбуклар, планшетлар килә. Гомумән, XXI гасыр журналисты технологияләр белән тыгыз бәйләнештә булырга тиеш».

**Илгиз Шәкүров:**

«Мәгълүмат агентлыкларында эшкә алганда, конвергентлы журналистика өлкәсендәге белгечне кулайрак күрәләр, шуңа хәзерге заман каләмчеләре барысына өлгерергә тиеш».

**Галимуллина Диләрә Вазыйх кызы, 15 яшь**
*Җитәкче: Галимуллина Зөлфия Марсил кызы*

## БЕЗНЕҢ МАРУСЯБЫЗ

Сәлам, дуслар! Мин Киров өлкәсе Вятка Аланы районы Иске Пенәгәр авылы кызы. Минем сезгә үземнең яраткан дүрт аяклы дустым – Маруся исемле бик тә акыллы, бик тә матур кәҗәбез турында сөйлисем килә.

Әти-әниләребез безне кечкенәдән шәфкатьле, миһербанлы һәм ярдәмчел булырга өйрәтеп үстерәләр. Әтием белән әнием узган җәйдә кәҗә алып кайттылар. Белсәгез иде аның матурлыгын... Ап-ак йонлы, күзләренә үк төшеп тора торган озын кашлы кәҗәбезне беренче күрүдә үк ошаттык. Үзе дә йомшак тавышы белән ягымлы гына «мәэлдәп» «Сезме минем хуҗаларым? Бүгеннән мин сезнеке!» – дигән кебек, бер дә ялындырмый гына абзарына кереп басты. Ә кичен, сөт савылгач, әнием белән бергәләп, кәҗәнең озын йоннарын кыскарттык. Болай эшләгәч, кәҗәбез тагы да чибәрләнеп китте. Мондый матур кәҗә тик бездә генә шул! Менә шул көннән ул безнең аерылмас дустыбызга әйләнде. Көн саен арканга йөртү, абзарын ялт иттереп җыештырып кую, кичке савымга алып кайту минем җилкәгә төште. Билгеле, башта кыенрак булды, хәтта курыккан чакларым да булгалады. Тик әкрен-әкрен кәҗә – миңа, мин кәҗәгә ияләштек.

Әти-әнием: «Эшләгәнең безнең өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен», – дип, кәҗәбезгә кыш буена җитәрлек хуш исле печән, миллек җыярга мине дә үзләренә ияртteләр. Ә хәзер миләш, кызыл шомырт җимешләрен җыеп, кышка витаминлы ризык әзерлибез.

Йортыбыздагы кәҗәгә иң сөенгәне энекәшем булды. Бер яшьлек Камилебез кәҗә белән уртак телне бик тиз тапты. Әле сөйләшә дә белмәгән сабый кәҗә белән ни турында сөйләшәләрдер, анысын төгәл генә әйтә алмыйм. Тик шуны әйтеп үтәсем килә: кәҗәбез энекәшемне күрүгә ашаган җиреннән туктап, сөенә-сөенә мәэлди башлый. Ә Камил энем, нәни генә куллары белән чирәм йолкып, Маруся янына ашыга. Нәкъ Тукай абыебыз язганча, «Гали (Камил) аны чирәм белән кунак итә, кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә».

Сез бу вакытта кәҗә белән кечкенә баланың ничек сөенгәнен күрсәгез иде!..

Кәҗәбез дә безне үз итте: үзенең тәмле һәм шифалы сөте белән сыйлый. Сөте шифалы булмыйча, ул бит печәннең иң тәмле, сусыл җирен генә ашый. Иң яратып ашаганы – сусыл кыяклы печән, алма, кыяр, потиссон икән.

Халык, кәҗә малын, никтер бик кире хайван, диләр. Киредерме, юктырмы, ә хайваннар арасында чисталык буенча беренче урында тора ул. Аның бер генә тапкыр да пычрак җиргә ятканы, пычрак су эчкәне юк, хәтта яңгырлы көннәрдә җыелып торган суга аягын тидермичә, печәнлерәк җиргә басып йөрергә тырыша кәҗәбез. Ә инде саварга кергәч, билгеле урынына басып, йомшак кына мәэлдәп безне каршы ала. Янәсе, көне буе сезгә тәмле сөт җыйдым, мине сыйлаганыгыз өчен, мин дә сезне сыйлыйм әле, дигән кебек, сөтен савып алганчы, сабыр гына, тыныч кына басып тора. Күбекләнеп савылган тәмле сөтне бернинди тәмле соклар, әллә нинди эчемлекләр алмаштыра алмый шул.

Яраткан кәҗәбезгә озын гомер телибез. Алга таба безне тәмле дә, шифалы да сөте белән сыйласын иде. Сер итеп кенә әйтәм: киләсе кышка ул безне үзенең нәни бәтиләре белән шатландырачак. Шулай була күрсен, Амин!

**Гыймазова Лилия, 18 яшь**

# АНДА РӘХӘТТӘН ЙӨРҮЧЕНЕ ТАБА АЛМАССЫҢ: ХӘЕРЧЕ БАЗАРЫ «ЕЛАК» КӨННЕ НИЧЕК ЯШИ?

*Сыңар итек, ертыла башлаган куртка, таушалып беткән дисклар, совет заманыннан калган медальләр... Берәүләр өчен болар чүп булса, икенчеләргә, без санаганнарны һәм тагын әллә ниләр сатып, көн күрергә туры килә...*

Алар якшәмбе иртәсен көтеп ала. Аннан, өйдәге кирәк һәм кирәкмәс әйберләрен җыеп, монд – Тинчурин бакчасына киләләр. Сервант киштәләренә менеп утырган антиквариат та җиргә төшә, иске, таушалган китаплар, борынгы акчалар, чыбыксыз үтүкләр – барысы да керем чыганагына әверелә. Сүзебез – Казанның нәкъ үзәгендә урнашкан хәерче базары турында.

**Таш яуса да...**

Без бу урынга көннәр суыткач килдек. Ничек киенсәң дә, җил үзәккә үтә торган көн иде ул. Җитмәсә, көне буе яңгыр кебек бер нәрсә явып торды. Ни дә булса сату максаты белән килүчеләрнең кышкы салкыннарда да басып торуларын беләидем инде, баксаң, алучылары да шундый икән: Тинчурин бакчасында алма төшәрлек кенә урын калган иде.

– Татарстан урамыннан җәяү киләм. Зарланмыйм: яшь чакта, авылда көн күргәндә, җилкәгә әллә нинди авырлыклар төште. Алар янында бу... Элек тә башка чара юк иде, һаман шул хәлдә, кызым, – дип сөйләде мамык шәл япкан, кечкенә генә битле бер әби (нигә сөйләштереп торуымны аңлагач, исемен язмауны үтенде).

Җәй айларында базар иртәнге алтылардан көндезге ике-өчкә кадәр эшли икән. Суыткач, алай озак басып торып булмый, ди сәүдә итүчеләр.

– Картайдык шул инде: эчкә суык тиз үтә, аяклар сызлый. Яшьрәкләр тора әле, без тиз бирешәбез шул, – дип сүзен дәвам итте шул ук әбекәй.

**«Акча сатам. 20 меңгә...»**

Полиэтилен яки җәймәләргә тезеп куйган әйберләр арасында күгәреп беткән ачкычлар, кашыклар, бала уенчыклары, кассеталар

белән беррәттән «эксклюзив» тәкъдимнәр: хан заманыннан калган тимер акчалар, күннән эшләнгән букча, итекләр, башка берәүдә дә булмаган спорт костюмнары, граммофон өчен пластинкалар… Кыскасы, хәзерге заман Плюшкиннары сусауларын монда килеп баса ала.

Алалар бит! Ике йөз сум торса да, ике мең дисәләр дә, алалар әйберне. Талаша-талаша «эксклюзив»җыя халык. Кая куеп бетерә торгандыр… Хәер, сатып алучыларның төрлесе бар. Берәүләр искелек колы булса, икенчеләр ун киелгән күлмәккә дә риза.

– Хәерче базарын бер килүдә генә күреп, белеп бетереп булмый. Монда сату-алуның үз нечкәлекләре бар: китап сатучы бер абзый базарның эчке тәртипләре белән таныштыруны әнә шул сүзләрдән башлады. «Сәүдәгәр»ләргә – сата, сатып алучыларга ала белергә кирәк. Иске әйбер сатучылар товарның тарихын шулкадәр кызыклы итеп сөйли, алмаган җиреңнән алырлык! Ә алучыларның иң осталары сатулаша. Бер яктан, бахыр сатучыларны кызганасың, икенче яктан, ул иске-москыны алып торучы булганга рәхмәт.

**«Пушкин – 200, Такташ – 20 сум…»**

Бу абзый үзе китапларны күпләп җыя, аннан шушында алып чыгып сата икән.

– Кеше китә – китаплар кала. Соңгыларын булса да яшәтәсе иде. Укылмаса, аларын да югалтачакбыз. Миңа китапларны китапханәсе белән китереп бирәләр – куярга урыннары юк, ул кадәр байлыкны ташларга кызганалар. Ә монда иясе табыла аның. 100-200, хәтта 20-30 сумга да биреп җибәрәм, эчтәлеге, таушалганлык дәрәҗәсенә карап инде, – дип сөйләде ул.

«Шушы китапларның күпмесен укып чыктыгыз соң?» – дим мин аңа, унлап тартмага тутырылган китапларга төртеп.

– Яртысын гына. Мин башка төрле әдәбият белән кызыксынам, үземнең китапханәм бар, – дип җавап бирде ул.

Тартмаларында нинди генә китап юк! Сериялап җыйганнар. Аларга карагач, хуҗасының нинди булганлыгын да чамалый башлыйсың. Берсе Пушкинны, Толстойны җыйган, икенче берәүнең уйдырмалар яратканлыгы күренеп тора. Татар әдәбиятын да табарга була монда: Ибраһим Газиның ике туганыннан аерылып калган «Онытылмас еллар»ы, Такташның тулы җыелмасы да монда.

Роберт Миңнуллинның өр-яңа җыентыклары да күренә. Татар китапларын 20 сумнан саталар. Башка алучыларга шәптер дә бит, тик миңа кызганыч булып китте. Имеш, рус классикларын – 200, татарларны 20 сумга бәяләгәннәр.

**«Ипи-сөтлек кенә җыела инде шунда...»**

Күпчелек сатучылар – өлкән яшьтәге апалар һәм йөзләрен җыерчык каплаган әбиләр. «Сорап торма, үзем әйтәм: рәхәттән йөрүче юк монда», – ди берсе. Шулай да, байтак кына сораштырганнан соң, үзем өчен сатучыларны ике төркемгә бүлдем: берәүләр бер көнлек булса да ипи хакы өчен йөрсә, икенчеләре – ялгызлар...

– Җиткереп булса, чыгар идемме, шушы хәлгә калыр идемме соң? Балалар кайсысы – кайда. Фатирына, утына, газына түли башласам... ашарыма акча калмый, балам. Безгә, картаеп беткәч, артыгы кирәк түгел, ипие булса шунда, – дип, үзе сөйли, үзе яшьле күзләрен яшерә әбекәй.

Күбесе исемнәрен язмаска куша: йә кеше алдында оялалар, йә балалары сүгәр дип куркып әйтмиләр. Үзе бәйләгән башлыкбияләйләр сатучы Валя апа гына курыкмады.

– Гомер буе заводта эшләдем. Пенсиясе дә җитәр иде инде, иптәшем юк шул, көнем һич үтми. Аптырагач, бәйли башладым. Атна буе бәйлим дә якшәмбе шушында килəм. Автобусы йөреп тора, Казанның икенче башыннан ук киләм. Зарланмыйм, кызым. Монда һич югы сөйләшеп торырга иптәшләрем табылды. Менә хәзер суыклары гына комачаулый, – дип сөйләде ул. – Оныгымның өр-яңа киемнәрен дә алып килдем әле. Бер кия дә ташлый бит алар. Ә монда шул киемгә мохтаҗлар җитәрлек.

Язмышлары төрле аларның. «Тормышның төбенә төшеп җитмәсәк тә, күптән өстә түгел инде без», – ди алар. Шулай да, тормыш белән тартышырга көч табып, хәерчелектән, ялгызлыктан качып, шушында киләләр...

**Тинчурин паркыннан тыш, Казанда хәерче базары Авиатөзелеш районында, Жилплощадка бистәсендә (Беломорская белән Гудованцев урамы чатында башлана) да бар. Ахыргысын 1960 елларда компрессор заводы янында оешкан хәерчебазарының дәвамчысы, дип сөйли сатучылар.**

**Шәрипов Рүзәл Фәнис улы, 17 яшь**
*Җитәкчесе: Ибраева Рәсимә Хәниф кызы*

## АЙСЫЛУ МИНГАЛИМ: «БАЛАЛАРНЫ ДӨРЕС КАБУЛ ИТЕП, АҢЛЫЙ БЕЛЕРГӘ ГЕНӘ КИРӘК»

Мөмкинлекләре чикле балаларны кимсетү очраклары күренми генә дигәндә, Красноярск мәктәбендә яңа хәл: беренче сентябрьдә укытучы шул ук сыйныфта укучы инвалидтан башка күмәк фото ясарга тәкъдим итә. Күрәсең, чыннан да «матурлык»ка омтылып яшәүче шәхес… Бу хәлгә хәтта Ольга Бузова да битараф кала алмый – Инстаграм битендә *#ВаняЯХочуСТобойФото* хэштегы астында шул баланың фотосын урнаштырып, махсус флешмоб оештыра.

Шулай итеп, русларда мөмкинлекләре чикле булганнарны Бузова якласа, татарларда исә бу изге эшне инде берничә ел рәттән Айсылу Чижевская-Мингалим алып бара. ГТРК «Татарстан»да эшләгән стилист-визажист, Венера Ганиева группасында белем алган җырчы, оста скрипкачы – болар барысы да Айсылу Мингалим һөнәрләренең бер өлеше генә әле.

– Тормышымның бер мизгелендә яңа сулыш кирәк була башлады, һәм бер дә көтмәгәндә балалар йортында эшләү теләге барлыкка килде. Эзләндем, төрле интернатларда булдым, тик бу өлкәдә эшли алмам, дип гел кайтарып җибәрә иделәр. Әлеге юл интуитив рәвештә сайланган булса да, соңыннан йөрәк тә андагы сабыйларга ешрак тартыла башлады. Шуңа күрә беркемнең дә сүзенә карамыйча, Казан шәһәре Идел буе районының балалар йортына эшкә урнашырга булдым, – дип сөйли ул үзе.

### «Чын язмыш бүләге булгандыр бу!»

– Телевидениедә эшләгәндә миңа балалар йортына барырга туры килде. Шунда читтә генә башкалардан аерылып торучы бер малайга күзем төште, аның үземнеке икәнен шундук сизеп алдым. Тиздән бу баланы улыкка алып, Әмир исеме куштым, ә этисенең исеменә, уйламыйча да, Эдуард исемен сайладым. Шуннан очраклы рәвештә тормыш мине Эдуард исемле кеше белән очраштырды, һәм без уртак тормыш башладык. Бу инде минем икенче никахым иде, шуңа күрә Солтан исемле балабыз да тууы мине нык шаккаты-

рды! Тормыштагы кыю адымнарым өчен чын язмыш бүләге булгандыр бу!

Икенче ирем белән дә тиздән аерылышуга карамастан, балалар йортыннан Ульяна, Юлианна һәм Даниил исемле тагын өч сабый алдым. Шулай биш бала белән гөрләшеп яши башладык. Аларның һәрберсе үзенчә сәләтле: берсе - рәсем ясау белән мавыга, икенчесе – пешекче булырга хыяллана, өченчен исә бөтенләй профессор диярсең. Даниил белән без хәтта Мәскәүдә узучы «Ты супер!» проектында да катнаштык, һәм ул Филипп Киркоров белән дуэт башкару бәхетенә ия булды. Андагы чыгышларга әзерләнгәндә авырлыклар да, бөтен борчыган проблемалар да бик тиз онытыла иде, чөнки гел камилләшергә, алга омтылырга кирәк бит. Ә рус эстрадасы йолдызлары белән күрешеп эшләү үзе зур бәхет, шуңа бу мизгелләр мәңге онытылмаслык булып истә калды да инде.

**«Үзеңә ышан»**

– Алга таба Лаеш мәдәният йорты мөдире эшенә керештем. Тик тора-бара башка яклардан да үсәсем килде, балалар белән эшләү дә сагындырды. Шунысы кызганыч, аннан бер киткәч, кире кайтып булмый икән, шуңа күрә шул ук балаларга мин башка яктан юл табарга булдым – «Үзеңә ышан» исемле иҗат һәм укыту студиясе оештырдым. Монда төрле яшьтәге мөмкинлекләре чикле булучылар белән эшләү өчен барысы да бар: мин биредә лекцияләр биреп, укыта да, үз продюсерлык үзәге ача алам... Хәзер студиянең үсеше белән шөгыльләнәм, спонсорлар эзлим. Мин бу мәсьәләгә битараф булмаучы һәр кешегә шат!

Шушы проект кысаларында 6 нчы сентябрь көнне Лаешта «Үзеңә ышан» дип исемләнгән беренче региональ фестиваль дә оештырдык. Ул, балалар тормышның нинди генә авырлыгын күрүгә карамастан, үзләрен сәхнәдә чын йолдызлар итеп хис итсеннәр өчен уйлап чыгарылган зур бәйрәм. Монда барлыгы 59 катнашучы чыгыш ясады, аларның һәрберсе җырга һәм иҗатка гашыйк. Арасында шигырьләр язып, киләчәктә үзләрен артист итеп күрүчеләр дә шактый иде. Әле алай гына да түгел, концертта балалар йортыннан алынган 12 сабыйлы Никифоровлар гаиләсе дә чыгыш ясады! Шушындый ук грандиоз тамашаларны Яшел Үзәндә

һәм Казанда да уздырдык, чөнки мондый сәләтле балаларны рухи яктан баету минем өчен бик мөһим.

**«Айсылу, чит баланы ничек ярата аласың?»**

– Мәхәббәт ялкын кебек янып китеп, тиз вакыт эчендә сүрелергә дә мөмкин. Шуңа күрә балаларны бары тик дөрес кабул итеп, аңлый белергә генә кирәк. Шул очракта мәхәббәттән дә көчлерәк тотрыклылык хисе барлыкка килә. Аның исә синең үзеңне дә, балаларны да бик тиз бәхетле итә торган сихри көче бар!

# 📖 19-25 яшьлекләр

**Гайнетдинова Индира Фәннүр кызы, 19 яшь**

## БЕЗ ТАТАРЛАР – БЕР ХАЛЫК

Тел элек-электән үк кешеләрнең төп аралашу чарасы булып торган. Кеше нинди телдә сөйләшсә, шул телдә фикер йөртә. Гомере буе ун тел өйрәнеп, теләсә-кайсы илләрдә яшәп, әллә нинди чит ил кешеләре белән аралашып яшәсә дә, иң беренче сүзен газиз ана телендә әйткән һәм шул телгә таянып, зур тормышка аяк баскан. Дөньяны тану; укырга һәм язарга өйрәнү; тәрбия алу; белем туплап һөнәрле булу; иҗат, фән,техника, сәнгать һәм башка төрле казанышларда алдынгы булу – барысы да тел ярдәмендә генә тормышка ашырыла.

Соңгы елларда телгә кагылышлы вәзгыять беребезне дә битараф калдырмый, борчый. Татар телен укыту проблемасы Татарстанны гына кагылып узмады, бөтен Рәсәй киңлегенә җәелде. Гомумән, татар теленә кагылышлы проблема нәрсәдән килеп чыкты соң? Телебезгә карата хөрмәтне һәм абруйны ничә еллап аякка бастырырга тырышкан вакытта президентыбыз В. В. Путинның «ирекле булырга тиеш» дигән сүзе телебезне дә, милләтебез язмышын да куркыныч астына куйды һәм шуннан соң әлеге телне укытмас өчен бер-бер артлы яңа сәбәпләр табыла торды. Әйтик, бердәм дәүләт имтиханын бары тик урысча гына тапшыра алу хокукы... Туган телне читкә этәрү, безнеңчә, шуннан башланды. Ата-аналар беренче чиратта нинди телдә имтиханны тапшырырга кирәк дигәнне карыйлар, аннары татар телен өйрәнүне өстәмә йөкләмә дип табалар.

Безнеңчә, татар телендә белем алган укучылар имтиханны бирә алмый дию ул хакыйкатькә туры килми. Белем укучы тарафыннан үзләштерелсә, имтиханны русча тапшыру авырлык тудырмаска тиеш. Монда телнең иң мөһим – когнитив функциясен дә истә тотарга кирәк. Туган телдә алынган белем ныклы, тирән була. Тукаебыз да хаклы әйткән бит: «Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы».

Мәктәптә татар теле дәресләрен укыту тирәсендә барган ызгыш җәмәгатьчелекне уятты һәм татар дөньясында элек булмаган җанлылык күзәтелә башлады.Тик менә иң авыры татар теле һәм әдәбияты уытучыларына төште. Дәресләре кимү сәбәпле аларның күбесе икенче һөнәри әзерлек үтеп, рус телен укытуга күчте. Күпләре, өлкән яшьтәгеләре, гомумән, лаеклы ялга китте я бөтенләй эшсез калды. Гомер буе җиң сызганып, армый-талмый татартеле һәм әдәбияты укытканнар үзләрен әллә нинди тыюлы, ярамаган тел укыткан кебек хис итәргә мәҗбүр булдылар. Тарих кабатлана дибез, 1552 еллар янә кайткан кебек тоелды…

«Татарстан – аерым дәүләт түгел, үзе өчен махсус шартлар таләп итәргә хакы юк. Бөтен төбәкләр дә бертигез шартларда булырга тиеш!» дигән сүзләр соңга таба еш яңгырады. Дәүләт теле татар телен укытуга каршылар саны кинәт кенә күбәеп китте һәм бу сәер күренеш түгел, чөнки бүгенге көндә бар нәрсә рус телендә. БДИ гына түгел, иң гади мәктәп имтиханнары да рус телендә уза. Әлбәттә, татар телен кирәксез дип санагач, аның кирәге дә юк… Бүгенге катлаулы хәлләрдә сүз милли хисләр турында гына бармый. Республикабызның аерым статусы, аның тулы канлы дәүләт булырга омтылуы, икътисади яктан үсеше. Татарстан Россиядә иң алга киткән төбәкләрнең берсе һәм шул статусны югалтмасак иде.

Бүген килеп туган зур проблема – татарда милли горурлык югалу, милли үзаң түбәнәю. Имеш, «рус телен өйрәнеп кенә тормышта юл ярып, үсеп була. Татар телендә гаиләдә, өйдә сөйләшсәгез, шул җитә…». Иң аянычлысы, авылдан чыккан яшьләр тырыш-тырмаша үзара русча аралаша, акрынлап, «татарча аңламас» буынга әверелә бара. Ә бит бер гасыр элек кенә татарлар югары мәдәниятле милләт саналган, кардәш төрки халыклар арасында меңьеллык әдәбияты булган, заманында Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г.Тукайлар, М.Гафурилар иҗаты башка замандаш төрки халыклар өчен өлге-үрнәк булган. Урта Азиядә башка кардәш халыкларны да без – татарлар укытып йөргәнбез.

Кешеләр: «ни өчен халык татар телен өйрәнергә тиеш?» һәм «ни өчен халык татар телен өйрәнмәскә һәм аны өйрәтмәскә тиешләр соң?» га бүленде. Социаль челтәрләрдә төрле берләшмәләр барлыкка килә, аларда һәрбер кеше татар теленә кагылышлы үзенең фикерләрен яза. Бу уңайдан без дә үзебезнең педагогия көллиятендә

сораштыру уздырырдык. Беренче курстан алып дүртенче курс студентлары – барлыгы кырык өч кеше катнашты. Шул санның 40% проценты: «әйе, татар теле рус теле кебек үк мәҗбүри укытылырга тиеш» – дип җавап бирсә, калган 60% «Юк, татар теле укытуда файда күрмим, бөтенләй укытылмаска тиеш» – дип ассызыкладылар. Кайберләре татар теле ирекле рәвештә укытылырга тиеш дип фикерли. Сораштыруыбызда татар теле яклы булган кешеләр күбесенчә – татарлар, ә телгә каршы чыкканнар – рус милләтеннән булганнар. Һәм ни кызык, башка милләт кешеләре (мәсәлән, чуаш, мари, ар, таҗик, әрмән, казах, удмурт, кыргыз) ике кул-аяклап татар телен яклап чыгалар. Әлеге халыкларда башка милләт кешеләренә карата толерантлык, хөрмәт яши дип акчыкладык. Шулай ук афроамериканец кешесеннән аерым сораштыру алдым. Без аның белән тәрҗемә итү җайланмасы ярдәмендә аралаштык. Ул «татар теле» дигән телнең барлыгын гомумән белмәгән. Ләкин туган телемдә сөйләшеп күрсәткәч, ул әлеге телне бераз таныды. Өч ел буе Яр Чаллы шәһәрендә яшәп, кайбер сүзләрне ишеткәләгәне булган икән. Туган телемдә җөмләләр яңгыраткачтын, мин милли һәм заманча татар җырларын кабыздым (заманчадан, мәсәлән: Элвин Грей, Азат Фазлыев, Ришат Төхватуллин, Илгәрәй һ.б) һәм ни сөенеч, татар җырлары Марк исемле афроамериканец кешесенә бик ошады, ул хәтта кайбер җырларның исемнәрен кат-кат сорап, үзенең кесә телефонына язып алды. Аның уйлавынча, татар теле бик авыр, ләкин искиткеч матур тел. «Әгәр дә мин татар телен белсәм, гел татар телендә генә аралашыр идем» диде ул. Без, һичшиксез, татар телен өйрәнергә тиеш, чөнки:

1.Татар теле – ТР ның дәүләт теле. Димәк, аны Татарстанда гомер итүче һәркем үзләштерергә тиеш.

2. Татар телен беләсең икән, димәк төрки телләрне (утызлап телне) дә аңлыйсың. Ә төрки телләр бүгенге көндә яхшы танылган.

3.Татар теле – әби-бабаларыбыз теле, аны сакларга кирәк.

4. Татар теле рус һәм инглиз телләреннән ким түгел, аларга урын бар икән, татар теленә дә булырга тиеш.

Татар телен таныту һәм үстерү өчен «Сәләт» һәм «Мин татарча сөйләшәм» кебек проектларны күбрәк булдырырга кирәк. Хәзер интернет заманы булгач, социаль челтәрләрдә күбрәк татар

блогларын үстерергә, ана телендә алып барыла торган файдалы сайтлар ачылырга тиеш. Иң мөһиме – кечкенә балаларга мәктәптә генә түгел, ә балалар бакчасыннан ук татар телен өйрәтә башларга кирәк.

Белгәнегезчә, Татарстанда телләр турында законы яшәп килә. Аның нигезендә һәр кешенең дә татар телендә сөйләшергә хокукы бар. Татар телен өйрәнүгә басым ясыйк, ә башка телләрне бала үзеннән-үзе дә өйрәнергә мөмкин. Татар телен ничек кенә үстерергә тырышсак та, беренче чиратта, һәр кеше үзеннән башларга тиеш. «Ана теле – тою, сизү, ә иң мөһиме – йөрәк теле» – шуны онытмыйк. Ә инде чит тел белү – кешенең зур байлыгы, диләр. Ана телебез үле тел, фәкать ата-бабаларыбыз теле генә булып калмасын иде. Татар кешеләренең иң кыйммәтле һәм зур байлыгы – горур атлап, заман белән бергә баручы үз туган телләре булсын иде. Телебез ярдәмендә без бер халык, бердәм халык булып яшик!

**Хуҗина Зәринә Рамил кызы, 20 яшь**
*Җитәкчесе: Хуҗина Гөлназ Рәфис кызы*

## 1 МАРТ - ПЕСИЛӘР КӨНЕ: «ӘБИНЕ КҮМЕП КАЙТКАНДА ИШЕК ТӨБЕНДӘ ПЕСИ УТЫРА ИДЕ»

**Россиядә Песиләр көнен 1 мартта бәйрәм итәләр. Бездә мәчеләр – яз символларының берсе, ә март песи ае дип тә санала.**

28 февраль – кышның соңгы көнендә Казан Ярминкәсендә «Өйгә таба юл» дигән күргәзмә узды. Ул песиләр көненә багышланган иде. Безнең йомшак дусларыбызны карарга килгән халык та шактый күп иде. Шунда йөреп кайтканнан соң, песи асраучы артистларга, аларны яратучыларга шалтыратып, йорт хайваннары турында сөйләшеп алдым.

**«Безнең песи бары тик «кайфовать» итәргә ярата»**

**Данир Сабиров, юмор остасы:** «Бер сүз белән генә әйткәндә, песи – ялкау, ялагай хайван. Артыгын урамга да чыкмый инде. Бүген көн җылы, бар дип этә-төртә чыгарып җибәрәбез. Көне-төне шул диванда гына ята инде. Ул безнең алгы бүлмәдә яши, бераз гына анда торсам, аякка сырпаланып, ышкылып, ялагайланып йөри башлый. Безнең песи бары тик «кайфовать» итәргә ярата.

Минем хатыным өйдә хайван булуына каршы, шуңа ул безнең алгы бүлмәдә яши. Анда да аңа барлык яшәү шартлары тудырылган. Җылы, ашарына чыгарып торабыз. Өшемәсен дип, аңа аерым радиатор куйдык, ә болай песиләр минус 10 градуста да рәхәтләнеп яши икән дип укыдым.

Песи безгә бик кызык кына килеп эләкте. Карт әбине җирләп кайтканда, ул безнең ишек төбендә утыра иде. Юкка гына безгә килмәгәндер, ул безнең песи булачак дигәч, миңа берсе дә каршы килмәде.

Безнең килен – Миләүшәнең абыйсының хатыны песиләр ярата. Аларның өйләрендә гел песи яши. Аларның песиенең исеме Кашап, чөнки Миләүшәнең абыйсының кушаматы шундый. Ә безнең балалар ул вакытта бәләкәй иделәр, нинди песине күрсәләр дә, алар өчен бөтенесе — Кашап. Шуңа күрә без дә, песинең җенесен белмичә, Кашап дип исем куштык. Бер-ике айдан соң, ветеринарга

алып баргач, кыз икәнен белдек. Шулай итеп Кашаптан Кәшифәгә әйләнде ул. Аны песине стерильләштердек, югыйсә ул песиләрне кая куеп бетерәсең.

Безгә, хуҗасыз хайваннар булмасын өчен, чит илдән үрнәк алырга кирәк. Мәсәлән, шул ук Төркия, Америкада барыбер песиләргә карата икенче мөнәсәбәт, аларның язмышына дәүләт битараф түгел. Урам песиләрен безнең илдә, миңа калса, кем хөрмәт итә, кем сөя, шул гына нидер эшли кебек. Ә хөкүмәт бернинди карар да кабул итми. Табигать, терлек һәм хайваннар мәсьәләсе ул шулай ук хөкүмәт дәрәҗәсендә хәл ителергә тиеш.

Мин бернинди ырымга да ышанмыйм. Элегрәк кара песи үтсә, кыенсына идем, хәзер юк. Үзем биш тапкыр намаз укымасам да, җомга саен мәчеткә йөрим. Хәзрәт ырым юк ул, ырымга ышану ярамый дип бер әйтте, шуннан бирле ышанмыйм.

Эт белән чагыштырганда, песи күпкә хәйләкәррәк. Эт – тугры җан иясе, кайсы вакытта кермә, күземә карап тора инде ул. Эткә ашама дисең икән, ашамый да ул, песигә ашама дисәң, тизрәк кабып йөгереп китә».

**«Йомшак булса да, әти аны Шайтан дип йөртә иде»**

**Эльвина Миңнуллина, студент:** «Мин песиләрне бик яратам. 2014 елда безгә британец токымлы песи бүләк иттеләр. Аңа Йомшак исеме куштык. Әти песиләр яратмый иде. Өйдәге бөтен челтәрләрне, диваннарны тырнап бетерсә дә, аны әти дә үз итә башлады. Гомумән, песи ул һәрвакыт бәхет инде, алардан күпме позитив аласың. Бигрәк тә менә шул британецны яраттым. Ул ике алгы аягын кушкач, йөрәк рәсеме барлыкка килә иде. Бөтен күрше-тирә кызыга иде безнең песигә. Ул 2018 елның гыйнварында югалды. Әллә берәрсе урлады шунда...

Йомшак башка песиләрдән тышкы кыяфәте белән аерылып тора иде. Британецларның борыннары сытыграк һәм ул мамыктай йомшак була. Аны бүләк иткәндә: «Бу песи сиңа мендәр урынына, чиста, йомшак песи булачак», – дип бирделәр. Ул безгә кечкенә, бер атналык песи баласы булып кайтты. Өйрәтергә тырышсак та, британецлар табигатьтән өй песие булсалар да, безнеке өй песие булмады. Нәтиҗәдә, урамга чыгып йөри башлады, кая мендәр урынына булсын инде!

Песиемә бер яшь тирәсе булганда, мунчада юындырдым да фен белән киптердем, тарадым үзен. Шундый матур булып калды! Аннары ул урамга чыгып китте, көлгә батып кайткан, кабат юындырасы булды. Характеры ягыннан британецлар шук песиләр, характерлары бар. Характеры булган кешеләр дә үзләренә күбрәк тарталар бит. Песиләр дә шулай. Шуңа күрәме, әти аны бик яратты. Исеме Йомшак булса да, әти аны Шайтан дип йөртте. Чөнки, әйткәнемчә, бик холыксыз песи иде».

**«Мәченең мәхәббәтенә лаек булырга кирәк»**

**Мария Сөләйманова, «ЗооЗабот» зоояклау оешмасы әгъзасы:** «Песиләр – характерлы, үзенчәлекле хайваннар. Алар кешенең һәр әйткән сүзен аңлый. Электән үк песиләр изге хайван саналган, чөнки аларны Аллага тиңләгәннәр. Алар иң ныгы йокларга ярата. Сәламәт, тирән йокы алар өчен бик мөһим.

Мин күп песи токымнарын беләм, иң яратканы – сфинкслар. Алар турында күп сөйли алам. Минемчә, бу иң үзенчәлекле токым. Сфинкс – мәче, эт һәм хәтта маймыл арасында ниндидер уртаклыкка ия булган песи. Алар бик тугры, хуҗаның игътибарын таләп итәләр.

Эт белән песинең аермасы кайда дигәндә, эт хуҗаны шартсыз ярата, ә мәченең мәхәббәтенә лаек булырга кирәк.

Песиләр белән бәйле күп ырым-шырымнар бар, әлбәттә. Мәсәлән, кайберәүләр фикеренчә, мәче йортны явыз ияләрдән саклый. Мин моңа ышанмыйм, әмма өйдәге мәче чыннан да яхшы энергетика тудыра дип саныйм. Шулай ук кара песи юл аркылы чыкса, бәхетсезлеккә, диләр. Минемчә, песи төсенә карап бәхетсезлек китерә алмый. Моны кара мәче хуҗасы буларак раслыйм.

Йортсыз мәчеләр проблемасы, әлбәттә, закон дәрәҗәсендә гуманлы юл белән хәл ителергә тиеш. Безнең дусларыбызны кеше кайгыртырга бурычлы, чөнки мәчеләр үз гаебе белән генә йортсыз калмый. Беренче чиратта, кеше үз хайваны өчен җаваплы булырга һәм контрольсез үрчүгә юл куймаска тиеш – бу йортсыз песиләр булуның төп сәбәбе. Песи яраткан кеше генә аларны үзенә алса, мондый проблема тумас иде».

## Песиләрне нинди чирләр борчый?

**Ольга Шамкина, Биектауда ветеринар табиб:** «Песиләр дә, нәкъ кешеләр кебек, төрле авырулар белән авырый. Йогышсыз авырулардан: йөрәк-кан системасы, баш авыртулары, үпкә, бәвел системасы авырулары, үрчем буенча проблемалар һ.б. була. Һәрберсенә индивидуаль якын килү, дәвалау кирәк.

Күпчелек мәчеләрдә борча, суалчан була. Кешеләр үзләренең песиләрендә борча, суалчан булуга борчылып мөрәҗәгать итәләр. Иң күп мөрәҗәгать нәкъ шуның белән бәйле.

Миндәге статистика авыл җирлеге белән бәйле. Стерильләштерелмәгән песиләр белән шулай ук проблемалар күп була, чөнки алар үзләренә бәла эзлиләр: бер-берсе белән сугышалар һәм башлары, колаклары, койрыклары яралана. Песиләрдәге авырулар әле ел вакытына – сезонга да карый. Яз башлангач, бигрәк тә шәһәрләрдә, «оча торган песиләр» проблемасы башлана. Кешеләр бүлмәләрне җилләтү өчен тәрәзәләрне ачып куялар һәм песиләр ачык тәрәзәләрдән очып төшә башлый, москит челтәре дә аларны саклап кала алмый. Менә шул чагында мөрәҗәгатьләр тагын да арта.

Клиникада эшне теркәүдән башлыйбыз. Хайванга амбулатор карта ачыла, аңа барлык мөһим мәгълүмат кертелә. Хуҗасыннан җентекле сораштырудан соң, ветеринар турыдан-туры клиник карауга керешә. Анамнез җыю һәм җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә табиб пациентны дәвалау тактикасын билгели, кирәк булганда аны өстәмә тикшерүләргә җибәрә. Мәсәлән, сынган урыннар бар икән, рентген тикшерүләр үтәргә кирәк була.

Бәяләр, әлбәттә, төрлечә. Безнең клиникада беренчел кабул итү 400 сумнан башлана, шәһәрләрдә 400дән 1500 сумга кадәр булырга мөмкин. Өстәвенә, әле тәүлек буе эшли торган клиникалар була. Әлбәттә, төнге кабул итү бәясе югарырак.

Авыл җирлегеннән дә песиләрне ветеринар табибларына күп алып киләләр. Быел каты суыкларга бәйле рәвештә, хуҗалар песиләренең колаклары, аяклары өшү белән еш киләләр. Аннары песиләр теләсә кая менәргә, үрмәләргә ярата, шуңа күрә яралану, киселү очраклары күп була».

**«Мәчеләр үзләренә патшаларча мөнәсәбәт көтәләр»**

**Камилә Хәбибуллина, волонтер:** «Бер билгеле мем бар. Хуҗа турында эт: «Сине күрүгә бик шатмын», – ди, ә мәче: «Нигә шулай озак минем янга килмәдең, минем ашыйсым килә», – ди. Мәчеләр – үзенчәлекле хайваннар, алар үзләренә патшаларча мөнәсәбәт көтәләр.

Барлык мәчеләр дә кешеләрнең телен, интонацияләрне аңлый, аларга төрле интонацияләр белән билгеле бер фразаларны әйтергә мөмкин. Һәм барлык хайваннар да моны аңлый. Мисырда песиләргә зур хөрмәт белән караганнар, баш игәннәр. Төрле халыкларда ниндидер изге хайван бар – йә сыер, йә мәче…

Нәселле мәчеләр авыруларга, стресска ныграк бирешә. Урамда табылган гади Барсиклар авыруларга яхшырак каршы тора, чөнки урам тормышы бу песиләрдә иммунитет формалаштыра. Алар тычкан да тота, башка хайваннар өчен дә кайгыртучан «нянькалар» булырга мөмкиннәр. Балалар белән дә дустанә мөнәсәбәттә булалар.

Кемдер кара яки җирән мәче уңыш китерә, дип әйтә. Безнең өчен барлык хайваннар да уңыш китерүчеләр. Без барысына да шулай яратып карыйбыз, бездә уңыш китерә-китерми дип аерулар юк.

Мәчеләр артык үрчеп китмәсен өчен, әлбәттә, иң киң кулланылган ысул – стерильләштерү. Әгәр ишегалдында хуҗасыз, йортсыз калган песиләр очрый икән, һичьюгы ул яши торган подвалларны бикләмәскә, песиләргә типкәләмәскә, әгәр дә подъездга кертү мөмкинлеге бар икән, кертергә кирәк. Гомумән, песиләргә яшәү урыны табарга тырышып карарга кирәк.

Төрекләр хайваннарга бик яхшы мөнәсәбәттә һәм безгә алардан өйрәнерлек нәрсәләр бар. Алар салкын вакытларда песиләрнең өсләренә одеял каплап куя».

Язмамны француз прозаигы Теофил Готьеның сүзләре белән тәмамлыйм: «Әгәр сезне мәче ошатса, ул сезгә дусты булырга мөмкинлек бирәчәк, ләкин хуҗа булырга беркайчан да юл куймас».

**Гарифуллина Чулпан Илшат кызы, 21 яшь**

## КҮЗ МЕҢНЕ КҮРӘ, ДИН БЕРНЕ СӨЙ, ДИ

*Мөселманнарга башка дин вәкиле булган хатын-кыз белән никахлашу тыела. Күптән түгел Россия мөселманнары диния нәзарәте шундый фәтва чыгарды. Әлеге карарның максаты – мөселман гаиләсе институтын ныгыту дип аңлаталар. Бу яңалык турында белгечләр ни уйлый? Милләтара, динара низагка барып җитмәбезме? Гаилә корам дип, дин алмаштыручылар артмасмы?*

### Алырга ярамый алмаска

Россия мөселманнары диния идарәсенең голәмәләр советы карары нигезендә, ил территориясендә динара никахлар, аерым алганда «китап кешеләре вәкилләре» (христианнар, яһүдләр. – Ред.) белән гаилә кору ярамый, бары тик аерым очракларда, җирле мөфти карары белән генә рөхсәт ителә. Фәтвада язылганча, башка диндә булган хатын-кыз Аллаһны – бер, Гайсә һәм Мөхәммәтне Аллаһның илчесе дип таныса, мөселман кешесенә хатын булып бара ала. Шул хатын-кыз Коръән кушканнарны үтәргә әзер икәнен дә белдерергә тиеш.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең Инстаграм сәхифәсендә бер кешенең соравына җавапта болай дип аңлатты:

– Безнең Россия Диния нәзарәтенә катнашыбыз юк. Шуңа күрә аларның карарлары Татарстандагы мөнәсәбәтләргә берничек тә йогынты ясамый.

Татарстан Диния нәзарәтенең голәмәләр советы да Россия Диния нәзарәте карары белән килешмәвен хәбәр итте.

– Россия Федерациясе территориясендә иң киң таралган хәнәфи мәзһәбендәге (мәзһәб – ислам диненең сөнни юнәлешендә хокук системасы яки дини агым. – авт.иск.) хокук мәктәбе нигезләмәләренә карасак, мөселман кешегә Китап рөхсәт иткән хатын-кызлар белән никахлашырга рөхсәт ителә. Аларга христианнар һәм яһүдиләр дә керә. Бу кагыйдә мәзһәбләр барлыкка килгәнче, ислам эрасы башланып киткәндә дә булган һәм хәзерге көнгә кадәр үз көчен саклый. Моннан тыш, дини мәсьәләләрдә Россиядә динара тынычлыкны һәм татулыкны сакларга тырышуны бик

мөһим дип саныйбыз, – диелә республика нәзарәте матбугат хезмәте җавабында.

Чечня Республикасы мөфтие Сәлах хаҗи Межиев сүзләренчә, башка дин тотучылар белән никахларны тыю күптәннән исламда инде гомум мәгълүм хакыйкать булып тора. «Исламда һәрвакыт башка дин вәкилләре белән никахка тыю булды. Бу хакта фикер алышу һәм сөйләшү дә кирәк түгел, әлеге мәсьәләдә бәхәсләр дә, каршылыклар да юк», – дип саный мөфти.

Мәскәү мөфтие Әлбир Крганов исә Россия мөселманнары диния нәзарәтендәге хезмәттәшләрен уйланырга өнди. «Голәмәләр советындагы вәкилләр чыгарган фәтвага хөрмәт белән карыйбыз, тик Коръәндә әйтелгәннән дә артыграгын әйтә алмыйбыз. Аллаһы Тәгалә Китап кешеләре белән никах рөхсәт итә. Башка дин вәкилен хатынлыкка алыргамы-юкмы – ир-ат эше», – диде ул.

Ислам дине тарафдарлары гына түгел, нәзарәт тәкъдимен башкалар да хупламагае әле. Россия православие чиркәве (РПЦ) мондый тыюның христианнар өчен дә булуын искәртте. Протоиерей Андрей Ткачев әйтүенчә, элек христианнар да башка дин тотучылар белән гаилә кора алмаган. «Хәзер йомшардык, эрегән туңдырма төсле. Бәлки, безгә дә шулай ук никах мәсьәләсендә бу юнәлештә эшләргә, кырысрак һәм катгыйрак булырга кирәктер?» – дип саный рухани.

Безнең хәзрәтләр бу уңайдан нәрсә уйлый икән дип, без Әл-Мәрҗани Җәмигъ» мәчете имамы Әнсар хәзрәт Мифтаховка мөрәҗәгать иттек.

– Һәр төбәкнең үз мөфтияте бар. Безнең дә үзебезнеке. Татарстанның барлык мең ярым мәчете Камил хәзрәт Сәмигуллинга буйсына. Башка мөфтиятләр кабул иткән фәтвалар безнең республикага кагылмый. Укып, танышып бара алабыз, әмма үзебез өчен закон дип кабул итмибез. Россия Диния нәзарәте чыгарган фәтвага килгәндә, Коръәндә бу мәсьәләгә бәйле барысы да аңлаешлы итеп язылган. «Маидә» (Аш яулыгы) сүрәсенең 5 нче аятендә болай диелә: «...сезгә фәхеш эшләрдән пакизә мөэминә хатыннар, янә сездән әүвәл китап бирелгән китап әһелләреннән фәхеш эшләрдән пакизә мөэминә яхшы хатыннар хәләл булды». Никах укылганда, гаилә башлыгы буларак, ир-ат мөселман булырга тиеш. Бу – бәхәс-

сез. Ә инде хатын-кыз мөселман булса хәерле, булмаган очракта, ул Аллаһы Тәгаләне танырга һәм ирен үз диненә күчәргә күндермим, балаларны ислам дине буенча тәрбиялим дип әйтергә тиеш. Ир-ат тора-бара хатынын ислам диненә акрынлап күндерә, өйрәтә, аңлата ала, – ди хәзрәт. Аның әйтүенчә, хәзерге вакытта Татарстанда үз теләге белән ислам диненә килүчеләр дә күп.

**«Диннән баш тарту – милләтне юк итү»**

Диннәр, мәдәниятләр, милләтләр гасырлар буе дустанә яшәгән Татарстанда бу яңалык ничектер кискен кабул ителде кебек. Белгечләр катнаш никахларны тыюга нинди караштa?

–Мөфтият мондый карарга юкка гына килмәгәндер. Хәзерге шартларда мөселманнар азчылыкны тәшкил итә, ягъни ассимиляцияләшү тенденциясе күзәтелә. Шәригать мөселман кызларына мөселман булмаган ир-атларга кияүгә чыгуны тыя, христианнарда да шул ук кагыйдә. Мөселманга исә башка дин вәкилен хатынлыкка алырга ярый, – диде адвокат Руслан Нәгыев. – Кайбер галимнәр шундый фикердә тора: халыкның азчылыгын тәшкил иткән илләрдә мөселманнарга башка дин вәкилләре белән гаилә кормау хәерлерәк. Барысы да мөселман булмаган хатын яисә ир белән никахлаша башласа, ни буласын күзаллап карагыз. Мәсәлән, халыкның 20 процентыннан артыгы гына – ислам динен тотучылар, ди, алар шулай эшли башласа? Минемчә, мөселманнар югалачак.

Сәясәт белгече Руслан Айсин әйтүенчә, дини тәгълиматларны белмәүчеләр, киң җәмәгатьчелек өчен нәзарәт чыгарган фәтва, күрәсең, берникадәр шаккатыргыч вакыйга булган.

– Ислам тәгълиматыннан чыгып фикер йөртсәк, хатын мөселман яисә Китап әһеленнән булса хәерле. Мәҗүси һәм дингә, Аллаһка ышанмаучыларны хатынлыкка алу катгый тыела. Диния нәзарәтенең документында да шул язылган. Шушы нечкәлекләрне белмәгән кешеләр өчен, әлбәттә, бу – вакыйга иде. Соңгы арада ислам дине тирәсендәге шау-шу да йогынты ясагандыр, бәлки, – ди сәясәтче.

Белгеч әйтүенчә, фәтвада татарлар өчен дә игътибар итәрлек сүзләр юк түгел.

– Кызганыч, татарның үзбилгеләнү принциплары югала. Ни сәбәпле? Шул ук катнаш никахлар аркасында. Андый гаиләдә туган

баланың үзбилгеләнүе билгесез, ул ни урыс, ни татар түгел. Шуннан инде бәла, аннан маңкорт чыга. Диния нәзарәте тәкъдим иткән документта бернинди каршылык та күрмим. Интерпретациясе, ягъни мәгънәсен аңлатып бирү төрлечә булырга мөмкин, – ди Руслан Айсин.

Ә бит мәхәббәтне милләт, дин, тел кебек төшенчәләрдән өстенрәк күрүчеләр дә юк түгел. Хискә бирелеп, диненнән баш тартучы яисә динен алмаштыручылар бар. Мондый чикләүләр бәрабәренә андыйлар тагын да күбәймәсме соң?

– Кеше ул – үзе генә бик зәгыйфь берәмлек. Җәмгыять капризларына гына иярсәң, дин дә таркала, башкасы да, әллә нәрсәләргә барып җитә алабыз. Нигез булып торган төшенчәләр бар. Аларны үзгәртү, бозу һич кенә дә дөрес булмас. Шуның берсе – дин тәгълиматы. Ул үзгәрми. Европа илләренә күз салсаң, анда хәзер ир-ат һәм хатын-кыз төшенчәләре дә югала бара. «Гендер 1», «гендер 2» дип әйтәләр хәзер. Ислам дине исә әнә шул фундаменталь принциплар сагында тора. Мәхәббәт – мәхәббәт инде ул. Мәхәббәт ул – хис. Хис юкка да чыгарга мөмкин. Хәзерге күпчелекнең дин тотуы да – формаль күренеш кенә инде ул. Тәре яисә ярымай тагып йөрү белән аның дингә катнашы бетә дә, – дигән фикердә Руслан Айсин. – Татарны ислам дине саклап калды. Ул безнең тормышта гаять зур урынны алып тора. Аннан баш тарту – милләтне юк итү дә, ахмаклык та.

Фотограф Флүн Вилданов фикеренчә, хәзер никах ниндидер бер максат белән генә башкарыла торган формаль гамәлгә әйләнеп бара, моңа җитди карамаучылар да җитәрлек.

– Күпләр – урыслар һәм башкалар – никахка ник ризалаша? Ничек тә булса кияүне яисә кәләшне үзенеке итәр өчен. Никах динле, ислам кагыйдәләре буенча яшәгән кешегә укылырга тиеш. Ислам динендә икән, аның хәләл җефете дә мөселман була. Бу мөселман кешесе өчен яңалык түгел! Фәтва чыгаручыларның да төп фикерләре шул иде. Никахка бик җиңел караучылар күбәйде, традициягә, модага әйләнде бу. Никах декорациягә әйләнеп бара. Диндә түгелсең икән, андыйларга ЗАГС ишекләре ачык, язылсыннар, торсыннар, – ди ул.

**Бу – кызык!**

Патша Россиясендә төрле халыклар арасында гына түгел, төрле сословиеләр арасындагы никахлар да сирәк күренеш була. Катнаш гаиләләрнең массакүләм күренешкә әверелүе Бөек Ватан сугышыннан соң башлана. 1950 елда мондый гаиләләрнең өлеше 10 процентка җитә. 1959 елда аларның саны илдәге барлык никахларның 10,2 процентын (5,2 млн) тәшкил иткән, 1979 елда – 9,9 млн яки 14,9 процент, ә 1989 елда – 12,8 млн яки 17,5 процентка җитә.

**Габдуллина Энҗе Алмаз кызы, 20 яшь**

# СУСЛОНГЕРДАН РЕПОРТАЖ: «АЧЛЫКТАН ШЕШЕНГӘН ИРЕНӘ ХАТЫНЫ КҮКРӘК СӨТЕНӘ ХӘТЛЕ ИМЕЗГӘН»

«Бигрәк ябык күренәсең. Суслонгердан качтыңмы әллә?» Халык телендә әлегә кадәр калган бу атама сугыш чорында булган мәхшәрне кабат искә төшерә. Юк, фашист концлагеры да түгел, дөбер-шатыр бомбалар шартлаган яу кыры да түгел, күрше Мари республикасы Звенигово районындагы урман эчендәге бер авыл атамасы ул.

Мари урманнары эчендә урнашкан Суслонгер хәрби өйрәтү лагерьлары ише базалар күп булган. Әмма нәкъ менә шушы лагерьдагы кешелексез командирлар хәрби хезмәткә чакырылган ирләрне интектергеч үлемгә дучар итә.

Халык телендә калган хатирәләр буенча, бу хәрби лагерьга җибәрелгән ир-егетләрне ач тотып газаплаганнар, бик күбесе шунда үлгән дә.

Нәрсә булган? Нигә алай явызларча кыланганнар? Нигә меңләгән солдат фронтта түгел, ә үзебезнең урманнарда ачлыктан, ялангачлыктан һәм салкыннан кырылган? Әлеге сорауларга җавапны беркем дә бирә алмый. Хәзер Суслонгер хәрби лагеры булган җирдә землянка, склад урыннары һәм бар мәхшәрне күреп торган Көмеш күл генә исән. Сугыш үткәнгә күп еллар узган булса да, архивтагы документлар һаман да хәрби сер итеп саклана.

## «Биредә һәлак булучылар саны билгесез»

Хәрби лагерь Звенигово районы Суслонгер дип аталучы шәһәр тибындагы бистәдән чама белән 10-12 чакрым тирәсе ераклыкта урнашкан була. Бистәдә яшәүчеләр дә лагерьда булган хәлләрне ачыргаланып сөйли. Дөрес, аларның да күбесе инде бакыйлыкка күчкән.

Галина ханым Лихачева Суслонгер урта мәктәбендә математика укытучысы булып эшли. Лагерь территориясен күрсәтүен сорагач, ул биш куллап риза булды. Нәкъ менә Галина ханымга мөрәҗәгать итүебез юкка түгел – ул Суслонгер хәрби лагеры турында ныклап

өйрәнгән, казу эшләре алып барган, архивларны ачуларын сорап йөргән белгеч тә.

Суслонгер бистәсеннән чыгып, хәзерге көндә дә поездлар йөргән тимер юлны үттек, асфальт юл буйлап киттек. Аннары юлдан сулга борылып, нарат урманына керәсе. Уң якта ике күрсәтмә-язу кала. Берсе – Көмеш күл турында элмә такта, икенчесе – хәрби лагерьда һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлләр. Лагерь урынына илтәсе юл буенча наратларга кызыл тасмалар элеп чыкканнар. Монысы да килеп карачылар адашмасын өчен.

Суслонгер хәрби лагеренда 46, 47 нче укчы дивизияләре төзелә. 1943 елда алар 56, 57 нче дивизияләр дип үзгәртелә. Суслонгер хәрби лагерына Арча, Кукмара, Теләче, Саба, Югары Ослан районнарыннан чыккан кешеләр күпләп әлгә. Чөнки Казан тирәсендә төзелергә тиеш булган 31 нче бригаданы да Суслонгерга күчерәләр. Алар, биредә хәрби күнекмәләр алганнан соң, фронтка китәргә тиеш була.

– Лагерьда татарлар, руслар, марилар гына булмый. Бирегә үзбәкләрне дә алып киләләр. Аларның өсләрендә бер кат халат була. Ә 1941 кышы коточкыч салкын килә. Лагерьда тудырылган шартлар аркасында алар исән кала алмый.

Күбесе хәбәрсез югалган булып исәпләнә. Кайберләренең туганнарына фронтта һәлак булды дигән хатлар килә, – ди Галина ханым.

Суслонгерда һәлак булучылар саны билгесез. Халык бик күпләп кырыла монда.

«1941-1945 елларда шушы җирләрдә ачлыктан-ялангачлыктан, зәмһәрир салкыннардан, төрле авырулардан газап чиккән һәм вафат булган якташларыбыз рухына дога булып ирешсен», – шушындый эчтәлектәге ташлар, хәтер такталары биредә берничә.

Галина ханым сөйләвенчә, Суслонгерда һәлак булучыларга куелган һәйкәлләргә ел да киләләр. Яңаны куючылар да бар, аларны гел карап, чистартып торалар.

**«Әсирлеккә эләксәгез, татарча сөйләшегез»**

Элеккеге лагерь территориясенә аяк басканда ук күңелгә шом йөгерде – безнең алда коточкыч зур мәйданны алып торган наратлык. Лагерьның мәйданы күпме булу турында төгәл мәгълүмат юк, әмма бер хатта лагерь территориясе сигез гектардан да күбрәк булуы әйтелеп үтелә.

– Шул чордагы бер хат саклanган. Анда мәйданның сигез гектардан да күбрәк булуы, кешеләрнең сиксәннән алып йөз меңгә кадәр булуы язылган. Хат авторы якыннарыннан ашарга алып килүләрен сораган. «Толокно (солыдан ясалган он) булса да алып килегез, аны су белән бутап, ашап була», – дип язган.

Биредә ашханәләр дә, ипи пешерү цехлары да, кер юу урыннары да, мунчалар да, һәр дивизиянең үзенең аерым клублары да була. Дөрес, ашханәләрнең төрлесе була инде. Арсентий дәдәйнең бабасы шушында пешекче булып эшли. Ул: «Без малайлар белән көн дә бер дивизиянең клубына кереп, кино карый идек», – дип сөйли торган иде, – ди Галина ханым.

Сугышка кадәр әлеге урында ташландык полигон булган. Территория ачык торган, берән-сәрән генә агачлар үскән. Хәзер наратлар бөтен җирне каплап киткән инде. Әмма уң якта, калкурак булып торган турыпочмаклык формасындагы урында агачлар юк. Җирле халык сөйләве буенча, лагерьга керү белән уң якта штаб урнашкан була. Әлеге турыпочмаклыкның нәкъ менә штаб булуы бик мөмкин икән.

Сул яктагы берничә турыпочмаклыкны клуб урыннары дип фаразлыйлар. Чөнки казу эшләре барышында ул җирдә күпләп кинопленкаларның футлярлары табыла.

– Татарстаннан бер абый үзенең бабасын эзләде. Бабайның лагерьдан чыгып йөрү хокукы булган, ул туган авылына да берничә тапкыр кайтып килгән. Анда исә авыл ирләрен «вербовать» иткән, ягъни чакырып йөргән. Аннары бабайның шул сүзен исләрендә калдырганнар: «Сез русларга охшамагансыз. Әгәр дә әсирлеккә эләксәгез, татарча сөйләшегез», – дип өйрәтәләр», – дигән ул. Шуңа күрә без әлеге лагерьда диверсантларны да әзерләмәделәр микән дип уйлыйбыз. Ә әлеге бабай сугыштан соң Суслонгерда төпләнеп,

икенче гаилә кора. Оныгы әтисенең васыятен үтәде – бабасының каберен булса да тапты, – ди Галина ханым.

Шулай ук лагерь территориясендә «фильтрация» лагеры булган дигән шик тә бар. Валентина Зобованың «Дорогами ада» дигән китабында Суслонгер бистәсе сурәтләнеп кителә. Аның әтисе сугыш башланганда Литвада чик сакчысы булып хезмәт итә һәм әсирлеккә эләгә. Әлеге китапта аның концлагерда ничек исән калуы, ә әсирлектән котылгач, Суслонгерда фильтрацион лагерьда булуы сөйләнә.

Китап күпчелек әтисенең хатирәләренә таянып язылган. Шулар арасында аларның тимер юлга чыгулары да әйтеп үтелә. Галина ханым фикеренчә, китапта Суслонгер лагерыннан бистәгә таба сузылган тар тимер юл турында сүз бара. Хәзерге көндә әлеге тимер юлның җирне күтәртеп ясалган урыны һәм бер ягында тукталыш кебек җире генә калган.

### «Землянкада янгын чыккач, күбесе чыгалмыйча тончыгып үлә»

Урман юлыннан алга таба үттек. Сул якта берсе артыннан берсе тезелеп киткән землянка чокырлары күренеп тора. Аларда йөзгә якын кеше яшәгән. Солдатлар ике катлы сәкеләрдә, агач ботаклары салынган капчыкларны баш асларына куеп йоклаганннар. Кешеләр бик күп була.

– Бирегә солдатларны йөзәрләп кенә алып килмиләр, көн саен мең ярымлап солдат өстәлә барган. Безнең бистәдә яшәүче бер бабайның сөйләгәне бар иде, кечкенә чакта шушында килә торган була алар. Бер землянкада төнлә янгын чыга. Чыгу юлына якын яткан кешеләр генә чыгып котыла, калганнары башта искә тончыгып, аннары янып үләләр. Аңлыйсызмы? Алар селкенә алмаслык дәрәҗәдә тыгыз итеп яткан булалар, хәтта чыга да алмый калалар, – ди Галина ханым.

Офицерлар 1943 елга кадәр Суслонгерда яшиләр. 43тә исә лагерь территориясендә офицерлар өчен махсус йортлар төзелә. Сугыштан соң әлеге йортларны бистәнең Мәктәп урамына күчерәләр.

– Безнең Ида Алексеевналарда Векслер фамилияле подполковник яшәгән. Аның ике кызы булган. «Башта бездә, аннары лагерьда

яшәделәр. Минем аларга килгәнем дә булды әле. Ул подполковник безгә ак ипи алып килә иде. Әни безгә дип бүлә, аннары әбигә дә калдыра. Без икенче авылга әбигә ипи кисәге алып бара идек», – дип сөйли иде.

Офицерларның бистәдә яшәүләре кемнәрдер өчен яшәү, кемнәрдер өчен рәхәт алу чыганагы булып тора. Өйнең бер ягында балалар ачлыктан интегеп утырса, икенче ягында хатыннар офицерлар белән типтерә. «Андыйлары да булган», – ди Галина ханым.

### «Иренә күкрәк сөтен имезгән»

Бистәдә сугыш чорында хәрби госпиталь, хәрби зират та була. Бистәдә яшәүчеләр лагерьда пешекче, кер юучы булып эшлиләр. Ә солдатлар көне-төне агач эшкәртү эшендә. Гөрләп торган лагерьда ашханәләрнең генә дә төрлесе була. Онны суга бутап ашаган кешеләр ябыгып, дистрофикларга әйләнә.

Лагерьда ачлыктан дистрофикка әйләнеп беткәннәр өчен госпитальләрдә махсус урыннар билгеләнә. Бу лагерьдагы хәлләр турында белгәч, хатыннары, әниләре, көнгә берничә тапкыр җәяүләп барып, ирләренә ашарга алып килә торган була.

– Лагерь урынына кешеләр күпләп килә. Кемнеңдер бабасы, кемнеңдер әтисе, абыйсы, туганы шушында хәбәрсез югалган. Татарстаннан килгән бер апа бәләкәй генә килеш әнисенә ияреп, әтисе янына лагерьга килүен сөйләгән иде. Өйдә аларның күкрәк баласы калган була. Балаларга да ашарга юк заман. Булмаган ризыкны каяндыр табып, әтиләренә алып киләләр. Һәм ачлыктан шешенеп беткән ирен күреп, хатыны аңа күкрәк сөтенә хәтле имезә. Шундый дәрәҗәдәге кансызлык булган монда, шул дәрәҗәдәге…

### Ворошилов эзеннән

1943 елның беренче яртысыннан соң лагерьда хәлләр күпмедер дәрәҗәдә яхшырып китә. Чөнки Суслонгерга тикшерү белән Дәүләт Саклану комитеты әгъзасы Маршал Климент Ворошилов үзе килә. Бронировкалы поезд, машина белән килгән Ворошиловны җирле

халык койма өсләренә менеп утырып карап тора. Тик аның мондагы мәхшәр турында каян белүен һаман фаразлыйлар гына.

– Язучы Николай Сорокин «Вечная Волга» әсәрендә солдатларның бер вагонга агачлар арасына яшереп бер солдатны тыгып җибәрүләре турында яза. Ул солдат Мәскәүгә барып җитеп, мондагы кансызлыкны ничек тә булса җитәкчеләргә җиткерергә тиеш була. Тик лагерьдан килүче тимер юл тар була, бистәдә вагоннарны бушатып, икенче вагоннарга тутырганнар. Язучы язганча булса, ул кешене барыбер күрерләр иде. Аннары әсәрдә поезд Мәскәүгә өч көндә барып җитә дип языла. Йошкар-Олада безнең данлыклы академик Вавилов яши. Аның истәлекләрендә эвакуация вакытында Мәскәүгә ике атна буе барулары әйтеп үтелә.

Икенче фараз да бар халык арасында. Яралы солдат госпитальгә эләгә, ә аның туганнары арасында Ворошилов белән эшләүче кеше дә була. Һәм шул кеше аркылы биредәге хәлләрне Ворошилов та белеп ала. Бу фараз белән күбрәк килешеп була, – ди Галина ханым.

Суслонгер белән бәйле истәлекләрнең кайсы дөрес, кайсы уйдырма икәнен белеп булмый. Мондый сүзләр дә йөри – Ворошиловның киләчәген лагерь җитәкчеләре алдан белгән һәм ябык, ялангач, хәлсез солдатларны урманга яшергәннәр. Ворошилов каршына бары тик әйбәт киенгән, ябык булмаган солдатларны гына китереп бастырганнар. Маршал китеп баргач, урманга җибәрелгән солдатларны кире алып кайтканнар. Тик Ворошилов нәрсәдер сизенгән булган, күрәсең, күпмедер вакыт көтеп торган һәм тиз генә кире әйләнеп килгән. Хәлсез, ач солдатларны күреп, ул барысын да аңлаган һәм лагерь командирын атып үтерергә боерык биргән.

– Командирны атып үтергәннәр дип әйтәләр. Тик безнең бер чыгарылыш сыйныф укучысы аның эзен 1945 елга хәтле тикшергән иде. Монда бары тик фаразлар, табышмаклар. Иң дөрес мәгълүмат барыбер дә архивларда гына саклана, – ди Галина ханым.

Ворошилов белән бәйле тагын бер истәлеккә еллар узгач кына тап булалар. Бабасы Суслонгерда хезмәт иткән бер ир-ат бабасының кабере көньякта табылуы турында сөйли. Фараз буенча, Ворошилов, хәлсезләнеп беткән солдатларны күреп, аларны берничек тә фронтка җибәреп булмавын аңлый. «Боларны сугышырга түгел, тернәкләндерергә кирәк бит», – дип аларны көньякка дәваланырга

җибәрә. Шуңа күрә Суслонгерда булган кайбер солдатлар көньяк республикаларга җибәрелә.

## «Ике диндәгечә итеп гыйбадәт кылгач, урман тынып калды»

Биредә яшәүчеләр әлегә кадәр урманда йөргәндә кеше тавышлары ишетелә дип сөйли икән. Газапланып үлгән кешеләрнең җаннары тынычлансын дип, 2014 елны бер һәйкәлне урнаштырганда батюшка белән мулланы да чакыралар. Христиан диненчә дә, ислам диненчә дә гыйбадәт кылалар.

– 2014 елга кадәр хәтта кошлар да сайрамый иде монда. Ике диндәгечә дә итеп тә укыгач, үзгәрде. Югары Осланнан ел да килүчеләр бар. Алар да: «Карагыз әле, кошлар да сайрый башлаган бит монда», – диделәр, – дип сөйләде Галина ханым. Аның үз истәлекләре дә бар.

Укучыларым, аларның әти-әниләре белән Көмеш күл буена ял итәргә бардык. Шунда күл өстендә пар күтәрелеп, түгәрәкләнә башланды һәм төрле фигуралар күренде. Шуңа өстәп, күл өстенә түп-түгәрәк ай калыкты. Әлбәттә, шомлы да, куркыныч та. Солдатлар, нишләргә белмәгәнлектән, Көмеш күлдә батып үлгән. Үзләре теләп, аңлап, суга сикергәннәр һәм тормышларын шулай һәлакәт белән тәмамлаганнар.

Көмеш күлне дайверларның да тикшергәне бар. Алар әйтүенчә, күл төбендә ниндидер хәрби техника да бар. Көмеш күл үзе карст катламы ишелү нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Шуңа күрә төптә әле агачлар да бар, – дип сөйләде Галина ханым.

Сугыш беткәч, лагерьны тараталар. 1946 елны солдатларны Йошкар-Ола янындагы «Харинская мельница» дигән җиргә алып китәләр, аннары Калининградка җибәрәләр. Бистәдә яшәүче бер ханымның ике туган апасы шушы лагерьда кер юучы булып эшли. Ул да солдатлар белән бергә Йошкар-Олага, аннары Калининградка да китә. Туганнарның үзара элемтәсе дә шунда югала.

Әлеге лагерь аша танылган кешеләр дә үтә. Алар арасында футбол буенча халыкара дәрәҗәдәге арбитр Марк Рафалов әле дә исән. Аның «Футбол оптом и в розницу» дигән китабында бер бүлек Суслонгерга багышланган. Шулай ук танылган кинорежиссер

Станислав Ростоцкий да Суслонгер һәм аның янындагы Сурок лагерьлары аша үткән кеше. Аның исә әлеге өйрәтү лагерьлары турында документаль фильмы да бар.

– Суслонгердагы кебек шартлар башка лагерьларда да була. Дөресрәге, ул заманда алар ил буйлап таралган булалар. Мисал өчен, Пенза өлкәсендә урнашкан лагерь. «Летят гуси» дип аталган китапта ул лагерьлар турында язып үтелә. Энәсеннән җебенә кадәр туры килә. Варварлык дип кенә атап була инде моны. ГУЛАГның филиаллары дип тә юкка гына атамаганнар, – ди Галина ханым.

### «Янгын вакытында архивтагы документлар янып бетте, диделәр»

Ничәмә-ничә еллар буена архивтагы документларның сер булып саклануы гаҗәп түгел. Суслонгер ише лагерьларда булган бар дөреслекне ачып бирү ил тарихына кара тап булып төшәргә мөмкин. Шуңа күрә тарихчыларга да, туганнары шушы кансызлык оясында вакытсыз һәлак булучыларга да, ничек кызганыч яңгырамасын, бары тик язмышка буйсынасы кала. Архивлар ачылмаган.

– 90нчы елларның башында шушы эш белән кызыксына башладым. Хәрби комиссариатка барып: «Бездә шундый-шундый өйрәтү лагеры булган», – дидем. Ничек акырганнарын белсәгез. Башта: «Бездә бернинди дә лагерьлар булмаган!» – диделәр, аннары: «Ул сиңа кирәкме?» - дип сорадылар. Тик бу бит безнең тарих.

Подольскидан алып кайткан документларда бөтенесе дә әйбәт итеп сурәтләнә. Ялган документлар дигәнемә директор: «Җирле халык та уйлап табып сөйләргә мөмкин», – диде. Аңа: «Документларны идеаль итеп ясап була. Сез дә боерыкларны, документларны үзегезгә кирәк булганча итеп тутырасыз. Алар да барысын да уйлап, әйбәт эшлибез дип котылганнар», – дидем. Боерыкларны үзгәртеп язу бернәрсә дә түгел чөнки.

Подольскидагы ачык архивларны да карап, өйрәнеп булмый. Чөнки, мисал өчен, лагерьның планы ясалган битне өстеннән икенче бит белән беркетеп куйганнар. Аннары: «Янгын вакытында булган документлар барысы да янып бетте», – диделәр. Ни өчендер «дөресләнгән» документлар янмаган, ә калганнары янган? – дип өзгәләнә Галина ханым.

## Суслонгер белән дошман әсирлегенең аермасы: «Концлагерьда безне ашаттылар»

Суслонгерны күпме генә яшерергә, онытырга тырышсак та, ул тарихта булган кызганыч факт. Хәзерге көндә тарихчыларның гына түгел, гади кешеләрнең дә мари урманнарында ниләр булганын беләсе килә. Архивлар берәр кайчан ачылырмы? Командирлар нигә шулай явыз кыланган соң? Бу хакта Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы җитәкчесе Михаил Черепановның да фикерен белештем.

– Әлеге лагерь тылда солдатларны сугышка әзерләү максатыннан төзелә. Элементар командаларны, төрле хәрби бурычларны үтәргә өйрәтергә тиеш булалар анда. Тик нәкъ менә Суслонгердагы лагерьның командиры «уголовник» булып чыга. Һәм лагерь җитәкчелеге нәрсә бар – он, азык-төлек, кием-салым һәм башка нәрсәләрне сата башлыйлар. Бистәдән 10 чакрым гына ераклыкта урнашкан лагерьда шул командирлар аркасында меңәрләп солдат кырыла.

Минем Суслонгерда да, фронтта да, аннары дошман әсирлегендә - Дахау концлагерында булып, өенә исән-имин кайткан ветеран белән сөйләшкәнем булды. Шунда аннан: «Суслонгер белән Дахау арасында нинди аерма бар?» – дип сорадым. Беләсезме нәрсә дип җавап бирде? «Концлагерьда безне ашаттылар», – ди.

Минем Суслонгерда да, фронтта да, аннары дошман әсирлегендә Дахау дип аталучы концлагерьда булып, өенә исән-имин кайткан ветеран белән сөйләшкәнем булды. Шунда аннан: «Суслонгер белән Дахау арасында нинди аерма бар?» – дип сорадым. Беләсезме нәрсә дип җавап бирде? «Концлагерьда безне ашаттылар», – ди.

Лагерьдагы ипи пешерү цехының җитәкчесе, кызганыч, татар була. Исем-фамилиясен әйтеп тормыйм. Аны нишләптер кулга алмыйлар. Һәм шушы кеше сугыштан соң Казан базарына килеп, сугыш чорында авылда ике йорт салуы белән мактанып йөри. Ике йорт! Үзе үлгәч, аның мәете берничә көн үлгән җирендә ята. Мөселманнар аңа тиеп тә карамый.

Лагерьга көн саен меңәрләгән солдатны алып киләләр. Аларның күпмеседер фронтка эләгә, күбесе ачлыктан-ялангачлыктан һәлак була, качарга теләгәндә атып үтерелә. Монда мактанырлык

бернәрсә дә юк һәм шуңа күрә дә архивларны беркем дә ачмый. Фронтта һәлак булучыларны да 2006 елга кадәр әйтми йөрделәр. Ә Суслонгерны инде бөтенләй дә әйтеп торасы юк. Ул архивлар беркайчан да ачылмас кебек.

Шулай да минем үземнең тикшереп караганым булды. Суслонгерга күпчелек кулак дип саналган кешеләрне озатканнар. Ә Татарстанда андыйлар 200 мең тирәсе була. Ул чорда кулак – халык дошманы дигәнне аңлаткан, шуңа күрә аларны бер дә жәлләп тормаганнар да инде. Әбиләрнең сөйләгәнен хәтерлим: хәрби комиссариат каршында көтеп торганда кемнең кая китәсен әйтә торган булалар. Әгәр дә Суслонгер дип әйтсәләр, бөтен кеше ята-ята елый торган була, чөнки аның нинди җир икәнен бөтенесе дә белгән. Магаданга киткән кебек була инде ул заманнар өчен.

Бистә вокзалыннан ерак түгел авыл зираты бар. Госпитальдә үлүчеләрнең каберләре шунда дип әйтәләр. Әгәр дә алар госпитальдә үлгән булсалар, каберендә нәрсә дә булса булырга тиеш. Исем-фамилиясе язылырга яки йолдызлар куелырга тиеш. Ә ул туганнар каберлегендә бернәрсә дә юк. Һәлак булучыларның туганнары белән Суслонгерда гел булып торабыз. Зиратны да, лагерь территориясен дә ничек тә булса билгеләп куясы килә.

Әле 9 нчы май көнне Суслонгерда автоузыш үткәрделәр. Мин моңа каршы. 9 нчы май белән Суслонгер янәшә дә тормый. Дөрес, анда да солдатлар хезмәт иткән. Тик Җиңү безгә Суслонгер ярдәме белән килмәгән. Әгәр Суслонгер кебек лагерьлар булмаса, без иртәрәк тә җиңгән булыр идек. Безнең солдатлар шул ук безнекеләр кулыннан үлгән бит анда, – дип сөйләде Михаил Черепанов.

## Догада булыйк

Хуш исле нарат урманында ишелгән землянкалар карап йөргәндә «сугышлардан Алла Сакласын, күкләребез аяз булсын» дигән теләкне мең дә бер тапкыр кабатладым. Каен җиләге, нарат сагызы исе таралган тып-тыныч саф һавалы урман юлында басып торганда тәннәр чемердәп китә. Бөек Ватан сугышында ил сагында торган солдатлар белән бергә шушындый коточкыч җирләрдә ачлыктан, ялангачлыктан интегеп һәлак булучы солдатларның да урыннары оҗмахта булсын. Сугыш афәтләрен күрергә язмасын иде бит!

# Драматургия



# 12-14 яшьлекләр

**Зәкива Диләрә Фирдәвес кызы,**
*Җитәкчесе: Зәкиева Энҗе Фаиз кызы*

## «ӘЛЛИ-БӘЛЛИ, БИШЕГЕМ...»

(Бер пәрдәдә, 5 күренештә)

**Катнашалар:**

**Галия** – авыл хатыны, 48-50 яшьләрдә. Авылча киенгән: башында артка чөеп бәйләнгән яулык, озын итәкле күлмәк, күлмәк өстеннән – алъяпкыч, аягында – бәйләнгән оекбаш. Тиз сөйләшә.

**Тимергали** – аның ире, 52-54 яшьләрдә. Авылча киенгән. Салмак кына, мәкальләр, әйтемнәр кулланып сөйләшә.

**Нияз** – аларның уллары. 24-26 яшьләрдә. Заманча, ләкин әдәпле киенгән.

**Алинә** – киленнәре. 20-22 яшьләрдә. Шәһәр кызы, бик тәрбияле.

**Айсылу** – кодагыйлары. 48-50 яшьләрдә. Үзсүзле.

**Марат** – кодалары. 50-52 яшьләрдә. Аралашучан.

### Беренче пәрдә

1 күренеш

*Галия белән Тимергалиләрнең өй эче. Аш бүлмәсе һәм йокы бүлмәсе күренә. Аш бүлмәсендә уртада – түгәрәк өстәл, шкаф, суыткыч тора. Өстәл өстендә җыеп куелган чәй йомрылары, чәйнүк. Чигүле сөлге белән капланып куелган ипи, печенье. Галия аш бүлмәсендә токмач кисә. Әкрен генә көйли.*

**Галия:**

Баламның баласы,
Күземнең карасы,
Балдан шикәрләрдән татлы
Мәхәббәт алмасы.
Картәниләр, картәтиләр булуы
Бәхет икән – онык тууы.
Яшәвемнең бездән соң да каласы

Әй, баламның баласы.
Баламның баласы,
Күземнең карасы,
Балдан шикәрләрдән татлы
Мәхәббәт алмасы.

Менә, Аллага шөкер, мин дә әби булдым! Хезмәттәшләрем оныкларын сөйләгәндә, әй көнләшә идем, көнләшә идем! Менә хәзер мин дә: «Безнеке алай итә, безнеке болай итә...» – дигән булып сүзгә кушылырмын, Ходай кушса. Иртән киләләр дә оныкларын сөйли башлыйлар, киләләр дә оныкларын сөйли башлыйлар! Әйтерсең, башка сөйләр сүзләре юк! Менә, минем дә онык туды! Онык! Кызым туды! И-и-их, тизрәк күрәсем килә, кулларыма алып сөясем килә инде үзен. Оныгым... Кызым... Менә, ашым өлгерсә, тәрәзәдән генә булса да барып күрербез инде, Аллаһ теләсә.

*Тимергали керә.Кулларын юа.*

**Галия:** Кердеңме, бабасы?

**Тимергали:** Менә сиңа иске авыздан яңа сүз! Нишләп «Әтисе»ннән «бабасы»на күчтем соң әле? Картаеп киттемме, әллә?

**Галия:** Соң, бабай булгач, бабасы инде. Оныгың тугач, бабайга әйләнәсең инде шулай... Әйдә, чәй генә эч тә, авыл тавыгы белән үзем кискән токмачлы ашны бала тудыру йортына илтеп кайтыйк. Киленнең хәлен белеп, оныгыбызны күреп кайтыйк. Кодагыйлар аш илткәндер инде илтүен, авыл тавыгына җитәме соң инде? Киленгә хәзер шулпа кирәк. Тизрәк савыгып, өйгә кайтсыннар. Оныгымны тизрәк сөясем килә!

**Тимергали:** Мин өй түбәсеннән үзебезнең балалар үскән бишекне алып төшеп куйыйм дип йөри идем...

**Галия:** Җитешерсең әле, бүген үк өйгә кайтмыйлар, ләбаса.

**Тимергали:** Соң, шулай дисәң генә... Калган эшкә кар яумаса ярый инде... Җыен, алай булгач. Юл кешесенең юлда булуы хәерле...

2 күренеш

*Бала табу йорты бинасы. Тәрәзәләргә палаталарның номерлары куелган. Галия белән Тимергали, сумкаларын тотып, тәрәзәләрне карап, эзләп йөриләр.*

**Галия:** Җиденче палата дигән иде. Җиде кайда? Күрәсеңе? Ә-әнә, тегесе бугай. *(Кычкыра)* А-ли-нә! Алинә ди-им! Ишетте! Күрде! Әйе, әйе! Килдек! Менә икебез дә килдек! Әтиең дә килде! Ничек хәлең? Хәлләрегез ничек дим. Кыз ничек? Елыймы? Кемгә охшаган? Миңа..? *(Тимергалигә карап, сөенеп)* Миңа охшаган, ди бит! Иии, рәхмәт яугыры! Үземнең оныгым үземә охшаган! Ярый, озак басып торма! Бар, ят! Өзлегә күрмә! Хәзер тавык ашын менгерерләр. Нygытып аша! Ашыйсы килми, димә. Сиңа ашарга кирәк! Китәбез, китәбез! Нияз эштә әле, эштә. Кайткач килер. Ярар, ярар. Әйе, кайтабыз, кайтабыз. Бәбәйне елатма! Киттек! Сау бул!!!

**Тимергали:** Бар, балам, бар! Саклангнны саклармын, дигән…

*Тимергали кул болгап саубуллаша. Галия сөйләнә-сөйләнә кайту ягына китәләр.*

ДӘВАМЫ БАР

## Фархуллин Әмир Раиф улы, 14 яшь

*Җитәкчесе: Гыйззәттуллин Илфир Рәхимша улы*

# ӘЗ ГЕНӘ КАЛДЫ

**Катнашалар:**

**Марат һәм Зилә исемле балалар**

Күршедәге бала – **Тәнзилә**

**Тәнзиләнең әти-әнисе**

**Айрат һәм Илсөяр** – Марат белән Зиләнең әти-әнисе

1 пәрдә

*Вакыйга безнең көннәрдә авылда бара.*

*Урам. Маратларның өе һәм күршеләрнеке күренә. Урамга Зилә белән Марат чыга.*

**Зилә:** Марат, әйдә, әле берәр нәрсә белән уйныйк.

**Марат:** Әйдә, уйныйк.

**Зилә:** Эмм.. Бадминтон?

**Марат:** Юк! Әйдә, волейбол.

**Зилә:** Әйдә.

**Марат:** Туп алып килә аласыңмы?

*Зилә туп алып килә. Алар волейбол уйный башлый. Зилә Маратка ата. Марат тупны өскә чөеп ата. Аннан Зиләнең бәргән тубы күршеләрнең өенә таба оча һәм тәрәзәнең астына төшә. Ләкин тәрәзә ватылмый. Бу хәлне Тәнзилә күреп ала.*

**Тәнзилә:** Әстәгъфирулла! Нишлиләр инде, ә? Ә теге күршеләр икән. *(Тәрәзә янына килеп)* Сез нәрсә? Тубыгыз әздән генә тәрәзәне ватмады!

*Ләкин Зилә белән Марат аны ишетмиләр.*

**Зилә:** Ой, әздән генә тәрәзәгә тимичә калды, Тәнзилә күргән булса, йөзе ачулыдыр инде!

**Марат:** Әй, борчылма, тимәде бит! Кара әле, безнең туп алар бакчасында, менә аны ничек алырбыз? Алар безне сүгәчәкләр, әйдә тиз генә өйгә кереп китик.

**Зилә:** Ярар, әйдә керик.

*Балалар кереп китәләр.*

**2** күренеш

*Күршеләр өе. Тәнзилә əти-әнисен көтеп тора. Үзалдына сөйләнә:*

**Тәнзилә:** Эх, шулар, әздән генә тәрәзәне ватмадылар, Менә əти белән әнигә әйбәтләп сөйләп бирәм мин алар турында, сүксеннәр әле аларны.

*Кыңгырау тавышы килә.*

**Тәнзилә:** Ах, əти-әнием кайтты. *(Тәнзилә ишекне ача)*

**Әнисе:** Нихәл кызым?

**Тәнзилә:** Бик начар шул, әни. Безнең тәрәзәгә туп белән бәрделәр, ул әздән генә ватылмады.

**Тәнзиләнең әнисе:** Нәрсә дисең? Я, әкрен генә сөйлә.

**Тәнзилә:** Күршедәге Марат белән Зилә инде! Ә тәрәзәбез ватылган булса, без аларны нәрсә эшләтер идек икән?

**Тәнзиләнең əти-әнисе:** Борчылма кызым, тәрәзәбезгә берни булмаган. Ватылса, әтиең яңа пыяла куяр иде.

**Тәнзилә:** Әни, аларның тубы безнең тәрәзә янында ята, тупларын яшереп куйыйк әле аларның.

**Тәнзиләнең әтисе:** Кызым, син тупны ал да күршеләргә кертеп бир.

**Тәнзилә:** *(теләмичә генә)* «Нәрсә, бирәсе мени? (Ул тупны алып күршеләрә кереп китә)

**Тәнзилә:** Зилә-ә! Мара-ат! Чыгыгыз әле, тубыгызны алып кердем! *(Балалар чыгалар һәм бергәләп урамның икенче башына китеп, туп белән уйный башлыйлар)*

# 📖 15-18 яшьлекләр

**Зәкиева Миләүшә Алмаз кызы, 17 яшь**

*Җитәкчесе: Шагаева Алия Юныс кызы*

## КАЯ БАРАБЫЗ?!

Пьеса 1 пәрдәдә, 4 күренештә

**Катнашалар:**

**Юныс** – гаилә башлыгы, 45 яшендәге ир-ат, мәктәп директоры, интеллигент, матур сөйләшә, сүзендә тора.

**Галимә** – хатыны, 40 яшендәге татар хатыны, врач, ипле, сөйкемле, балаларны укытуга зур көч куя.

Балалары:

**Госман** – уллары, 18 яшь, студент

**Миләүшә** – кызлары, 17 яшь, студент

**Мирьям** – төпчек кызлары, 9 яшь

**Күршеләре**:

**Рәфкать** – гаилә башлыгы, 70 яшьлек бабай, дәү әти

**Зөлфия** – хатыны, дәү әни

**Заһит** – урта яшьтәге ир

**Мәйсәрә** – Заһитнең хатыны

**Наил** – уллары, 7 яшь

**Укучы балалар**

1 пәрдә

**Мирьям:** Әтием, өй эшен эшләдем! Тыңлап кара әле мине!

Юныс: Фәнен дә әйтсәң...

**Мирьям:** Татар теле! Сочинение язарга иде, «Минем гаилә» дигән. Тыңла инде.

**Юныс:** Болай булгач, барыбыз бергә тыңлыйк. Әнисе, балалар, килегез! Сочинение тыңлыйбыз!

**Галимә:** И-и, балам, сочинениенең татарча тәрҗемәсе бармы аның?

**Госман:** Бар, әни! Бар!

**Миләүшә:** Мин дә беләм татарчасын. Ә менә бу балагыз – белми!

**Юныс:** Я, кызым, дорфаланма, килешми, булачак укытучыга. Иң кирәкмәгән сүзне әйттең хәзер.

**Мирьям:** Сочинение татарча – хмм. Сочин, әллә Сочи инде. Юктыр, алай түгелдер әле. Бер икъдисат дигән сүз шикелледер әле. Әллә оныттым инде. Әйтте бит апай миңа аны. Әйтте. Именно менә «сочинение түгел», – диеп әйтте бит. Эх, тутубаш мин, тутубаш! *(Абыйсы белән апасы кырыйдан көлешеп торалар)*.

**Госман:** Борчылма, сеңлем, битәрләмә үзеңне! Оныт инде тутубашны! Сочинение инша була ул!

**Мирьям:** Менә бит, исемә төште! Точно!

**Юныс:** Ике телне катнаштырып сөйләшү – зур әдәпсезлек бит ул, балалар! Бер авызны ачкач, бер телдә генә сөйләшү – тәрбия һәм зиһен билгесе. Я, кызым, иншаны тыңлыйк әле!

**Госман:** (эченнән генә) мине «тутубаш» диеп яздымы икән инде?

**Мирьям:** «Безнең гаилә».

Гаилә... Нәрсә ул? Гаилә ул – иң мөһим нәрсә. Гаилә туры барырга, бөтен авырлыкларны бергә җиңәргә тиеш. Мин дә үзебезнең гаиләбезне шундыйлардан дип саныйм. Безнең гаиләбез оешканга 21 нче сентябрьдә 23 ел була. Озын-озак бәхетле, мул, тулы, бәрәкәтле тормыш юлы аша узганнар минем әтием белән әнием. Мәхәббәт җимешләре булып, бер-беребезгә терәк булырдай, абыйны, апамны һәм мине тудырганнар алар. Безнең гаиләдә ир-ат, хатын-кыз эше дигән сүзләр юк. Бездә берәү дә, беркайчан да эшсез утырмый. Әтием белән әниемнең эшләре дә кешегә ярдәм итү: әти – укытучы, әнием – табиб. Алар һәрчак үзара сөйләшәләр, киңәшләшәләр, фикерләшәләр.

Гаиләбездә матур гадәт бар. Атна ахырында барыбыз бергә «Атна ничек узды?» дигән сөйләшү оештырабыз. Мин алып баручы. Сүз бирүче. Сорау бирүче.

Иң элек сүз әтиебезгә бирелә. Ул үзенең эше турында, матур гаиләләр турында уртаклаша. Әмма беркайчан да кеше турында

начар сөйләми. Без аннан кешенең үрнәк булырдай сыйфатларын гына генә ишетәбез.

Әти сөйләп бетергәч, әнигә сүз бирәм мин. Әниебез табиб – кеше врачы, диеп йөртә иде аны, дәү әниебез. Без көлә идек. Әни кешегә игътибарлы булырга, ничек авырмаска, нинди чирләрдән ничек сакланырга өйрәтә. Әни кешеләрне ярата. Кешегә олы хөрмәт белән карый. Төннең кайсы вакытында чакырсалар да, булыша. Әти аны аңлый. Ни кызык, алар беркайчан да талашмыйлар.

Госман абый зур кеше булырга жыена. Укый да, укый, укый да укый. Тагын әле эшкә дә урнашты. Алар апам белән татар-төрек лицеенда укыдылар. Бер дә кызык булмагандыр инде аларга: абый малайлар белән генә укыды, ә апам тик кызлар янында тәрбияләнде. Аларның атналары гел бертөрле уза иде. Әле ярый быел укырга керделәр. Ленин укыган җиргә. Тик менә Ленинны гына аңлатырга вакытлары юк әле. Мактанырлык булгач, зур кеше булгандыр инде ул! Бәлки бу атнада озак итеп сөйләрләр. Абыем белән апаем эшкә урнаштылар. Хәзер алар зур кеше – тәрбиячеләр. Балалар тәрбиялиләр. Хәзер акча ташып торыр инде.

Шулай итеп, әлегә абый белән апай укып, эшләп ничек итеп көн үткәргәннәрен сөйләгәндә, мин уйлап утырам. Ни дисәң, тагын татарчасы ничек була аның диеп сорарлар икән? Теләкләр теләшәбез, өйдәге эшләрне планлаштырабыз.

Өй эшләрен дә бергәләп эшләргә яратабыз. Әниебез тәмле итеп милли ашлар, ризыклар пешерергә ярата. Без апам белән бөтереләбез, кыстыбый, өчмочмак, дурчмак, кош теле, бавырсак… Санап китсәң, Юныс Әхмәтҗанов китабындагы шикелле.

Төп эшебез уку булса да, өй җыештыру, идәннәрне, савыт-сабаларны юу шикелле эшләр белән әниебезне борчымаска тырышабыз. Буш вакытларыбызда, бергәләшеп, кроссвордлар, сканвордлар чишәргә, компьютерда интеллектуаль уеннар уйнарга яратабыз. Әтиебез бик белемле, эрудит кеше безнең. Безгә дә күп кызыклы мәгълүмат бирә ул, без белмәгән һәм аңламаган күп нәрсәләрне гади һәм кызыклы итеп аңлатып бирә. Театрларга, концертларга да күп вакытта бергәләп йөрибез. Аннан бергәләшеп фикер алышабыз. Кемгә нәрсә ошаганын, нәрсә ошамаганын ачыктан-ачык сөйләшәбез. Әтинең «Иң яхшы жырчы?» соравына

бездә җавап һәрвакыт әзер: «Әни инде!» – ди абый. Апам «Илһам Шакиров», – диеп җавап бирә. Әни генә Салаватның җырлаганын бер дә яратмый. Миңа менә Таһир Якупов ошый, әтиемнең якташы икән ул.

Бездә һәрчак кунаклар күп була, чөнки туганнарыбыз, гаилә дусларыбыз күп безнең. Барысы белән дә тату, аралашып яшибез. Әтием дә, әнием дә – авыл балалары. Әти мишәр булса да, татарча матур сөйләшә. Аларга кунакка кайтканда гына күп әйбер аңлашылмый. Ну, кызык инде! Туйганчы шуларның цәцәкле цәйнекләреннән цәй эцәр идем!

ин үз гаиләмне бик тә яратам. Алар да мине яраталар. Мин аларның һәрчак сау-сәламәт, озын гомерле, бәхетле булуларын теләп яшим. Бөтен-бөтен гаиләләргә дә иң изге теләкләремне телим. Ә кешегә теләгән изге теләкләр унлата, йөзләтә савап булып кешегә кире кайта ул, кызым, дип әйтә иде минем дәү әни.

**Юныс:** Вәәт, ичмасам, минем кыз! Кызым, булдыргансың бугай шикелле. Партизан чыкмас синнән, балам! Алай да гаиләбез бик матур булып чыккан синең күзлектән. Рәхмәт сиңа!

**Галимә:** Бигрәкләр дә уңган икәнбез дә әле без!

**Госман:** Укымышлы да икән!

**Миләүшә:** Ленинның да бөеклеген өйрәтсәгез! Бер дигән гаилә булабыз инде. Балалар да тәрбиялисе бар бит безнең дә!

**Госман:** Ә, чыннан да, әти-әни! Сез бит безне татарча итеп тәрбияләдегез. Татар, рус сыйныфы турында сүз бармый иде бит безнең! Мәрьям дә татар сыйныфында күңеллерәк, ди.

**Госман:** Бик борынгыдан
бабалар аша
миңа да килеп җиттең.
Бирдең аң.
бирдең белем.
Хәзер инде
офыктагы маяк булып
алга чакыр,
татар теле,
Тукай теле,
туган теле.

ДӘВАМЫ БАР

**Закирова Нәзилә Фарсель кызы,16 яшь**

*Җитәкчесе: Юнысова Лилия Мирза кызы*

# ҖИР-АНА ЧАКЫРУЫ

(3 пәрдәдә)

**Катнашалар:**

**Кәрим** –5 нче сыйныф укучысы

**Галим** – 5 нче сыйныф укучысы

**Ләйсән** – биология укытучысы

**Шүрәле** – мифологик зат

1 пәрдә

*Урман аланлыгы. Тирә-якта ямь-яшел агачлар. Кошлар сайрый. Алан уртасында корыган агач кәүсәсе төсендә Шүрәле утырып тора, кулы агачка кыстырылган. Кәрим керә, кулына, җиләк җыяр өчен, кечкенә кәрҗин тоткан.*

**Кәрим:** *(куркудан күзләре зур булып ачыла, калтырый башлый,* шап итеп күтенә утыра, сүзен әйтә алмый азаплана). О-о-ой! Ке-ке-к-ем син? *(Тиз генә торып агач артына поса.)* Н-н-ни-и-шлисең мо-о-онда?

**Шүрәле:** Кычкырма, адәми зат. Курыкма, мин сине бернәрсә дә эшләтә алмыйм. Күрәсеңме, кулларым кысылган. Бөтен дөньяга сөрән салып кычкырганчы, булышыр идең. Атың кем синең?

**Кәрим:** *(куркып, калтырап) Бе-е-ел-мим. А-атсыз ми-ин.*

**Шүрәле:** Аңгыра малай. Исемсез кеше булмый. *(Үкереп.)* Исемеңне сорыйм.

**Кәрим:** М-м-и-н К-к-к-әрим. К-к-кем син?

**Шүрәле:** Исемеңне дә әйтә алмыйсың. Надан малай! Мине бөтен балалар да белә. Укымыйсыңмы әллә син?

**Кәрим:** *(калтыравын дәвам итеп)* Укый-й-м, 5 нче сыйныфта укыйм ми-ин. Минем сине кайда-а-дыр күргәнем дә бар, тик хә-ә-терләмим. Но, шу-у-ны беләм: син то-о-чно кеше тү-ү-гел.

**Шүрәле:** *(к*иная белән) Кара нинди акыл иясе, минем кеше түгел икәнне аердың.*(Уфтанып.)* Уф, акыллы кеше белән очрашсам иде дип, күпме теләсәм дә барып чыкмады. Син бөтенләй *(бармагы* белән башын бораулап күрсәтә) тилеме әллә? Мине дә белмисеңме?

**Кәрим:** Нишләп ти-и-ле булыйм. Мин күп белергә я-я-ратмыйм, бары шул гына. Бе-бе-ләсең килсә, күп бе-белгән кешенең башы-ы авырта, ди. Во-о-т!

**Шүрәле:** Ишәсең икән ишәк чумарын. Ул башны нәрсә дип йөртәсең соң син? Уйларга да ярамагач. Әллә авырумы син?

**Кәрим:** Ю-юк, инде, юк. *(Уйлана.)* Хәзер искә төшерәм. *(Сөенеп.)* Ә-ә-ә, «Тукай бабайның Шүрәлесе» бит син. Точно!

**Шүрәле:** Ниһаять. Надан булсаң да, тиле үк түгел икәнсең. Тик миңа аннан ни файда? *(Үкереп елый.)* Нәрсә дип йөрисең монда ялкау малай?

**Кәрим:** *(куркып).* Мин ни ни... Нигә үкереп е-е-елыйсың дип со-со-рыйсы идем.

**Шүрәле:** Сиңа сөйләсәң дә инде... Бер файда да чыкмас.*(Бер-берсенә карап торганнан соң.)* Мин Тукай Шүрәлесе түгел.

**Кәрим:** Алайса кем Шүрәлесе соң син? Кулың да агачка кыстырылган.

**Шүрәле:** *(авыр сулап куйгач)* Ярар, сөйлим инде. Сөйләмәм дигән идем, язмышым шулдыр. Тукай язган Шүрәле – минем бабам ул. Ул да минем кебек шук булган, өлкәннәр киңәшенә колак салмаган. Шуңа хаталарны да күп ясаган. Башкалар тырышып өйрәнгәндә, мин дә хәйләләргә яраттым. Шуңа күрә иң кирәкле белемнәрне өйрәнә алмадым. Һәм, әлбәттә, хаталарны да күп ясый башладым. Нинди генә хәлләр булмасын, өйрәнгән гадәт буенча төрле сәбәпләр табып, качу ягын карый идем. Булдырам, дип уйладым. Беркөнне ерак урман аланына килеп чыктым. Анда бик күп бөҗәкләр кайнаша: кайсы яфрак, кайсы кайры кимерә. Мин һәрвакыттагыча, берәүгә дә берни әйтмичә, бу урыннан китеп бардым. Алар кыска вакыт эчендә бик күп агачларны корытканнар. Урман хуҗасы белеп алгач, мине җәзага тартты. Башка Шүрәлеләр дә мине гафу итә алмады, алар ерак урманга күченде. Мине үзләре белән алмадылар. (Агачка күрсәтә.) Менә хәзер шушы агач аркасында, мин бу урманнан беркая да китә алмыйм. Кемдер килә башласа, яшеренәм. Киемем

дә агач төсенә кереп бетте. Шул сәбәпле генә мин әле дә исән. *(Авыр сулап.)* Тик мондый гомер кемгә кирәк соң?

**Кәрим:** *(батыраеп).* Мин сиңа хәзер булышам. *(Кырына ук килеп.)* Кая, нәрсә эшлим? Тик монда балтасыз берни дә эшләп булмый, бугай.

**Шүрәле:** Ашыкма, адәми зат. Син эшли торган эш түгел бу. Җитмәгәненә, әле синең белемең дә…

**Кәрим:** *(бүлдереп).* Минме, минме? Мин тырышсаммы?!

**Шүрәле:** Кәпрәймә. Сиңа бөтенләй ышаныч юк. Тукайның Шүрәлесен дә көчкә искә төшердең. Миңа Тылсымчы, урманны саклауның барлык кагыйдәләрен өйрәнгәч кенә, бу агачтан котылырсың, диде. Менә бер гасыр вакыт үтте, тик юлымда бөтенләй надан адәми зат, ягъни син очрадың.

**Кәрим:** *(әкрен генә башын аска иеп).* Минем яхшы иптәшем бар. Ул барысын да белә.

ДӘВАМЫ БАР.

## Минһаҗева Диләрә Рамил кызы, 15 яшь

*Җитәкчесе: Дәүләтова Рушания Фатих кызы*

### ЗАМАНА АУЛАК ӨЕ

Катнашалар:

**Әдибә** – 15 яшьлек авыл кызы.

**Әдибәнең әнисе**

**Мәрьям** – Әдибәнең дус кызы, бик чая, шат күңелле кыз. Матур бии.

**Сәрия** – Мәрьямнең күршеләренә шәһәрдән кунакка кайткан кыз. Тыйнак, җитди, матур җырлый.

**Марат** – Мәрьямнең абыйсы. Хәрби киемнән.

**Маратның дус егетләре**

*Вакыйга хәзерге заманда татар авылларының берсендә бара. Авыл өенең түрге ягы. Өй эче матур, пөхтә җиһазландырылган. Өстәл, диван, кресло, урындыклар, көзге, ноотбук. Бүлмәгә сөйләшә-сөйләшә әнисе белән Әдибә керә.*

**Әдибә:** Әни, онытылып калган әйберләрең юкмы, карап чыктыңмы?

**Әнисе:** Карадым инде, кызым, карадым. Аннары бер айга китмибез бит, иртәгә кичкә кайтып җитәрбез, Аллаһы боерса. *(Сәхнәнең икенче ягына, чыгып китү ягына бара-бара).* Кызым, берүк өйдә тәртип булсын! Кич чыгып йөрмә. Ишегеңне бикләп утыр. Беркемгә дә ачма. Үзең дә беләсең: бандит белән дөнья тулды хәзер. (*Әдибә әнисенең һәр сүзен «ярар», «ярар» дип җөпләп тора)*. Үзең генә курыксаң, Мәрьямне куна чакыр.

**Әдибә:** Әнисе кунарга ук җибәрмәс шул. Аннары Казаннан Сәрия дә кайткан кичә.

**Әнисе:** Юлдан үзем шалтыратырмын Кифая апаңа. Кызларны җибәрсен дип синең янга. Тыңламый калмас. Ярар, алтыным, сау булып тор. (*Әдибәнең бит очыннан үбеп чыгып китә).*

**Әдибә:** Әни, әни. *(Капкадан озатып, карап калам дип, әнисе артыннан ташлана. Бераздан бик күңелсез генә керә)*. Киттеләр. Бигрәк ямансу булып калды. Елармын да әле. *(Музыка куя, диван мендәрен кочаклап диванга менеп утыра. Музыкага кушылып җырлый)*. И, болай моңаеп утырып эш чыкмас, Мәрьямгә шалтыратып алыйм әле. *(Телефоннан шалтырата)*. Мәрьям, сәлам, хәлләр ничек? Синең шулай һәрвакыт ал да гөл булыр инде. Юк шул. Әниләр киттеләр. Берүзем моңаеп утырам. Ә, әни юл өсте сезгә кереп чыктымыни? Ничек соң, килә аласызмы? Хәзер үк килсәгез, бигрәк тә әйбәт булыр иде. А то елыйсылар килә. Ярар, көтәм. *(Кәефе күтәрелеп китә, күңелле ритм көйләп бүмәне җыештыра башлый)*. Кызлар килгәнче, бераз тәртипкә китерим әле. Караңгыга калмаслар алар, килеп җитәрләр. *(Икенче бүлмәгә кереп китә.)*

Ишектән Мәрьям белән Сәрия керәләр.

**Сәрия:** Әллә безне көтмәгән дә инде?

**Мәрьям:** Көтмәсә дә, кертмәсә дә кайтып китмибез инде.

**Әдибә:** *(Бүлмәдән чыга)* Нинди көтмәгән дә, нинди кертмәгән, ди ул. Әйдәгез, кызлар, узыгыз. Үз өегездә кебек булыгыз.

**Мәрьям:** Руслар әйтмешли, «Будьте как дома, но не забывайте что в гостях».

**Әдибә:** И шушының теле, бер җавапсыз калмас.

**Сәрия:** Әдибә, беләсеңме, ул мине өйдән өермә урынына очырып алып чыгып китте.

**Мәрьям:** Син ташбаканы көтсәң, таң атканда гына килеп җитүең дә мөмкин.

**Сәрия:** Соң, дуслар белән аралаша идем бит. Кызык видео җибәргәннәр иде, каратып бетермәде. *(Телефонын алып диванга утыра. Нидер карамакчы була)*.

**Мәрьям:** Юк инде, дускайларым, аулак өй икән, аулак өй инде. Бернинди телефон, интернет та юк. Мобильныйларны сүндерәбез.

**Әдибә:** Әйе шул, кызлар. Әйдәгез, әбиләр заманындагы кебек аулак өй ясыйбыз. Ул вакытларда аулак өйдә кызлар нәрсә эшләделәр икән?

**Сәрия:** Нишләсеннәр, сукыр лампа яктысында чигү чиккәннәр, җеп эрләгәннәр.

**Мәрьям:** Лампаң булмаса, берәр кул эшең бардыр әле.

**Әдибә:** Анысы җитәрлек. *(Түр бүлмәдән тартма алып чыга. Тартма тулы. Кызлар тартманы актара башлыйлар).*

**Мәрьям:** *(Тартмадан ыргак, энә белән бәйләнгән салфетка ала)* Карагыз, нинди матур. Моны бит бер генә әйләнәсе калган. Җебе дә бар.

**Әдибә:** Әллә кайчан бәйли башлаган идем инде мин аны. Вакытым булмаганга күрә, бәйләүдән туктадым. Сызымында тагын әллә нинди бизәкләр бәйләргә диелгән әле аның.

**Мәрьям:** Диелсә ни! Ә без аны бер әйләнеп чыгабыз да и все. Болай да бик матур бит инде.

**Сәрия:** *(Бәйләм әйбер күрсәтеп)* Миңа менә бу ошый. Бизәкләрен кара син аның.

**Әдибә:** Үрнәген интернеттан алган идем мин аның. Бик матур кебек иде. Бәйли башлагач, ошамый башлады. Мондыйны хәзер беркем кими.

**Сәрия:** Менә мин кияр идем. Шәһәрдә кулдан эшләнгән әйберләр һәрвакыт модада. Кая әле үзем бәйләп бетерим.

**Әдибә:** Мин, алайса, менә бу чигүне чигеп бетерәм. Әнигә бүләккә дип чигә башлаган идем. Туган көненә өлгертә алмадым.

ДӘВАМЫ БАР

**Шиһапова Диана Илдар кызы, 16 яшь**

# БЕРКАЙЧАН ДА СОҢ ТҮГЕЛ ...

(4 пәрдәле драма)

**Катнашалар:**

**Алия**

**Рәсим**

**Рәхилә** – Алия:нең әбисе

**Сәлимә** – Рәсимнең әбисе

**Нурсинә** – Алия:нең әнисе

**Марат** – Алиянең әтисе

**Асия** – авыл фельдшеры

**Әмир** – авыл егете. Рәсимнең иптәше

**Айнур** – авыл егете

1 пәрдә

*Авыл күренеше. Күл буе. Җәйге кич. Сәхнә ачылганда берәү дә юк. Ара-тирә бакалар бакылдавы ишетелә. Кошлар тавышы. Йөгереп Рәсим белән Алия: керә.*

**Алия:** *(пышылдап).* Кунакларны, иптәшләрне ташлап качу дөрес булырмы соң?

**Рәсим:** Борчылма, кадерлем. Алмазга мин барысын да аңлаттым. Кунаклар анаң карамагында.

**Алия:** Эх, ике-өч сәгатьтән без синең белән бер елга аерылышабыз.

**Рәсим:** «Гомер аккан су белән бер,» – диләр бит. Менә күрерсең, сизми дә калырсың, мин кайтып та җитәрмен.

**Алия:** Мин инде син кайтуга, медицина көллиятенең икенче курс студенты булырмын.

**Рәсим:** Киләчәктә мин – механизатор, ә син авылыбыз фельдшеры булып авылда төпләнсәк иде. Балаларыбыз шушы болыннарда җиләк җыярлар. Эх…

**Алия:** Минем авылда каласым килми. Әлегә бу мөһим түгел. Бүген син китәсең. Синсез бер ел ничек түзәрмен. *(Үпкәләгән, иркәләнгән була.)*

**Рәсим:** *(чәчләреннән сыйпап)* Әйе шул, исәнлектә күрешергә язсын! *(Үбешәләр.)*

**Алия:** Әйдә, югалтканнардыр, вакыт та бара.

*Кочаклашып чыгып китәләр. Таң аткан. Авыл күренеше, капка төбе. Рәхилә белән Сәлимә яшьләрне озатып, капка төбендә серләшеп утыралар.*

**Рәхилә:** Әйдә, Сәлимәкәем, хәерле юллар булсын, илләр имин булып, Рәсим тыныч кына хезмәт итеп кайтсын дип, дога кылыйк.

*Сәлимә белән Рәхилә дога кылалар.*

**Сәлимә:** Әйе, ахирәткәем.

**Рәхилә:** Армия – һәр ир-егетнең бурычы инде.

**Сәлимә:** Хәтерлисеңме, авылыбызның асыл егетләрен сугышка озаткан көнне?

**Рәхилә:** *(уйчан)*. И-и-и, ничек онытасың инде.

*Әбиләр артта утыра, алда кичке уен күренеше. Салмак көй агыла. Бер төркем егетләр һәм кызлар – кичке уенда. Егетләр гармунга кушылып җыр сузалар. Җыр тәмамлана.*

**Айнур:** Моңаймыйк әле, без бит дошманны куарга барабыз.

**Әмир:** Әйе, кызлар. Әйдәгез әле, биегез.

*Дәртле көй уйный, кызлар бииләр. Бию тәмамлана һәм егетләр чыгып китә, кызлар озатып калалар. Әкрен генә көй астында ике әби кала.*

**Рәхилә:** Заманалар башка иде, ә балаларга якты киләчәк насыйп булсын.

**Сәлимә:** Амин. Амин!

ДӘВАМЫ БАР

ЭЧТӘЛЕК

**ШИГЪРИЯТ** . . . . . 4
Дәү әнием – сугыш баласы . . . . . 5
Яратмыйм сугыш сүзен . . . . . 6
Дистант дәрес . . . . . 7
Татарстан – туган илем . . . . . 9
*** . . . . . 11
Авылым . . . . . 12
Яратам туган ягымны . . . . . 13
Туган телем . . . . . 14
Мәңгелеккә китсен сагышлар... . . . . . 15
Җиңү көне . . . . . 16
«Хис итәсем килә берәр нәрсә» . . . . . 17
Алиш абыйга . . . . . 18
*** . . . . . 19
Иске Казаным . . . . . 20
Күбәләк . . . . . 21
Хуш киләсең, Сабан туе . . . . . 22
Язам әле авылым турында . . . . . 23
Җиңүегез өчен мең рәхмәт! . . . . . 25
Яшә сөенеп кенә . . . . . 27
Милләтләр дуслыгы . . . . . 28
Буран . . . . . 29
Китаплардан, зинһар аермагыз! . . . . . 30
Песием . . . . . 31
Туган телем . . . . . 32
Минем әти иң-иңе . . . . . 33
Кошларым . . . . . 34
Нәкый Исәнбәткә . . . . . 35
Әнием гөле . . . . . 37
Калдыр . . . . . 38
Татар телем – туган телем . . . . . 39
Дәрестә . . . . . 40
Сагыну . . . . . 41
Бүген минем шундый халәт . . . . . 42
Саф һава – тәнгә дәва . . . . . 43
Йолдызым . . . . . 44
Хатын-кызга . . . . . 45
*** . . . . . 46
*** . . . . . 47
Дус . . . . . 48
Был-был . . . . . 49

Әнием . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Күзлегемне салдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Үзебезне җуярбыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Синле киләчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

**ЧӘЧМӘ ӘСӘР** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Кошчыклар «үстердем» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Чишмә турында хәтирә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Умартачы малай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Бәләкәчнең рәхмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Имтихан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Мәгънәсез кичәләр, ләкин кадерле кочаклар . . . . . . . . . . 80
Зәңгәр түбәле йорт сере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Хамелеон . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Үткәннәргә сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Хәерлесен насыйп ит . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94

**БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
«Светофорны кем уйлап тапкан?» . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
«Мин аны көттем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
«Сыналган дуслар» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
«Чын була күрмәсен!» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
«Батыр йөрәкле Куян» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Тиен белән Куян дуслыгы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
«Кырмыскалар аланында» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
«Бакалар язмышы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Кызыл чәчле Зәринә» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
«Кечкенә партизан- Азат» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
«Сагыз» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
«Дуслар» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120

**ПУБЛИЦИСТИКА** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Мин – алтын урталыкта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Йөрәгемә май була . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Көзнең сихри бизәкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Журналистны аяклары гына ашатмый . . . . . . . . . . . . . . 129
Безнең Марусябыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

Анда рәхәттән йөрүчене таба алмассың: хәерче базары «елак» көнне ничек яши? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Айсылу Мингалим: «Балаларны дөрес кабул итеп, аңлый белергә генә кирәк» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Без татарлар – бер халык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
1 март - Песиләр көне: «Әбине күмеп кайтканда ишек төбендә песи утыра иде» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Күз меңне күрә, дин берне сөй, ди . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Суслонгердан репортаж: «Ачлыктан шешенгән иренә хатыны күкрәк сөтенә хәтле имезгән». . . . . . . . 154

**ДРАМАТУРГИЯ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
«Әлли-бәлли, бишегем...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Әз генә калды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Кая барабыз?! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Җир-ана чакыруы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Замана аулак өе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Беркайчан да соң түгел .... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180

«СӘЛӘТКӘ НУР БУЛГАН ЙОЛДЫЗЛАР»
**КАЗАН, 2021**

